# ШУРА

№ 37
2022




2000999960581

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК

Җомга хотбәсе . . . 5
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . 11

ВӘГАЗЬЛӘР . . . 15
Гарәфә көне . . . 16
Корбан гаете вәгазе . . . 20
Корбан гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы . . . 27
Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . 31
Корбан гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . 34
Табигатьне саклау – һәр кешенең бурычы . . . 38
Туганлыкны саклау гомерне озынайта . . . 42
Мөхәррам ае фазыйләтләре . . . 47
Гашурә көне хакында . . . 53
Мөселманнар өчен хәзерге заман казанышлары . . . 58
Заман һәм мөселман гаиләсе . . . 64
Дөньялар тыныч булсын . . . 70
Гыйлем алу – фарыз . . . 75
Әбү Мансур Әл-Матуриди юлыннан барабыз… . . . 78
Диннәр арасында татулык . . . 83
Тәрбияле ата һәм ана . . . 87
Ислам – тынычлык юлы . . . 91
Мәүлид кичәсе . . . 98

ФӘТВАЛАР . . . 104
Аллаһыны мәхлүкатларының сыйфатлары белән тасвирларга ярыймы? . . . 106
Намазда бишенче рәкәгатькә бассаң, нишләргә? . . . 109
Тәсбихне кайчан әйтергә – фарыз яки сөннәт намаздан соңмы? . . . 111

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи . . . . . . . . . . . . . . . 117

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123

ТАРИХ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Рус миссионерларының татар
муллалары хакында фикерләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
«Коръәнне яттан өйрәнү җиңел,
аннары хәтердә саклау кыен» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

ФӘН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Әбү Хәнифәнең укытучылары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161

ТӘРБИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Әдәпләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Бәлгам бине Багура . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Изге эшкә боеру һәм яман эштән тыю бүлеге . . . . . . . . . . 180
Төшенкелеккә бирелү – шәйтаннан . . . . . . . . . . . . . . . . . 194

ӘДӘБИ СӘХИФӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200
Кайнар диңгез юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201

**«ШУРА» дини альманах, №37**

*июль–сентябрь 2022*
*зөлхиҗҗә 1443-сафәр 1444*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Айсылу Юлдашева

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ленар Хамматов

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ООО «Медиа Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420021, Казан шәһ., Г.Камал ур., 53-46.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 21.06.2022
Чыгу көне: 05.07.2022

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на
татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

____________________________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ❁ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ❁ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ❁

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ❁ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ❁ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ❁ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ❁ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ❁ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ❁

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ❁ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ❁ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ❁ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً❁ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ❁ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ❁ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ❁ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ❁ كَمَا

بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞
اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللَّهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وَهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин», – дип әйтә.

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәhи, әлхәмдүлилләәhи, әлхәмдүлилләәhил-ләҙии hәдәәнә лиhәәҙәә вә мәә күннәә линәhтәдийә ләү ләәән hәдәәнәллаh. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәh. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиhил-кәриими әстәгыйҙү билләәhи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаh». Нәшhәдү ән ләә иләәhә илләллаhу. Вәхдәhү ләә шәриикә ләhү. Шәhәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләhи. Вә нәшhәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүhү вә расүүлүhү. Дәәгыыйнәә иләл-лаhи. Салләллаhу тәгаалә галәйhи вә галәә әүләәдиhи вә әзвәәҗиhи вә галәә хуләфәә-иhир-раашидиинәл мүршидиинәл мәhдиййинә мин бәгъдиhи. Вә үзәраа-иhил кәәмилиинә фии гаhдиhи. Хусуусан минhүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусҙмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләhүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаhи тәгаалә галәйhим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаh! Иттәкуллаhә вә әтыыйгууhу. Иннәллаhә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә hүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаhу газзә вә җәллә фии китәәбиhил кәриими әстәгыйҙү билләhи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаhу галәйhи вә сәлләм: ______________________________

______________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять hәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалаллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрууун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин», – дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[1] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

______________________________________________

[1] 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа ияручеләргә

сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән,**

**[көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*8 нче июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Гарәфә көне

Галәмнәрне юктан бар итеп, безнең тәнебезгә җан иңдерүче, бөтен нигъмәтләрне бирүче Аллаһы Раббыбызга дан-мактаулар булса иде. Безгә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватларыбыз булса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, Аллаһы рәхмәте белән олы бәйрәмебез якынлашты, ул – Корбан гаете. Шушы бәйрәмне һәр мөселман түземсезлек белән көтә, чөнки бу бәйрәм Ислам дөньясы өчен Аллаһы тарафыннан билгеләнгән бәйрәм. Һәрберебез шушы бәйрәмнең тарихын һәм әһәмиятен белә. Әмма әле шушы вакытта хаҗиларның изге җирдә булып, иң бәхетле, иң җаваплы этапта икәннәрен белүчеләр күп түгелдер, чөнки хаҗ гыйбадәте һәм сәфәр нәкъ менә шушы корбан бәйрәменә бәйле.

Хаҗның төп нигезләренең берсе – ул Гарәфә көне, ягъни шушы көнне хаҗилар Гарәфәт тавында гыйбадәт кылып, Аллаһыдан ярлыкау сорап, догалар кылып, Коръән укып, намазлар укый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы көннең мөһимлеген һәм Аллаһы каршында бөеклеген билгеләп, бик күп хәдисләр җиткереп калдырган. Гомумән алганда, хаҗ гыйбадәте – һәр мөселман өчен дулкынландыргыч гыйбадәт. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَأَذِّن فِي النَّاسِ بِالْحَجِّ يَأْتُوكَ رِجَالًا وَعَلَىٰ كُلِّ ضَامِرٍ يَأْتِينَ مِن كُلِّ فَجٍّ عَمِيقٍ

**«Кешеләр арасында хаҗны [фарыз буларак] игълан ит, җәяү һәм һәр ерак юлдан килгән арык [һәм алҗыган] дөя өстендә сиңа килсеннәр».**

«Әл-Хаҗ», 22:27

Ә инде бу көндә шушы изге җирләргә бара алмаган мөселманнар бәйрәм мохитен ясарга тырышырга тиеш. Бу көнне ураза тоту бөтен гөнаһларның гафу ителүенә бер сәбәпче була – бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә әйтеп калдырган. Шушы көнне ураза тоткан өчен, Аллаһы Тәгалә бөтен кече гөнаһларны кичерә, ә инде белеп һәм белми кылган олы гөнаһлар өчен, уразада булган хәлдә Аллаһыга тәүбә белән ялварсак, Раббыбыз кичерми калмас, чөнки Аның рәхмәте киң. Шушы көнне Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм күп итеп игелек кылып, начарлыклардан тыелып, дога вә ярлыкау сорарга кушкан. Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, тәшрикъ көннәрендә, һәр намаздан соң тәшрикъ тәкбире әйтелә. Шушы көннән алып без Корбан гаетенә әзерләнә башлыйбыз. Якын-тирәбездәге туганнарга, дусларга, әти-әниләргә бүләкләр әзерләп, олы хөрмәт күрсәтсәк, безгә Аллаһының рәхмәте булыр. Бу көннең бер генә мизгелен дә бушка үткәрмәскә кирәк, чөнки безгә бик күп фазыйләтләр бирелә, хаҗга бара алмасак та, изгелек кылудан туктамыйча дога кылу тиешледер.

Бу олы бәйрәмдә хаҗга бармаган, әмма Аллаһы рәхмәте белән корбан чалу мөмкинлегенә ия булган кардәшләребез дә аз түгел. Бу гыйбадәтне кылучы мөселманнарга берничә нәсыйхәт бирәсе килә. Корбан якынаюны аңлата, ягъни Аллаһы Тәгаләгә якынаю, Аның рәхмәтенә, гафу итүенә, ризалыгына якын булу. Әлбәттә инде шушы мөһим гыйбадәтне ихлас күңел белән үтәү тиешле. Күп вакыт Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәтеп калдырган сөннәтләр үтәлми калу куркынычы бар. Шундый хәл булмасын өчен, берничә кагыйдәне искә алыйк:

1. Корбан итеп чалынасы хайванны кыйнамыйча, җәберләмичә, тыныч кына итеп, чалынасы җиргә алып бару.

2. Хайванны чалган вакытта пычакның үткен булуы яки пычакны үткенләгәндә хайванга күрсәтмичә үткенләү, бер хайванны чалуны икенче хайванга күрсәтмәү.

3. Хайванны дөрес итеп чалу, һәм иң мөһиме – чалган вакытта: «Бисмилләәһи Аллааһү Әкбәр», – дип әйтү, чөнки без хайван чалганда шушы сүзне ниятләп әйтмәсәк, чалынган малның ите хәләл булмый.

4. Корбанны чалганда тиешле догасын кылу һәм чалгач, шушы малның ите белән тиешле кешеләрне сөендерү.

Еш кына бала тугач чалына торган гакыйка корбанын Корбан гаетендә чалалар, әмма бу гакыйка корбаны булмый, ул гает корбаныннан китә. Шуңа да бик игътибарлы булсак иде.

Әгәр инде безгә хаҗ кылу мөмкинлеге татый икән, һичшиксез, һәр мөселман өчен хәерле гыйбадәт һәм хәерле тормыш сорарга кирәк.

Аллаһы Тәгалә безгә иксез-чиксез мөмкинлекләр юлын ача, безгә бары шушы мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмыйча, аларны дөрес кулланырга кирәк. Һәр мизгелдә сәгадәт алып яшәү мөмкин вакытта, шушы юлдан барсак, бик хәерле булыр. Аллаһы Тәгалә гаетләребезне мөбарәк, корбаннарыбызны, уразаларыбызны кабул кылса иде, ә хаҗиларга исәнимин хәлдә кабул хаҗлар белән әйләнеп кайтуны насыйп итсә иде!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт

итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*9 нчы июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Корбан гаете вәгазе

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!

Барлык шөкерләребезне, рәхмәтләребезне безне шушында җыйган, безгә шушы бәйрәмнәрне күрергә насыйп иткән Раббыбыз Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә әйтәбез. Аллаһыга шөкер, нинди зур бәйрәм җитте. Шушы вакытта Татарстаныбызда, ә көн дәвамында Җир шары буйлап Корбан бәйрәмен билгеләп үтәбез! Әмма бәйрәм җитеп, аны каршы алырга насыйп булмаган кардәшләрбез дә бар. Аллаһы Тәгалә аларга Үзенең рәхмәтен бирсә иде. Безнең дә кылган гөнаһларыбызны ярлыкаса иде, изгелекләребез, гыйбадәтләребез, зикер-тәсбихләребез өчен савапларны арттырып бирсә иде. Барчабызга да ике дөнья бәхете, сәгадәте насыйп булсын.

Раббыбызның әмеренә буйсынып, пакь, күркәм киемнәребезне киеп, хушбуйлар кулланып, таң белән мәчетләребезгә җыела алдык. Аллаһы Тәгалә шушы вәгазьләребезне дә бәрәкәтле кылсын, күркәм вәгазьләр белән вәгазьләнеп, үзебез, милләтебез, илебез, өммәтебез өчен, кадерле әти-әниләребез, имам-остазларыбыз өчен догалар кылып, гает намазларын башкарганнан соң, өйләребезгә кайтып, әзерләп куйган корбаннарыбызны чалырга, туганнарыбыз-дусларыбыз янына кунакларга барырга, вафат булганнарның каберләрен зиярат кылырга насыйп булса иде, әәмин!

Ел да көтеп ала торган ике бәйрәмебез бар. Берсенә алдан ук сәламәтлегебезне карап, рухи яктан чистарынып, ә аннан соң бер ай буе фарыз булган уразаларыбызны тотып, сөннәт булган тәравих намазларыбызны укып һ.б. гамәлләр кылып ирешсәк, икенчесенә малы-

быз белән, ягъни нисабыбыз җитсә иде дип, алдан ук кәсеп ягын карап, хәләл акчалар туплап әзерләнәбез. Һәм, шөкер, бүген без икенче зур бәйрәмебезгә дә ирештек. Аллаһы Тәгалә чалыначак корбаннарыбызны бары тик Үз ризалыгы өчен дип, барыбыздан да кабул итсә иде.

Аңлашыла ки, мөмкинлекләре булган кешеләр бу көндә шушы изге гамәлләрне башкара ала, ә маллары нисапка җитмәгән, яки башка сәбәпләре булган кешеләр дә бар бит. Кемнәргә корбан чалу вәҗиб соң?

Корбан чалучы:

1) мөселман,

2) үз акылында,

3) балигъլык яшендә,

4) ирекле булырга тиеш.

Аның:

5) сәфәрдә булмавы,

6) нисаб күләмендә мал-мөлкәте булуы шарт.

Нисабка ел дәвамында ия булмаска да мөмкин, ягъни якын арада гына да кешегә акча, мал кереп, ул нисапка җитсә, бу кешегә корбан чалу вәҗиб була. Әбү Хәнифә хәзрәтләре бу хөкемне Аллаһы Тәгаләнең Коръәни Кәримдәге аятенә нигезләнеп чыгара. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ

**«[Шулай булгач] Раббың өчен намаз укы һәм [Аның исеме белән] корбан чал [да, корбан итләрен юксылларга тарат]».**

«Кәүсәр», 108:2

Әхмәдһади Максуди хәзрәтләре үзенең «Гыйбадәте Исламия» китабында вәҗиб сүзенә мондый аңлатма бирә: «Вәҗиб гамәлне кылган кеше – саваплы, кылмаганы – гөнаһлы, ә аның вәҗиблегенә (тиешле булганына) ышанмаган кеше зур гөнаһлы була. Вәҗиб гамәлләр: витр

һәм гает (ураза һәм корбан бәйрәме) намазларын уку, фитыр садакасын бирү, корбан чалу». Һәм шул ук китабында ул фарыз дигән төшенчәгә дә аңлатма биреп болай дип әйтә: «Фарыз гамәлне кылган кеше – саваплы, кылмаганы – гөнаһлы, ә аның фарызлыгына (тиешле булганына) ышанмаган кеше кяфер (имансыз) була. Фарыз гамәлләр: Ислам диненең хаклыгына ышану, көн саен биш вакыт намаз уку, Рамазан аенда ураза тоту, ел саен малның зәкятен бирү, мөмкинлеге булган кешегә, гомерендә бер мәртәбә Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып хаҗ кылу».

Аллаһыга шөкер, як-ягыгызга карагыз әле. Күрше-күлән, дуслар-туганнар белән бүген менә Аллаһы йортында шушы олуг бәйрәмне үткәрергә дип килдек. Динебездә аның тоткан урыны – вәҗиб. Шуңа да мин, әлеге форсаттан файдаланып, Аллаһы Тәгаләнең башка әмерләре турында да, ягъни биш вакыт намаз, ураза, хаҗ турында да исегезгә төшереп үтәм. Аллаһының барлык әмерләрен дә үтәргә тырышып яшәгәндә генә, Ул безгә саулыгын да, сәламәтлеген дә, тынычлыгын да бирер.

Чыннан да, без соңгы елларда нинди генә сынаулар аша үтмәдек. Яңгырлар яумау, яки киресенчә, күп итеп яву; җәй уртасында бозлар явып, бакчаларыбыз, иген-кырларыбызга зыян килү; давыллар чыгып, агачлар сыну, өй, каралты-кураларның түбәләрен алып ату; бертөрле вирус килеп, пандемия булып, өйләрдә дә утыру. Ул вакытларда хәтта мәчетләргә йөрү буенча да кайбер кагыйдәләргә буйсынырга, битлекләр дә киеп йөрергә туры килде. Кадерле җәмәгать, кешенең аяк киеме бавы чишелү дә сынау, кеше шуның өчен дә Аллаһы Тәгаләгә хәмедләр әйтеп, риза булып бәйләп куйса, ул аның өчен дә савап алачак. Ә болары инде күзгә күренерлек зур сынаулар. Ә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм күп хәдисләрендә сынауларның безнең кулларыбыз кылган гамәлләр аркасында килүен әйтеп калдырды. Шуңа күрә, бүген монда җыелган кебек, сезне барыгызны да, калган намазларга да, ике

гаеттән олуграк, көннәрнең солтаны булган җомга намазларына да чакырып калам. Өммәтебез бер һәм бердәм булса иде. Әәмин!

Корбан бәйрәме – җир шарының барлык почмакларында зурлап билгеләп үтелә торган мөселман бәйрәме ул. Ә аның тарихы Ибраһим галәйһиссәлам һәм аның улы Исмәгыйль галәйһиссәламгә кайтып кала. Бу һәрберебезгә дә яхшы таныш булган вакыйга елдан-ел кабатланып торса да, аннан чыккан дәресләр безнең күңелләребездә тиешле урынны ала алды микән? Без кайчакларда кесәбездә булган акчаны да садака итеп бирергә кызганып торабыз. Кайчакларда кешеләргә карап елмаюыбызны да жәллибез. Сәлам бирергә дә саранланабыз. Ә монда?! Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә барлык малын да түгел, байлыгын да түгел, ә, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, газиз баласын корбан итәргә боера. Инде корбан итәргә алып барган вакытта Ибраһим галәйһиссәламдә, йә Исмәгыйль галәйһиссәламдә, йә Хаҗәр анабызның күңелендә икеләнү хисләрен күреп булдымы? Киресенчә, шәйтан Исмәгыйль хәзрәтләре янына килеп, котырта башлагач та, Исмәгыйль галәйһиссәлам аны куып җибәрде. Һәм без бүген шушы мәчетләрдә җыелган кебек, миллионлаган кардәшләребез бүген хаҗ сәфәрендә. Һәм алар да Исмәгыйль хәзрәт кебек таш ату йоласын башкаралар. Аллаһы Тәгалә аларның хаҗларын кабул кылсын. Белегез: кабул кылынган хаҗ өчен бер бүләк – җәннәттер!

Ибраһим галәйһиссәламнең үткен пычагы Исмәгыйль галәйһиссәламгә бер зыян да китерә алмый. Риваять буенча, шулвакыт Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламгә болай дип әйтә: «Ий, Җәбраил, фәрештәләр бу сарыкны алып, Ибраһим янына алып барсыннар. Һәм ул улы урынына шушы сарыкны корбан китерсен». Җәбраил галәйһиссәлам: «Бу – бик зур рәхмәт, йә Раббым», – дип җавап кайтара. Һәм Аллаһы Тәгалә: «Бөеклегем белән ант итәм. Һәрбер фәрештә үзе белән бер сарык алып килсә дә, бу барыбер җитәрлек рәхмәт бул-

маячак, чөнки Исмәгыйль: **«Ий әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне [һич уйлап тормыйча] үтә. ИншәАллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», – диде**», – дип әйтә. Кадерле җәмәгать, Аллаһы Тәгалә Исмәгыйль галәйһиссәламне нинди олуг дәрәҗәләргә күтәрә. Безгә дә Аллаһы Тәгалә каршында ихлас коллардан булырга насыйп булса иде.

Күрәбез, бер вакыйгадан корбан чалу, таш ату кебек күпме күркәм йолалар калган. Ә иң мөһиме, ул безне Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен үтәргә, сабыр булырга, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә өмет итәргә өйрәтә. Аллаһы Тәгалә колларына безнең аналарыбызга караганда да рәхимлерәк, шәфкатьлерәк. Онытмасак иде шуны.

Инде бергәләшеп корбан бәйрәме намазын укыгач, кайтып, Аллаһы бирсә, корбаннар чалырбыз. Аллаһы Тәгалә кешене хайваннар һәм үсемлекләр өстеннән хәлиф итеп кылды. Шуңа күрә без аларга карата мәрхәмәтле, игътибарлы булырга тиешбез. Инде корбаннарыбыз кабул булсын, чалуыбыз дөрес булсын өчен, аның тәртибен искә төшереп үтик.

Корбанлык өчен ак яки күк төсендәге, бөтен әгъзалары камил, сәламәт, зур мөгезле симез тәкә хәерлерәк санала. Корбан фәкать Корбан бәйрәменең әүвәлге өч көнендә генә чалына, әмма бүген чалу яхшысы булып санала. Менә бездәге кебек, корбан бәйрәме намазлары үткәрелгән шәһәрләрдә һәм авылларда, корбан намаздан соң чалына башлый. Ә бәйрәм намазы укылмаган авыллар, җирлекләр бар, алар корбаннарын таң җиткәннән соң чала башлый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бүген безнең беренче эшебез – бәйрәм намазы уку, ә аннары – корбан чалу. Кем шулай эшли, сөннәтебезне үти. Әгәр дә кемдер корбанны намаздан иртәрәк чалса, аның ите гаиләсенә бирелгән гади иттән китәчәк». Шулай итеп, корбан чалу – шушы намаздан соң башланып, өченче көннең ахшам намазына кадәр дәвам итә, ахшам намазыннан соң корбан чалу дөрес булмый.

Динебез табигатькә дә, хайваннарга да хөрмәт белән карарга боера. Корбан сүзенең мәгънәсен «якынаю» дип карасак, димәк, без бу гамәлебез белән Аллаһы Тәгаләгә, Аның ризалыгына якынаерга телибез. Шуңа да, бигрәк тә корбанлык хайванын, газап кылмыйча, сул ягына яткырырга һәм башын кыйблага борып куярга, үткен пычак кулланырга тиешле.

Хайванны чалыр алдыннан, корбанлыкның иясе яки суючы яткан хайванга карап, түбәндәге доганы укый:

اَللَّهُمَّ إِنَّ صَلَاتِى وَنُسُكِى وَمَحْيَاىَ وَمَمَاتِى لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

لَا شَرِيكَ لَهُ اَللَّهُمَّ تَقَبَّلْ هَذِهِ الْأُضْحِيَّةَ

(مِنْ فُلَانِ بْنِ فُلَانْ) أَوْ (مِنْ فُلَانَةِ بِنْتِ فُلَانْ)

«Аллаһуммә иннә саләәтии вә нүсүкии вә мәхйәәйә вә мәмәәтии лилләәһи раббил-гааләминә ләә шәриикә ләһ. Аллаһуммә тәкаббәл һәәҙиһилудхиййәтә (мин фүләәни ибни фүләән) әү (мин фүләәнәтә бинти фүләән)».

Мәгънәсе: «Йә, Раббым, дөреслектә, минем намазым һәм гыйбадәтләрем, тереклегем һәм үлемем барча галәмнәрнең хуҗасы Аллаһы Тәгалә өчен, Аның һичбер тиңдәше юк. Йә, Раббым, ошбу корбанны фәлән-фәлән улыннан яки фәлән-фәлән кызыннан кабул ит». Чаласы кеше хайванны: «Бисмилләһ, Аллаһү Әкбәр», – дип чала һәм дога кыла.

Корбан чалачак кешегә, хаҗиларга охшау өчен, зөлхиҗҗә ае кергәннән соң чәчен алдырмыйча һәм тырнакларын кисмичә тору – мөстәхәб.

Әлбәттә, корбан чалгач, алдарак әйтеп узганча, без туганнар-дусларга да барып, бәйрәм белән котлашабыз, зиратларга барып каберлекләрне дә чистартабыз. Әмма, тагын бер мөһим аспект бар: балаларыбыз өчен бу көнне бәйрәм итеп оештырсак иде. Аларның күңелендә бу көннәр чын мәгънәсендә бәйрәм буларак уелып калсын. Шуңа күрә

күркәм табыннар, бүләкләр турында онытмагыз!

Кабаттан барыгызны да бәйрәм белән котлап, яраткан сәхабәләребез кебек: «Тәкаббәл Аллаһ миннәә вә минкүм», ягъни: «Аллаһы Тәгалә бездән дә сездән дә кабул итсә иде», – дип әйтәм. Аллаһы Тәгалә намазларыбыздан да, тәсбихләребездән дә, чалачак корбаннарыбыздан да разый калса иде. Әәмин.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

# خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

## الْخُطْبَةُ الْاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلَامُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لآَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللّٰهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلَاقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللّٰهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللّٰهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللّٰهِ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللّٰهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللّٰهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللّٰهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللَّـهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّـهَ اِنَّ اللَّـهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللَّهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاٰيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللَّـهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلَّـهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللَّـهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللّٰهِ، اِنَّ اللّٰهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللّٰهَ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

# Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транскрипциясе

## Беренче хотбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли вәлҗәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү вәл-әфһәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии һәәҙиһил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-таүәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Нәхмәдүллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләһү вәлиййүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирһү тәкбиираа. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Вә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә’и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааһү тәгаалә вә сәлләмә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый вәл-гаүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәҙәл йәүмә бил-ингаами вәл-ихсәәни вә

иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү ган сәбгәтин вәд-да’нү вәл-мәгзү гән вәәхидин мүҗзиәтү вә ләә йәҗүүзүл-гәҗфәәә’ү вәл-гарҗәәә’ү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәҙһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәәмтисәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгәәләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңҙур нәфсүм-мәә каддәмәт ли-гаад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракә Ллаһу ләнә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии вә ләкүм вә лисәә’ири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

## Икенче хотбә

Әлхәмду лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгинүһү вә нәстәгъфируһү вә нү’минү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи вә нәгүүҙү билләәһи мин шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәду әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә эшһәду әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ.

Иннəллаһə вə мəлəəикəтəһүү йүсаллүүнə галəн-нəбий. Йəə əййүһəлләẓиинə əəмəнү саллүү галəйһи вə сəллимүү тəслиимəə. Аллаһүммə салли галəə Мүхəммəдин вə галəə əəли Мүхəммəдин бигадəди мəн саллəə вə саам. Аллаһүммə салли галəə Мүхəммəдин вə галəə əəли Мүхəммəдин бигадəди мəн кагəдə вə каам.

Саллии вə сəллим гəлəйһи вə гəлəə җəмиигиль-əнбийəə'и вəл-мүрсəлиин. Вə галəə мəлəəикəтикəл-мүкаррабиинə вə галəə əһли таагəтикə əҗмəгиин мин əһлис-сəмəəүəəти вəл-əрадыйн. Вəрхəмнəə вəхшүрнəə мəгəһүм бирахмəтикə йəə əрхəмəр-раахимин.

Аллаһүммə-гъфир лилмү'миниинə вəл-мү'минəəт, вəл-мүслимиинə, вəл-мүслимəəт, əл-əхъйəə'и минһүм вəл-əмьүəəт, иннəкə əнтə мүҗиибүд-дəгəүəəт вə мүнзилүл-бəракəəт, вə раафигуд-дəраҗəəт, вə каадыйүл-хəəҗəəт, бирахмəтикə йəə əрхəмəр-раахимиин.

Аллаһүммəр-хəмил хулəфəə'əр-раашидиинə вəл-үмəрааа'əл-мəдыйнəл-ләẓиинə кадау билхəккы вə кəəнүү йəгъдилүүн. Аллаһүммəн-сурмəн нəсараддиинə вəһди мəн хаẓəлəддиин. Гибəəдəллааһ, иннəллааһə йəъ'мүрү бил-гадли вəл-ихсəəни вə ийтəəəи ẓил-курбəə вə йəнһəə ганил-фəхшəəəи вəл-мүнкəри вəл-бəгъйи йəгыйиẓукум лəгəлләкүм тəẓəккəрүүн. Үẓкүруллааһəл-галиййəл-гаẓыймəл-хəййəл-каййүүм, йəẓкүрүкүм вəш-күрүүһү йəзидкүм, вəстəгъфирууһүү йəгъфир лəкүм вə ләẓикруллааһи тəбəəракə вə тəгəəлəə əглəə вə əүлəə вə əгəззү вə əҗəллү вə əгẓамү вə əтəммү вə əкбəр.

## Корбан гаете хотбәсенең тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының Заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлүкъләр дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле Зат булганына) акыл ияләре хәйран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, пәйгамбәребез Мөхәммәд – Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) – җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм Олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә корбанны: «Корбан чал!» – дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек – җиде кешедән, сарык вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар – Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир тәшрикъне Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһыга сыенам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ
اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:18

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хотбә

Аллаһыга мактау булсын, Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыенабыз. Кемгә Аллаһы һидаять бирсә — аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидаять бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд Аның колы һәм хак Расүле булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки: Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәр салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәр салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә Мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син – догаларны кабул итүче, бәрәкәт иңдерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидаять бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне зикер итү – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәләләтле, иң камил, иң зур гамәл.

*15 нче июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Табигатьне саклау – һәр кешенең бурычы

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә:

أَلَمْ تَرَوْا أَنَّ اللَّهَ سَخَّرَ لَكُم مَّا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ

**«Күрмәдегезме, Аллаһы күкләрдә булганнарны һәм җирдә булганнарны сезнең [файдалануыгыз] өчен буйсындырды...»**, – дип әйтә.

«Локман», 31:20

Адәм баласына булганның кадерен белмәү сыйфаты хас. Һәм ул барлык бирелгән нигъмәтләрне дә мәңгелек дип кабул итә. Расүлебез кешенең сәламәтлек һәм буш вакыт кебек нигъмәтләрнең кадерен белмәве хакында әйткән.[1]

Кадерен белми торган тагын бер нигъмәт – ул табигать, безне чолгап алган әйләнә-тирә мохит. Кызганычка, бу олуг нигъмәткә безнең игътибарыбыз бик аз. Без табигатьне мәңгелек, ничек һәм күпме куллансак та бетми торган байлык сыман кабул итәбез. Бу мөнәсәбәтебез бер дә дөрес түгел, чөнки әгәр бу мәсьәләгә җитди карап уйлансак, табигатьнең адәм

[1] Имамнар Әл-Бохари, Әт-Тирмизи, Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

баласы тарафыннан бик зур золым күргәнен аңларбыз. Пәйгамбәребез: «Һәрбер исраф – харам», – дип әйткән. Ә безнең табигатькә карата сансызлыгыбызның, аның нигъмәтләрен исраф кылуыбызның чиге юк.

Кызганычка, су, туфрак һәм һаваның ни дәрәҗәдә пычранганын без аңларлык халәттә түгел. Һәркөнне диярлек урманнарның, яшеллекләрнең кеше тарафыннан һәлак ителүен күзәтәбез. Урманнар – планетабызның үпкәләре, дигән бик тә мәгънәле сүзләр безгә тәэсир итми. Без начар, пычрак һаваны сулап яшәргә дә риза. Бүгенге көндә күп кенә авыруларның артуы, климатның үзгәрүе, озон катламының зарарлануы, хайваннарның, кошларның, үләннәрнең, хәтта сулыклардагы балыкларның һәлак булуы, безнең – кешенең табигатькә салган зыянының кайтавазы ул.

Әлбәттә, бәлки болар хакында бу дөньяда сорау алынмас, әмма Ахирәттә барысы өчен дә җавап бирәсебез булачак, чөнки без булганның кадерен белмичә, табигать дигән нигъмәткә салкын карыйбыз. Шул сәбәпле, Аллаһы тарафыннан безгә бирелгән сәламәтлек дигән нигъмәткә зыян салабыз. Ә югарыда Пәйгамбәребезнең сәламәтлек хакында әйткән хәдисен искә алып узган идек.

Коръәни Кәримдә агачның һәр җимеше безнең өчен нигъмәт булуы хакында язылган:

وَهُوَ الَّذِي أَنشَأَ جَنَّاتٍ مَّعْرُوشَاتٍ وَغَيْرَ مَعْرُوشَاتٍ وَالنَّخْلَ وَالزَّرْعَ مُخْتَلِفًا أُكُلُهُ وَالزَّيْتُونَ وَالرُّمَّانَ مُتَشَابِهًا وَغَيْرَ مُتَشَابِهٍ ۚ كُلُوا مِن ثَمَرِهِ إِذَا أَثْمَرَ وَآتُوا حَقَّهُ يَوْمَ حَصَادِهِ ۖ وَلَا تُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ

**«Ул – [төс, тәм, зурлык һәм ис ягыннан] җимешләре төрле булган терәкле һәм терәксез [йөзем куаклары үскән] бакчаларны да, хөрмәләрне, игеннәрне дә, [төсе һәм тәме белән] бер-берләренә охшаш һәм охшамаган итеп зәйтүн һәм анарларны Яратучы.**

**Уңыш биргән вакытларында, сез [боларның бөтенесенең] җимешләрен ашагыз, урып [җыеп] алган көнне хакын [гошер һәм зәкятен] бирегез, ләкин [бала-чага һәм гаилә әгъзаларын мохтаҗ калдырырлык дәрәҗәдә күп биреп] чиктән ашмагыз. Һичшиксез, Ул исраф итүчеләрне сөйми».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:141

Әнәс бине Мәлик Пәйгамбәребезнең мондый күркәм хәдисен риваять иткән: «Әгәр иртәгә Кыямәт җитәсен белсәң дә, бүген агач утырт», ягъни, шул рәвешле изге гамәл кылып, әҗер-савап эшләп калырга ашык. Шулай ук ул Расүлебезнең: «Әгәр берәү агач утыртса яки берәр нәрсә чәчсә, ә аннары кош, кеше яки хайван шул утыртылганнан яки чәчүлектән берәр нәрсә ашаса, бу, һичшиксез, әлеге кешегә садака булып язылыр», – дигән сүзләрен тапшырган.

Сүз дә юк, һәркем агач утырту кебек гамәлләрне башкара алмаска мөмкин, әмма безгә кечкенә генә булып тоелган кайбер гамәлләрнең дә Аллаһы каршында олуг булуын беләбез. Әбү Һөрайра пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләрен риваять иткән: «Иманның алтмыштан артык тармагы бар. Аларның иң хәерлесе – «ләә иләәһә илләллааһ» сүзләре, ә иң түбәне – юлдан кешеләргә комачау итә торган нәрсәләрне алып кую. Оялчанлык та – иманның бер тармагыдыр».

Расүлебез шулай ук: «Берәү Аллаһыга итагатьлек кылып, кешеләр йөри торган юлдан таш, агач яки сөякне алып куйса, ул кеше үзен уттан саклар», – дигән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Расүлебезнең: «Мин кешеләргә комачаулаган агачны юлдан алып атканы өчен генә җәннәтнең гүзәллекләреннән ләззәтләнгән кешене күрдем»[1], – дигән сүзләрен тапшырган.

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Сәламәтлегебез, буш вакытыбыз, гаиләбез, малыбыз, гомеребез безнең өчен әманәт булып торган кебек, безне әйләндереп алган табигать тә безнең өчен әманәт булып санала. Аңа салкын карау Раббыбызга шөкер итмәүгә тиң. Шуңа да шөкер итүчеләр исәбендә булырга теләсәк, Раббыбыз тарафыннан бирелгән һәр әманәткә игътибарлы булып яшәсәк иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*22 нче июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Туганлыкны саклау гомерне озынайта

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Иң якын туганнар – ул безнең әти-әниләр. Әти-әнисе исән булган һәм балаларына битараф булмаган кешеләр бик тә бәхетле. Ата-ананы берәү дә алыштыра алмый, әмма исән-сау булган вакытларында бик сирәкләр генә аларның кадерен белә. Нинди дә булса сәбәп аркасында әтисез йә әнисез үскән балалар әти-әниле булуның ни дәрәҗәдә алыштыргысыз булуын аңлый.

Ислам динендә ата-анага хөрмәт иң беренче урыннарда тора. Күп кенә хәдисләрдә: «Аллаһының ризалыгы – ата-ана ризалыгында, Аллаһының ачуы – ата-ана ачуында»[1], – дип әйтелгән. Икенче бер хәдистә Ислам динендә әни кешенең урыны хакында сүз бара: «Бер кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Йә, Расүлуллаһ, мин кемгә иң олы хөрмәтне күрсәтергә тиеш?» – дип сораган. Пәйгамбәребез: «Үзеңнең әниеңә», – дип әйткән. Бу кеше: «Ә аннары кемгә?» – дигән. Расүлебез: «Әниеңә», – дигән. Әлеге кеше янәдән: «Ә аннары кемгә, йә Расүлуллаһ?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм

---

[1] Имам Әл-Бәйһакый хәдисләр җыентыгыннан.

кабат: «Әниеңә», – дип җавап биргән. Моннан соң сорау бирүче кеше тагын бер тапкыр: «Ә аннары кемгә?» – дип сорагач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аннары әтиеңә, ә аннан соң кардәшлекләре дәрәҗәсе буенча туганнарыңа»,[1] – дип әйткән.

Әти-әниләргә дә үзләренең балалары алдындагы бурычларын онытмаска һәм аларга авырлык китермәскә кирәк. Шулай ук, иреккә омтылу хисләренә һәм башкалардан аерым яшәү омтылышына карамастан, туганнарга карата да ихтирам күрсәтү мөһим. Әгәр элегрәк кешеләр зур гаилә булып бер өйдә яшәсәләр, хәзер һәркем, өйләнмәгән (кияүдә булмаган) кеше булса да, аерым яшәргә омтыла. Нәтиҗәдә, гаилә эчендә аралашуның кимүе, рухи яктан бер-береңнән ерагаю күзәтелә һәм кечкенә генә талаш, үпкәләүләр дә мөнәсәбәтләрнең өзелүенә китерә. Хәтта якын туганнар да үзара еллар буе аралашмаска, бары кайгылы вакытларда гына телефоннан сөйләшеп алырга мөмкин. Әмма Аллаһы Тәгалә безгә төрле очракларда туганлык мөнәсәбәтләрен сакларга кушкан.

وَاتَّقُواْ اللَّهَ الَّذِي تَسَآءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيباً

**«Аның исеме белән бер-берегездән үтенә торган Аллаһыдан [Аңа каршы баш күтәрүдән] һәм туганлык җепләреннән [аларның өзелүеннән] куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – сезне күзәтүче».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:1

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәнен тапшырган: «Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыямәт көненә ышанган кеше туганлык җепләрен сакласын»[2]. Пәйгамбәребез: «Хакыйкатьтә, иман китерүчеләр арасында иң камил иманлыгыз – күркәм холыклы һәм үзенең гаиләсенә хәерле мөгамәләдә

1 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

булучыгыздыр»[1], – дигән.

Мөгаен, һәрбер кешенең дә авыр вакытта бары туганнар гына ярдәм иткәненә, хастаханәгә хәлне белергә килгәненә, туганының өстендә булган бурычларын түләгәненә инанганы бардыр. Шуңа күрә балаларны ятимнәр йортында, өлкәннәрне картлар һәм гарипләр йортында калдыру гадәтен онытырга кирәк. Туганлык җепләрен өзү – Ислам динендәге иң зур гөнаһларның берсе. Коръәндәге күп аятьләр һәм Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләре моның ачык мисалы булып тора.

Коръәндә болай дип әйтелгән:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلاَ تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئاً وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَاناً وَبِذِي الْقُرْبَى وَالْيَتَامَى
وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَى وَالْجَارِ الْجُنُبِوَالصَّاحِبِ بِالجَنْبِ وَابْنِ
السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ إِنَّ اللَّهَ لاَ يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالاً فَخُوراً

**«[Ий коллар!] Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага, [бертуганнар һәм агалар кебек] якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә, [нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән] якын күршегә, [нәселдәшлеге яки өе] ерак күршегә, [ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек] янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә [коллар, җарияләр һәм хезмәтчеләргә] игелек кылыгыз. Һичшиксез, Аллаһы тәкәббер [булганы өчен туган-кардәш һәм күршеләренә карата яхшы мөнәсәбәттә тормаган] һәм [өстенлекләрен санаган] мактанчык кешеләрне сөйми».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:36

Аятьтән күренгәнчә, туганлык җепләрен кан туганнар белән генә түгел, ә күршеләр, дуслар һәм кайсы динне тотуларына карамастан, эштәге хезмәттәшләр, дин кардәшләребез белән дә сакларга кирәк.

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакытта да үзенең сәхабәләренең хәлләре белән кызыксына, аларга кунакка бара иде. Элек кешеләр, дусларының хәлен белер өчен, чүлләрне үтә торган булган. Бүген бу мәсьәлә күпкә җиңеләйтелгән: вакыт булмаса да, теләсә кайсы илдә яшәгән кеше белән кайчан теләсәң, шул вакытта телефоннан сөйләшеп, хәтта сөйләшеп кенә калмыйча, телефон экраныннан күреп аралашырга мөмкин.

Динебездә, туганлык җепләрен ныгыткан өчен, әҗер-савап бирелүе һәм аларны өзгән очракта нәрсә булуы хакында да әйтелгән. Кодси хәдистә болай дип әйтелгән: «Аллаһы Тәгалә әйтә: «Мин – Аллаһы. Һәм мин – Рәхимле (Әр-Рахман) һәм Мин туганлык җепләрен барлыкка китердем, аларга Үз Исемемнән исем бирдем. Һәм берәү аларны сакласа, Мин аның белән элемтәне саклармын, ә берәү аларны өзсә, Мин дә аның белән араны өзәрмен»[1].

Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләр әйткәнен хәбәр иткән: «Кан кардәшлек Гарешкә беркетелгән. Аны тоташтырган кешене Аллаһы тоташтырыр, ә аны өзгән кешене Аллаһы Тәгалә өзәр»[2].

Пәйгамбәребезнең хәдисендә болай дип әйтелгән: «Араларында туганлык җепләрен өзүчеләр булган халык Аллаһының рәхмәтен алмас»[3].

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә, мөселманнар! Туганлык җепләрен саклагыз, дөреслектә, бу гомерне озынайта һәм ризыкны киң кыла», – дигән.

Ышанычлы булган тагын бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Берәү, хаклы түгеллеген белеп, бәхәсне калдырса, Аллаһы аңа җәннәтнең кы-

1 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Әхмәд, Әбү Нүгайм хәдисләр җыентыгыннан.

рыенда, ә хаклы була торып та бәхәсне калдырган кешегә җәннәтнең иң биек урынында сарай торгызыр»[1].

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Җиһаншин,*
*«Габдрәхим Утыз Имәни» мәчете имам-хатыйбы*

1 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

*29 нчы июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Мөхәррам ае фазыйләтләре

Бөтен галәмнәрне юктан бар кылып, шушы дөньяда безне халык кылган, хак белән ялган юлны аерып күрсәткән Раббыбыз Аллаһыга бөтен мактаулар хас. Үз тормышын Аллаһының динен ирештерүгә багышлаган сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават белән сәламнәребез ирешеп торсын.

Хөрмәтле җәмәгать! Көн узып киткәннән соң икенчесе килә, атна-ай узып киткәннән соң икенчесе килеп җитә – үзебез дә сизмичә бер елыбызны уздырып җибәрдек. Бөек Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

يُقَلِّبُ اللَّهُ اللَّيْلَ وَالنَّهَارَ ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَعِبْرَةً لِّأُولِي الْأَبْصَارِ

**«Аллаһы төн белән көнне әйләндереп тора. Һичшиксез, монда күрә белгән [һәм фикерли алган] кешеләр өчен гыйбрәт бар».**

«Ән-Нур», 24:44

Әйе, гыйбрәт бар: кичә генә җомганы укып кайттык – бүген икенчесенә ирештек; кичә генә Рамазан белән Корбан гаетләрен бәйрәм иттек – бүген, ахшамнан соң, яңа елга керәчәкбез. Шулай итеп гомеребез дә узып китә. Хәсән Әл-Басри болай дип әйткән: «Әй Адәм баласы! Дөреслектә, син – көннәр. Һәрбер көн киткән саен, синең бер өлешең китеп бара». Һәрбер ел үтеп киткән саен, безгә бирелгән гомеребез кимеп бара икән. Беренчедән, бөек Хисап көне килгәнче, үзебезне хисаплыйк, ел буена кылган гөнаһларыбызга үкенеп, тәүбәләр китерик һәм елыбызны хәерле гамәлләр белән тәмамлыйк. Икенчедән, яңа елыбызга максатлар

куеп, аларны үтәүдә тырышлык күрсәтик һәм елыбызны изге гамәлләр белән башлыйк. Аллаһының Расүле үзенең бер хәдисендә: «Иң хәерле кешеләр – изгелекләр кылып, озын гомер үткәргән кешеләр», – дигән. Раббыбыз безнең һәркайсыбызга озын гомер биреп, шушы гомеребезне Аллаһыга итагать итүдә үткәрергә насыйп әйләсен.

Һиҗри ел – мөселман өммәте үз тормышын бәйли торган ай хисабына нигезләнгән. Ислам тарихы, хаҗ-ураза-зәкят һәм башка, динебез белән бәйле булган бик күп мәсьәләләр һиҗри хисапка кайта. Һиҗри сүзе – күченеп китү, берәр нәрсәне калдыру дип тәрҗемә ителә. Шәригатьтә «һиҗри» сүзе Пәйгамбәребезнең, аңа сөекле булган Мәккә шәһәрен калдырып, иман урнашкан Мәдинә шәһәренә күченеп китүе белән бәйле. Мәдинә шәһәренә күченеп киткәннән соң, Ислам өммәте өчен яңа тарих битләре ачылды: Исламның хаклыгын күреп, кешеләр динне кабул итә башлады. Гомәр бине Әл-Хаттаб халифәлеге заманында башка дәүләтләр белән мөгамәлә кылу сәбәпле, бөтен нәрсәне теркәп бару гадәткә кертелә һәм, Ислам дәүләте башкалардан аерылып торсын дип, ел хисабы Пәйгамбәребезнең күченеп китү елына бәйләп куела. Моннан башлап, «һиҗрәткә» хәтле ике ел алдан, «һиҗрәтнең» дүртенче елында дип тарих битләренә теркәү башлана.

Бөек Аллаһы болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – унике. Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – хак дин».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Әбү Бәкрат исемле сәхабә, Пәйгамбәребезнең мондый сүзләрен китергән: «Елда унике ай бар. Аларның дүртесе тыелу айлары. Өчесе рәттән килә: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам һәм дүртенчесе – җөмәдәл-ахыр белән шәгъбан арасында булган раҗәб ае»[1].

Харам айлары тыелу айлары дип атала. Әгәр дә ел буена гөнаһ, харам гамәлләр эшләү тыелган икән, ошбу дүрт айда аларның харамлыгы, гөнаһлылыгы арта һәм гади гөнаһ итеп кенә язылып калмый. Шуңа күрә дә Аллаһы аятьне дәвам итеп:

فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

**«Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез»,** – дип әйтә.

«Әт-Тәүбә», 9:36

Әбү Катәдә исемле галим, бу аятьне аңлатып болай дип әйткән: «Харам айларында гаделсезлек эшләү – башка айларга караганда тагын да зуррак гөнаһ рәвешендә языла, хатасы тагын да авыррак була. Шулай итеп, Аллаһы Үзенең хозурында дәрәҗәле, мөһим булган кайсыбер урыннарны, вакытларны, фәрештәләрне, кешеләрне башкалардан аерып, сайлап алды. Фәрештәләр арасыннан, пәйгамбәрләргә Аллаһының хәбәрләрен ирештерүче итеп Җәбраил фәрештәне сайлады. Кешеләр арасыннан, пәйгамбәрлек вазифаларын үтәрлек кешеләрне сайлады. Җирләр арасыннан, Үзенең изге булган урыннарын сайлады. Айлар арасыннан Рамазан аен һәм харам айларын сайлады. Көннәрдән – җомга көнен, кичәләрдән Кадер кичәсен сайлады. Шуңа күрә дә Аллаһы бөекләгән көннәрне сез дә бөекләгез һәм Аллаһы тыйганнарыннан үзегезне саклагыз!»

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Һиҗри елның иң беренче, харам айларыннан булган ай – мөхәррам ае. Шушы айның фазыйләтен һәм аның изге гамәлләрен күрсәтеп, Аллаһының Расүле болай дип әйткән: «Рамазаннан соң, иң хәерле ураза – Аллаһының ае булган мөхәррам уразасы»[1]. Хөрмәтле кардәшләребез, белеп торыйк: әгәр берәр нәрсә, Аллаһының Үзенә бәйләнеп куелса, аның дәрәҗәсе һәм фазыйләте арта! Аллаһының йорты булган мәчетләр, гади йортлар сыман түгел. Аллаһының колы булу – ул бөеклектер. Шуңа күрә дә Аллаһының Расүле: «Аллаһының ае булган мөхәррам», – дип, Аллаһының Үзенә бәйләп, ошбу айның фазыйләтен һәм дәрәҗәсен күтәрде. Димәк, бу ай Аллаһы өчен сөекле, бу айда эшләнелгән изгелекләр өстенрәк, бу айда эшләнелгән гөнаһлар авыррак. Шуңа күрә дә мөселман кешесе, Аллаһы ярата торган нәрсәләрне яратып, ул вакыт һәм урыннарны кулдан ычкындырмыйча, алар сәбәпле Раббысына якынаерга тиеш.

Мөхәррам аенда эшләргә сөннәт булып торган гамәлләрнең берсе – ураза тоту. Уйланучыларга бу урында гыйбрәт бар: ел буена ураза тоту безне калдырмый. Бөек Аллаһы безне Рамазан уразасы белән ныгытты, соңыннан Пәйгамбәребез шәүвәл аеның алты көнен тотарга чакырып: «Ел буе ураза тоткан кебек булыр», – диде. Соңыннан дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә уразага чакырып: «Ул көннәрдә гамәлләребез Аллаһыга күтәрелә. Һәм мин ураза килеш күтәрелүен телим», – дип әйтте. Соңыннан һәр ай саен тулы ай көннәре булган 13, 14, 15 ләрендә уразага дәшеп: «Ел буена ураза тоткан сыман булыр», – диде. Соңыннан зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнлегенә игътибар итте һәм Гарәфә көнендәге уразага: «Үткән һәм киләчәк ел гөнаһларының кичерелүенә сәбәп», – дип кызыктырды. Һәм, ниһаять, яңа ел кергәч: «Мөхәррам – Аллаһының ае», – дип, ураза тотарга өндәде.

Хөрмәтле җәмәгать! Ураза тотуның бәрәкәте бар: «Их, менә шушы ризыкны ашар идем», – дип кызыксаң да, нәфесеңне кулга алып, аның

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

өстендә хуҗа буласың, аны тәрбиялисең. Шуңа күрә дә Әбү Өмәмә, Пәйгамбәребез янына килеп: «Йә Аллаһының Расүле! Миңа бик күп файда китерә торган гамәлгә өйрәт», – дип сорагач, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ураза тот, чөнки аның тиңдәше юк», – дип җавап кайтарды. Әйе, ураза биргән тәрбияне бер гыйбадәт тә бирә алмый.

Бөек Аллаһы елны ике харам булган зөлкагъдә белән зөлхиҗҗә айлары белән тәмамлый һәм ул айларда безне: «Сак булыгыз! Золымлык кылмагыз! Тәкъва булыгыз! Изгелек эшләгез!» – дип кисәтә. Яңа елның беренче булган мөхәррам ае килде һәм шулай ук безне кисәтә. Елны изгелек белән озаттык һәм елны изгелек белән каршы алабыз. Бу хакта Ибне Раҗәб исемле галим болай дип язган: «Берәү зөлхиҗҗә аеның уразасын тотып, аннары мөхәррам аеның уразасын тотса, ул үзенең елын изгелек белән тәмамлап, яңа елын изгелек белән башлаучы булыр. Бәлки бөтен елы да изгелек итеп язылыр. Берәүнең гамәленең башы итагать белән башланып, ахыры итагать белән тәмамланса, аның шушы ике гамәленең арасы да итагать кебек булыр».

Аллаһы үткән елыбызда эшләгән хата-кимчелекләребезне гафу итсен. Тоткан уразаларыбызны, чалган корбаннарыбызны, кылган хаҗларыбызны кабул кылсын. Һәм киләсе елны изге гамәлләр белән каршылап, ел дәверендә изгелек кылучылардан итсен.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт

итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Әлмәт шәһәренең 1нче мәхаллә имам-хатыйбы*

*5 нче август вәгазе,*

*мөхәррам аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Гашурә көне хакында

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә каршында хөрмәтле булган мөхәррам аена килеп кердек. Бу ай – Аллаһы ае. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә китерелгәнчә, мөхәррам ае – һиҗри исәбе буенча беренче ай. Бөек галим Хәсән Әл-Басри: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә һиҗри елны мөхәррам ае белән башлап җибәрә. Һәм Аллаһы Тәгалә каршында Рамазан аеннан кала хәерлерәк булган башка ай юктыр», – дигән.

Фикерләп карасак, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдән Мәдинә шәһәренә күчеп китүенә, һиҗрәт кылуына да 1400дән артык ел узган. Бу бит 100 дә, 200 дә, 1000 ел гына да түгел, ә шушы бөек вакыйгага унбиш гасырга якын вакыт үткән. Моңа да карамастан, Раббыбыз ислам динен саклаган. Шушы вакыт эчендә күпме вакыйгалар булып узган, мөселманнар тарихында күпме сынаулар, ничәмә-ничә кан кою очраклары булган, җиңүләр килгән. Гәрчә имансызлар тарафыннан Коръәнне үзгәртергә күпме форсат кылынган булса да, Раббыбыз Үзенең китабы Коръәни Кәримне безнең көннәргә кадәр бернинди арттырусыз һәм киметүсез ирештергән. Аларның күп тапкырлар шушы сүзләрне бозарга тырышуы мәгълүм. Әмма Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримне үзгәреш кертүләрдән саклап калган.

1400 дән артык ел – Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һиҗрәт кылуыннан күпме вакыт узган дигән сүз. Уйлаган, фикерләгән кеше өчен монда гыйбрәт, дәресләр бар. Нинди бөек, олуг булган тарих!

Мөхәррам ае һиҗри елның беренче ае гына түгел, ул Аллаһы Тәгалә хөрмәтләгән харам ай да. Коръәни Кәримдә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – унике. Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимуссәламнән калган] хак дин. [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез»,** – диелгән.

«Әт-Тәүбә», 9:36

Аллаһы Расүле үзенең хәдисендә: «Ел унике айдан тора, шуның дүртесе – харам айлары, ягъни сугышлар, ызгышлар тыелган айлар. Харам айларының өчесе – рәттән килә торган айлар, ягъни зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам. Раҗәб – тагын бер харам кылынган ай. Ул җөмәдәл-ахыр белән шәгъбан ае арасында килә», – дигән. Мөселман календарендәге айлар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманыннан ук килә. Без гыйнвар, февраль, март айларын санап биргән кебек, мөхәррам, сафәр, рабигыль-әүвәл, рабигыль-ахыр, җөмәдәл-әүвәл, җөмәдәл-ахыр, раҗәб, шәгъбән, Рамазан, шәүвәл, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә кебек һиҗри ай атамаларын да белергә тиеш.

Коръәни Кәримдә «шушы айларда золым кылмагыз», – дип әйтелүе башка айларда да гөнаһ эшләү – куркыныч нәрсә, әмма бу айларда гөнаһ кылу тагын да куркынычрак, бу – харам айлар, Аллаһы Тәгалә олылаган, зурлаган айлар булып тора, дигәнне белдерә.

Госман Әл-Һинди дигән бер галим: «Алар, безгә кадәр килгән сәләфләр, өч айның ун көнен олылый торган булганнар: Рамазан аеның соңгы ун көнен һәм төнен, чөнки анда Кадер киче яшерелгән; зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнен, чөнки анда хаҗ, гает, Гарәфә кебек бөек көннәр бар; мөхәррам аеның беренче ун көнен, чөнки аңа Гашурә көне, ураза тоту көннәре кергән», – дигән.

Мөхәррам ае үзенчәлеге – ул ураза тоту. Имам Әл-Мөслим хәдис җыентыгында расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләре китерелгән: «Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә каршында Рамазан аеннан кала, ураза тотар өчен, иң хәерле ай – ул мөхәррам ае». Имам Әс-Суюти болай дип әйтә торган булган: «Бервакыт миннән: «Ни өчен пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөхәррам аен аерып, Аллаһы ае дип атады?» – дип сорадылар. Бу сорауга җавап эзли торгач, шундый аңлатма таптым: мөхәррам аена шушы исемне бирүче – ул Аллаһы Тәгалә Үзе, ә башка айларның исемнәре җәһилият заманнарыннан ук билгеле булган. Мөхәррәм аен элек «сәфәрүл-әүвәл» дип йөрткәннәр. Аллаһы Расүле ислам дине белән килгәннән соң, бу айны мөхәррамга үзгәрткән һәм «Аллаһы ае» дип атаган».

Мөэмин-мөселманнар әлеге айда изгелекләр кылырга, бигрәк тә ураза тотарга тырышырга тиеш. Ләкин ай буе ураза тоту кирәкми, чөнки Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазаннан кала бер айда да ай буе ураза тотмаган. Мөхәррамда, мөмкинлегеңә карап, күбрәк көннәрне уразада үткәрү бик файдалы һәм саваплы булачак. Кемнең дә булса көче җитми икән, һичьюгы Гашурә көнендә ураза тотсын.

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гашурә көнендә тотылган бер көн ураза сәбәпле, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бер ел дәвамында кылынган гөнаһларны кичерер дип өметләнәм», – дигән. Ягъни бер көн тотылган ураза сәбәпле, бер еллык гөнаһлар гафу ителер. Һәм галимнәр Аллаһы Расүленең «өметләнәм» дигән сүзе «шулай булачак» дигәнгә бәрабәр, дип бәян итә.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән китерелә торган хәдистән билгеле булганча, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә күчкәч, яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотканын күреп, «Нәрсә бу?» – дип сораган. Аңа: «Бу – изге булган көн. Әлеге көнне Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Исраил уллары кавемен дошманнарыннан һәм фиргавеннән коткарды. Һәм шуңа хөрмәт йөзеннән, Муса галәйһиссәләм ураза тотты», – дигәннәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Муса галәйһиссәләмгә минем хакым зуррак», – дигән һәм үзе дә ураза тоткан, башкаларны да бу гамәлгә өндәгән. Сәхабәләр: «Йә, Расүлуллаһ, бу көн – яһүдиләр олылый торган көн», – дип килеп әйткәч, Аллаһы Расүле: «Киләсе елда мин мөхәррам аеның тугызында да ураза тотачакмын», – дигән. Шуңа да ике көн, өч көн ураза тотуның савабы бик күп. Мөмкинлегегез, сәламәтлегегез бар икән, Рамазан аенда ураза тотканны, берничә көнгә уразага керергә, иншәАллаһ, көчебез җитәчәк.

Шуны да онытмаска кирәк: Гашурә көнендә тотылган ураза бер еллык гөнаһларны ярлыкый, әмма бу ярлыкау кечкенә гөнаһлар өчен генә. Зур гөнаһлар Гашурә көне белән генә кичерелми. Без беркайчан да үзебезнең яхшылыкларны санап горурланырга тиеш түгел. Бер көн ураза тотам да, бер еллык гөнаһларым кичерелә дип, үзебезнең изгелекләр белән масаерга ярамый. Яхшылыкларыбызны санаганчы, гөнаһларыбызны исәплик, чөнки әлеге ел эчендә күпме гайбәт сөйләнгән, күпме ярамый торган нәрсәләр каралган, тыңланган, аларда катнашылган... Шуларны саныйк та, кылган изгелекләребез сәбәпле Аллаһы Тәгалә гөнаһларыбызны ки-

черер дип өметләник. Үз-үзебезгә 100% гарантия биреп, мин бу дөньяда гөнаһсыз килеш атлап йөрим, дип масаймыйк, гөнаһларыбызны уйлыйк!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», - дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әмир хәзрәт Усманов,*

*Әлмәт районы Түбән Мактама авылы имам-хатыйбы*

*12 нче август вәгазе,*

*мөхәррам аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Мөселманнар өчен хәзерге заман казанышлары

Галәмнәрне юктан бар итеп, безләрне халык кылып, бүгенге көнгәчә тәрбияләп, ризыкландырып һәм киендереп торучы Аллаһыга барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак Расүле, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифләрен бирсә иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, кеше бу дөньяга китерелгәннән бирле төрле заманнарда яшәде. Башта таш гасыр булса, аннан бронза, тимер, антик гасырлар булды. Соңрак бөек фәнни-техник ачышлар заманы булса, бүген без мәгълүмат заманында яшибез. Бүгенге көнебездән 100 елга гына үткәннәргә кайтып карасак та, гаять зур аерма күрәбез. Бүген безнең өйдә робот тузан суырткыч идәнне юа, керле киемнәрне автомат машина юып киптереп чыгара, бездән 100 чакрым ераклыкта булган өйнең температурасын телефон аркылы көйлибез, бүген утырып йөри торган машиналар, кешеләрне, машиналарны танып, каршына килеп чыкса, туктап кала, яки бөтенләй автопилотта йөри. Бүген без дөньяның төрле почмакларыннан бер мизгел эчендә мәгълүмат алабыз, бөтен яңалыктан хәбәрдар булып торабыз. Бүген Җир шарының теге ягында, океан уртасында торып, авылдагы әниләр белән йөзгә-йөз карап сөйләшәбез, һәм, гомумән, күп төрле әйберләр безнең өчен гадәти хәлгә әйләнде. Шушы күптөрле файдалы ачышлар арасында безнең өчен бик мөһим булганы – телефон, интернет челтәре. Һәр туачак көнне шуның белән башлыйбыз,

көнне шуның белән төгәллибез. Кайберләребезнең төне дә шуның белән үтә. Ул гел безнең янда. Үзе телефон, телевизор, газета, видеокамера, китап, хәдисләр җыентыгы, Коръән һәм бик күп вазифаларны үз эченә алган безнең смартфоннар уч төбе кадәр генә.

Бүгенге сүзем дә безнең өчен тагын бер гадәти әйбергә әйләнгән шушы смартфоннар аркылы эшли торган, бүгенге көннең тагын бер казанышы булган иҗтимагый челтәрләр[1], алардан килгән файда һәм зарар турында бара. Алар безнең тормышыбызга үтеп, безнең көнебезнең шактый вакытын алып тора. Шулар ярдәмендә кешеләргә ниндидер үрнәк гамәл яки яхшылыкка өндәү яисә дингә чакыру кебек хәерле гамәлләрне меңләгән, миллионлаган кешегә җиткерергә, күрсәтергә була. Безнең мәчетләребездә җомга вәгазьләрен, галимнәребезнең төрле темаларга багышланган дәресләрен бик күп кешеләрнең өйдән чыкмыйча карый алулары, әлбәттә, хәерледер. Бигрәктә бүгенге көн вәзгыятен күз алдында тотканда. Шул ук вакытта бозык гамәл яки ярамаган сүз яисә диннән тайпылу гамәлләрен дә шул ук иҗтимагый челтәрләр аркылы меңләгән кешегә җиткерергә була.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

وَلَيَحْمِلُنَّ أَثْقَالَهُمْ وَأَثْقَالًا مَّعَ أَثْقَالِهِمْ ۖ

> **«Алар үзләренең авыр йөкләрен дә, үзләренең авыр йөкләре белән [адашуына сәбәп булган кешеләрнеке булган] авыр йөкләрне дә өсләренә алачаклар»,** – дип әйтә.

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:13

Безгә атап әйтелмәгән булса да, бу сүзләр безнең өчен дә бер кисәтү булырга тиеш. Бу урында күбебездә сорау туа, чөнки башка урында Аллаһы Тәгалә: «Бер кеше дә икенче кешенең гөнаһысы өчен җавап бирмиячәк», – дип әйтә. Моны аңлатырга бик җиңел: әгәр кеше

[1] Социаль челтәрләр.

үзе шул гөнаһ белән бәйле булмаса, ягъни үзе шул гөнаһны эшләүгә сәбәпче булмаса, ул бер кешенең дә гөнаһысы өчен җавап бирми. Шуңа күрә, җәмәгать, безнең кулыбыздагы бу коралларны бик тә саклык белән кулланырга тиеш. Медаль ике яклы булган кебек, бүгенге заман казанышларының да яхшы ягы да, начары да бар. Галимнәр: «Кулыңдагы телефонны хәрби граната тоткан кебек саклык белән тотыгыз», – диләр. Ни өчен? Чөнки бу телефон яки компьютер аркылы бер ялгыш гөнаһ гамәлең меңләгән кешегә таралып, кешеләр дә бу гамәлне кылучылардан булса, син үзеңне харап иткән буласың. Бүгенге көндә күпме атаклы кешеләрнең бер ялгыш гамәлләре аркасында тормышлары җимерелә, гаиләләре таркала. Әгәр дә сез: «Монда яздым, бер кеше белмәде, теге сайтка кереп, үземә күчереп алдым, беркем белмәде, теге кешегә фото җибәрдем, башкалар белмәде», – дип уйлыйсыз икән – ялгышасыз. Яңа яуган ак кардан барган эзне икенче яуган кар күмә, диңгез кырыеннан барганда комда калган эзләрегезне шул диңгез дулкыны юа, ә менә берәр тыелган сайтка кереп, ярамаган әйберләр карадыгыз, берәр мәкаләгә шәрех калдырдыгыз икән – боларның барысыннан да «цифрлы эз» калачак.

Кешенең качып гөнаһ кылуы бер бәла булса, шул гөнаһын ачык, күрсәтеп кылуы – мең бәла. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен риваять иткән: «Минем өммәтемнән гөнаһларын күрсәтеп кылучылардан кала башкалары кичерелер. Димәк, гөнаһысын күрсәтеп кылучылар кичерелми. Ничек була ул диючеләргә, менә мондый мисал китерик: менә бер кеше төнлә белән гөнаһ кылды һәм аны беркем дә күрмәде, Аллаһы рәхмәте белән ул гөнаһны яшерде, бер кешегә дә күрсәтмәде, ди. Ләкин кеше иртә белән чыгып: «Әй, фәлән, мин төнлә белән шуны эшләдем әле», – дип, Аллаһы яшергән гөнаһын кешеләргә җиткерсә,

менә бу кичерелмәс», – дигән[1]. Шуңа күрә бүгенге заман казанышлары аркасында бөтен дөнья бер авыл рәвешендә. Кайбер сәхабәләрнең дүшәмбе, пәнҗешәмбе тоткан уразаларын хатыннары да белмәгән. Ә бүген кеше атнага бер тапкыр намазга басса, җомгага барса, аны бөтен «язылучылары» белеп торсыннар дип, иҗтимагый челтәргә куя һәм үзенә игътибар бирүләренә өметләнә. Имам белән фотога төшеп, аны шул челтәрләргә куймасалар, җомгалары җомгадан китми, дип уйлыйлардыр. Менә без бүген нинди хәлдә! Мөселманнар гомер буе гөнаһ кылса, яшерә торган булган. Ә бүген без – мөселманнар гөнаһны күрсәтәбез, моннан оялмыйбыз. Әле күптән түгел бер мөселман кардәшебезнең башка милләттән булган такси йөртүче егетне алдавын ютубтан гына 14 млн.га якын кеше карады. Бу эш болай була: безнең кардәшебез ике дусты белән такси туктата, юлда бик матур сөйләшеп, барасы җирләренә барып җиткәч, бу кардәшнең акчасы булмавы ачыклана һәм ул: «Мин сиңа картага күчерергә вәгъдә итәм», – дип, такси йөртүче егетнең карта номерын алып чыгып китә һәм югала. Күз алдына китерегез, мөселманнар гаиләсен, балаларын ашатырга, бераз акча эшләргә, дип юлга чыккан башка милләт кешесен, биргән вәгъдәләрен бозып, алдалап калдыра гына түгел, ә шуның белән мактанып, шуны сөйләп йөри. Менә мөселманнар нинди дип, бу турыда кем генә сөйләмәде һәм каян гына күрсәтмәделәр. Бер гамәл бөтен мөселман өммәтенә нинди зур зыян китерә.

Әбү Һөрайра Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итеп, болай дип әйтә: «Мөнафикъны өч билге аерып тора: сөйләгәндә ялганлый, вәгъдә бирсә, вәгъдәсен боза, аңа ышаныч белдергәндә, ул аны акламый»[2].

---

1 Имам Әл-Бохари, (6069), Әл-Мөслим, (2990) хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әл-Бохари һәм Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Карагыз, ничек төгәл туры килә безнең холык бу мәсьәләгә. Ялганлады, биргән вәгъдәсен бозды һәм үзенә күрсәткән ышанычны бозып, шуның белән мактанып, бөтен өммәткә тап төшерде.

Әлхәмдүлилләһ, шул милләттән булган мөселман кардәшләр бу егетне табып, акчасын берничә мәртәбә арттырып түлиләр, егет үзе дә мөселманнарның бу хәлләрдән кырыйда калмавы һәм ярдәм итүләре хакында әйтә.

Ә менә икенче очрак: гарәп милләтеннән булган бер ир кеше атка атланып, чүл буйлап гаиләсе янына кайтып барганда чүлдә хәлсезләнгән, ярдәм сораучы кешене күрә. Чүлдә атсыз, сусыз, ризыксыз һәм хәле беткән кешене күз алдыгызга китерегез. Бу – үлемгә дучар булуга тиң. Әлеге гарәп тизрәк атыннан төшеп, бу кеше янына килә, күтәреп атына утыртканда, тегесе аны тибеп җибәрә дә, атын урлап китеп бара. Ул карак булып чыга. Атсыз, ризыксыз бу кешенең язмышы чүл уртасында хәл ителгән, дигән сүз. Карак китә башлагач, бу ир кычкырып, аны үзенә чакырып китерә һәм: «Монда үләр алдыннан, зинһар, бер үтенечемне үтә», – дип әйтә. Теге карак: «Нинди үтенеч? Әйдә, әйтеп кара», – ди. Яхшылык эшлим дип алданган, үләсе кешенең соңгы үтенече мондый була: «Зинһар, Аллаһы ризалыгы өчен, минем белән нәрсә эшләгәнеңне беркемгә дә сөйләмә». Карак гаҗәпләнеп: «Сиңа хәзер барыбер түгелмени, син барыбер үләсең бит», – ди. Әмма ярдәм иткән кеше: «Син бу хәлне сөйләгәннән соң, минем халкым башкаларга ярдәм итүдән туктар, дип куркам», – дип әйтә. Карагыз, бу кеше каракка әлеге гөнаһы турында сөйләмәскә куша. Ул үзе турында кайгыртамы? Юк. Ул бу гамәл халыкка таралгач, ахыры нинди булуы турында борчыла: «Ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә минем халкым ярдәм итүдән туктар дип куркам», – ди. Шуңа күрә, җәмәгать, безнең кулыбызда булган бүгенге көн казанышларының нинди көчкә ия булып, безне һәлакәткә китерә алулары турында онытмыйк. Безнең кавем өчен бу

– зур сынау. Әгәр дә без, Аллаһы Тәгалә безнең кулларга тоттырган бу коралларны дөрес итеп, дөрес юлда куллансак, бу безнең өчен хәерле булачак. Әгәр дә инде бозык юлда, гөнаһ гамәлләрне күрсәтү һәм тарату өчен куллансак, моның ахыры аянычлы булыр. Нәрсәдер әйтер, нидер игълан итү алдыннан ахыры нинди буласын уйлыйк.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Вафин Ильнур,*

*«Оста вәгазьче» бәйгесе җиңүчесе*

*19 нчы август вәгазе,*

*мөхәррам аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Заман һәм мөселман гаиләсе

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык кылып, бүгенге көнгәчә тәрбияләп, ризыкландырып, киендереп торучы Аллаһыга барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак Расүле, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифләрен бирсә иде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Адәм белән Хавваны, бер-берсендә юаныч, тынычлык, тормыш шатлыгы һәм бәхет тапсыннар өчен, җәннәттә берләштерде. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

هُنَّ لِبَاسٌ لَّكُمْ وَأَنتُمْ لِبَاسٌ لَّهُنَّ

**«Алар – сезгә кием һәм сез – аларга кием»[1].**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:187

Нәрсә соң ул бәхетле гаилә? Башта бәхет төшенчәсен карап үтик.

Халыкара сораштыру вакытында төрле яшьтәге һәм төрле илдән булган уналты мең кешедән: «Бәхетне нәрсәдә күрәсез?» – дип сораганнар. Шушы 16 меңнең 36% ы – мәхәббәттә, 29% ы – дөньяның рәхәтен тоеп яшәүдә, 18% ы – сәламәтлектә, 7% ы – гаиләдә, 5% ы – малда, дип җавап

[1] Кайбер галимнәрнең фикере буенча, бу сүзләр гөнаһлы гамәлләрдән кием, пәрдә, дигәнне аңлата, ягъни хатын-кыз – ирен, ә ир-ат хатынын гөнаһлы гамәлләрдән саклый. Шулай ук ир-ат хатынының, хатын-кыз иренең хата-кимчелекләрен, гөнаһларын башкаларга сөйләп йөрми. Галимнәрнең кайберләре моны, хатын-кыз ире өчен, ә ир-ат хатыны өчен тынычлык булып тора, дип әйтә. Бу – ир-ат хатынында, хатын-кыз ирендә тынычлык таба, дигәнне белдерә. Икенче бер аятьтә: «Аллаһы – сезгә [ял итеп] тынычлык табуыгыз өчен төнне [караңгылык итеп] Яратучы», – диелгән. Башка галимнәр, бу сүзләр ир белән хатын төннәрен бер-берләренә кием дигәнне аңлата, ди. Аллаһы яхшырак белүче.

биргән. Әгәр дә дөньяда 36% кеше мәхәббәтен югалтса, ә 29% ы дөньяның рәхәтен тапмыйча яшәсә – бәхетсез була икән... Әмма һәр мөселман кешесе түбәндәге төшенчәне белергә тиеш: җан белән Аллаһы арасында булган элемтәнең якын булуыннан да зур бәхет юк. Шушы якынлыкны сизеп яшәгән кешедән дә бәхетле кеше юк.

Галимнәр һәрбер яңа әйберне хис итү, иң күбе 90 көнгә бара, дип әйтә. Мәсәлән, яңа кием, машина, фатир алгач бик куансак та, бу хис 90 көннән соң гадәти әйбергә әйләнә. Еллар буе йорт салсак та, 90 көннән соң ул гадәти йорт кына булып калачак. Яңа өйләнгән егет белән кызның да шушы хисләре бары өч ай булырга мөмкин, ә аннан соң алар да гадәти тормыш белән яши башлый. Кызганычка, менә шушы чорда: «Элеккеге хисләр бетте», – дип аерылыша башлыйлар.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Адәм балаларына дөньяда ләззәтләнүнең вакытын кыскарткан, әмма җәннәттә шушы хис мәңге булачак. Бу дөньяда мал да, алданмас өчен, күзгә күренми. Бу безнең төп максатыбыз түгел, әгәр дә Аллаһы белән элемтәбез булса, шушы хисебез мәңге булыр.

Җәмәгать, шушы хисне булдырып һәм саклап тору өчен, бик зур тырышлык куярга кирәк, моның юлларын күбебез белә. Мәсәлән, фарыз гамәлләрне үтәү: намаз, ураза, хаҗ, зәкят һ.б. Күп мөселманнар фарыз белән генә чикләнә, әмма, Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәтенә лаек булу өчен, нәфел гамәлләргә дә кучәргә кирәк. Димәк, икенчесе – нәфел гамәлләр. Өченчесе – зикер. Дүртенчесе – Коръән уку. Бишенчесе – изге гамәлләр кылу. Соңгысы – тәүбә итү.

Болар барысы да – сынау, чөнки җәннәт болай гына бирелми, аның бәясе бик кыйммәт. Шушы кагыйдә ирләргә дә, хатыннарга да кагыла. Җәмәгать, яхшы йорт салыр өчен, күпме көч, күпме байлык сарыф итәргә кирәк. Әле бу дөньядагы йорт өчен генә, ә җәннәттәге йортыбыз өчен күпме тырышасыбыз бар? Андагы йортның бүлмәләрен карап һәм

әйләнеп үтәр өчен генә дә, ике ел вакыт – 700 көн кирәк. Күз алдыгызга китерегез: Аллаһы Тәгалә нинди зур йортлар, сарайлар әзерләгән.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәндә ике җанның җәннәттәге әңгәмәсен тасвирлаган:

قَالَ قَائِلٌ مِّنْهُمْ إِنِّي كَانَ لِي قَرِينٌ ﴿٥١﴾ يَقُولُ أَإِنَّكَ لَمِنَ الْمُصَدِّقِينَ
﴿٥٢﴾ أَإِذَا مِتْنَا وَكُنَّا تُرَابًا وَعِظَامًا أَإِنَّا لَمَدِينُونَ ﴿٥٣﴾ قَالَ هَلْ أَنتُم
مُّطَّلِعُونَ ﴿٥٤﴾ فَاطَّلَعَ فَرَآهُ فِي سَوَاءِ الْجَحِيمِ ﴿٥٥﴾ قَالَ تَاللَّهِ إِن كِدتَّ
لَتُرْدِينِ ﴿٥٦﴾ وَلَوْلَا نِعْمَةُ رَبِّي لَكُنتُ مِنَ الْمُحْضَرِينَ ﴿٥٧﴾ أَفَمَا نَحْنُ
بِمَيِّتِينَ ﴿٥٨﴾ إِلَّا مَوْتَتَنَا الْأُولَىٰ وَمَا نَحْنُ بِمُعَذَّبِينَ ﴿٥٩﴾ إِنَّ هَٰذَا لَهُوَ
الْفَوْزُ الْعَظِيمُ ﴿٦٠﴾ لِمِثْلِ هَٰذَا فَلْيَعْمَلِ الْعَامِلُونَ ﴿٦١﴾

**«Араларыннан берсе әйтте: «Минем [терелүне инкяр иткән] иптәшем бар иде. [Мин аңа нәсыйхәт биргән чагымда] Ул [миңа] әйтте: «Син дә [үлгәннән соң терелүне] раслаучыларданмы әллә? Үлгәнебездән соң туфрак һәм [черегән] сөякләргә әверелгәч, җәзаландырылачакбызмы әллә?» [Ул зат җәннәттәге иптәшләренә кяфер иптәшенең сүзен әйткәннән соң] Әйтте: «Карамыйсызмы [ул җәһәннәм әһеленә]? [Югарыдан аның хәлен күрсәтим дә, үзегезнең урыныгызның кадерен белегез]». [Җәннәт белән җәһәннәм арасындагы пәрдә ачылып] Карады да, аны Ут уртасында күрде. Әйтте: «Аллаһы белән ант итәм, син мине [инкярга һәм гөнаһларга өндәп] һәлак итә яздың. Раббымның мәрхәмәте булмаса, [хәзер] мин дә [синең белән бергә җәһәннәмгә] китерелгәннәрдән булыр идем. [Ул һәм аның иптәшләре үзләренә насыйп булган олы нигъмәтләргә сөенү билгесе итеп әйтерләр:] Без бүтән үлмәбезме әллә? Беренче**

**үлемебездән тыш. Без беркайчан да җәзаландырылмабызмы инде? Һичшиксез, бу – зур котылуның үзе. Тырышучылар моның кебек [чиксез] бернәрсә өчен гамәл кылсын».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:51-61

Гаиләдәге яхшы мөнәсәбәтне төзү өчен, һәр кеше, беренче очракта, үзе тәрбияле, иманлы һәм сабыр булырга тиеш. Коръәни Кәримдә болай диелгән:

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ وَأَنتُمْ تَتْلُونَ الْكِتَابَ ۚ أَفَلَا تَعْقِلُونَ

**«Әллә сез кешеләргә игелек әмер ителә торып та, үз-үзләрегезне онытасызмы? Сез бит китап укыйсыз! Һаман акылга утырмыйсызмы?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Бу аять вәгазь сөйләп тә, сөйләгән белән гамәл кылмаучылар хакындадыр. Коръән безгә башта кимчелекне үзебездән эзләп, аннары аның өстендә эшләргә куша.

Җәмәгать, үз өстендә эшли белмәгән, бәхетсез булган кеше гаиләдә тормыш иптәше белән яхшы, җылы һәм нык мөнәсәбәт булдыра алмый! Шуңа күрә ир-атның гаиләдәге беренче бурычы – үз өстендә эшләү, гаиләсенә үрнәк булу. Икенче бурыч – гаиләсен Ислам диненә өндәү һәм өйрәтү. Өченчесе – гаиләсен гөнаһлардан саклау. Кыз бала кияүгә чыкканчы, Аллаһы һәм өммәт каршында аның өчен әтисе җаваплы, кияүгә чыккач, җаваплылык – ир кешедә. Дүртенчесе – гаиләсен матди яктан тәэмин итү. Мөселман булган ир-ат үзенең хатынына: «Мин сине тәэмин иттем, акча бирдем», – дип, тел-теш тидерергә тиеш түгел, чөнки әле аның алдында өч төрле бурычы бар.

Хатын-кызның ире алдында ике зур вәҗиб булган бурычы бар: үзенең тормышын иренең иминлеге өчен төзү. Икенчесе – балаларына

яхшы әни булу. Беренче бурыч хакында хәдис китерик: «Хатын-кыз үлсә һәм ире аннан канәгать булса, әлбәттә, бу хатын җәннәтле булыр»[1]. Шуңа күрә хатын-кызның алдында ирен канәгатьләндерү бурычы бар.

Икенче хәдис: «Дөреслектә, Аллаһы үзенең иренә рәхмәтле булмаган хатын-кызга карамас. Биш вакыт намазын укып, сафлыгын саклап, иренә буйсына икән, бу хатын үзе теләгән җәннәт капкасыннан керер»[2].

Әлбәттә, Кыямәт көнендә һәрберебез җәннәтле буласы килер, ләкин җәннәткә лаек булырбыз микән? Шәйтан – ул дошман, аның вәсвәсәсеннән сакланыр өчен, иман, тәкъвалык һәм гыйлем кирәк. Кайвакыт хәзерге заман гаиләсенә шушы гыйлем, иртә белән өстәл артында вәгазьләнү җитмидер. Иртәнге ашта акча, мөнәсәбәтләр хакында сөйләнә... Әлеге Коръән аятләре ир белән хатынга җибәрелмичә, кем өчен җибәрелсен ди?!

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кылган гамәлләр белән беркем дә җәннәтле була алмый, Аллаһының рәхмәте белән генә җәннәтле була алабыз», – дигән. Раббыбыз Үзенең Рәхмәтенә ирешүләребезне насыйп итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Лотфуллин Ислам,*

*«Оста вәгазьче» бәйгесе җиңүчесе*

*26 нчы август вәгазе,*
*мөхәррам аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Дөньялар тыныч булсын

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Бүгенге көндә, дөньялар тыныч булсын, дигән сүз барлык кешегә дә бертөрле тәэсир ясамыйдыр. Әби-бабайларыбыз бу сүзләрне ишеткәч, авыр сулап куеп, әәмин, дип куялар. Алар, билгеле, авыр замандагы вакыйгаларны искә ала һәм ул вакытларның кабатланмавын, шул заманның авыр көннәренең, мизгелләренең дә бу тормышка әйләнеп кайтмавын тели. Бу вакыйгаларны тарих китаплары битләреннән генә өйрәнгән яшьрәк буын, бәлки, башкачарак кабул итәдер. Ничек кенә булмасын, мондый теләктән соң, киресе булсын, дигән бер генә кеше дә юктыр. Әмма дөньяның тыныч булуы кемнән тора соң? Һәм, гомумән, ул нәрсәне аңлата?

Дөньяны киң мәгънәсендә караганда, ул, әлбәттә, барлык җир шары, илләр, алар эчендәге, арасындагы булган вакыйгалар, хәлләр. Анысы безнең өчен бер дәрес, гыйбрәт булып кына тора, һәм, әлбәттә, без бу очракта кулларыбызны догага күтәреп, шул әби-бабайларыбыз кебек иминлек сорыйбыз, әәмин, дип әйтәбез.

Әмма дөньяның таррак мәгънәсе бар. Илнең башлангычы кайда, дигән сорауны еш ишетергә туры килә. Һәм гадәттә: «Ил – безнең туган өйдән, әти-әнидән, күрше-күләннән, авылдан, шәһәрдән башалана», –

дип әйтәләр. Телевидение-радио аша ничәмә-ничә җинаять кылына дип сөйләп торалар. Бу тынычлыкмы? Күрше-күләндә генә түгел, үзебезнең өйләребездә дә юктан да тавыш чыга, савыт-саба чыңгылдап куя. Бу тынычлыкмы? Юлларда йөргәндә күпме кешенең игътибарсызлыгы аркасында, яки аек акылда булмаганнары сәбәпле ничәмә-ничә юл һәлакәтләре була. Боларның барысының да башы кайда соң, дип сорасагыз, җавабы: без – үзебез. Мәктәпләрдә «Үскәч кем буласым килә» дигән темага иншалар яздыра иделәр, әле дә бәлки шулайдыр. Без дә яздык: беребез – шофер, беребез – табиб, беребез – банк хезмәткәре, беребез – язучы булырбыз, дип хыялландык. Әмма бер генә кеше дә «мин җинаятьче, мин карак, мин хатынымны кыйнаучы булырмын» дип язмады бит!

Һади Такташ әйтмешли:

*«Егет чакта бар да матур була,*
*Кайдан чыга*
*Хатын кыйный торган батырлар».*

Әйдәгез, кадерле җәмәгать, бераз гына бу тынычсызлыкларның сәбәпләрен дә карап китик.

Беренчедән, моның сәбәбе – гөнаһларыбыз. Бер әйбер дә эссез югалмый, дип әйтергә яраталар. Кадерле дусларым, туганнарым, гөнаһлар – бигрәк тә эзсез югалмый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм күп тапкырлар: «Безгә килгән бәла-казаларның сәбәбе – үзебез аркасында», – дип әйтеп калдырды, безне кисәтте. Кеше бер гөнаһ кылыр, артыннан тагын берне, аннары тагын берне... Һәм үзе дә сизмәстән, Аллаһы Тәгаләнең әйткән сүзләре астына эләгер. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

كَلَّاۖ بَلْۜ رَانَ عَلَىٰ قُلُوبِهِم مَّا كَانُوا يَكْسِبُونَ ﴿١٤﴾

**«Юк! [Бу бозык бәндәнең сүзе һич дөрес түгел!] Кылган [начар] нәрсәләре [һәм рәттән эшләгән гөнаһлары] аларның йөрәкләрен [мәгънәви бер] тутык белән каплаган».**

«Әл-Мутаффифин / Киметеп үлчәүчеләр», 83:14

Галимнәребез гөнаһлар кылу аркасында, беренчедән, кешенең күңеле карала, икенчедән, бәрәкәт китә, дип әйттеләр. Чыннан да, берәр төрле гөнаһ кылсак, безнең йөрәкләребез Аллаһы Тәгалә, әти-әни, яхшылык, үлем, Ахирәт, хәйриячелек кебек әйберләр турында уйлар урынына, башка нәрсә белән капланачак. Ә инде без гел изгелектә йөрсәк, зикер, мәчет, намаз, ураза әһеле булсак, йөрәкләребез дә, Аллаһы Тәгалә аятьтә әйткәнчә, шул күркәм гамәлләр белән капланачак. Киресенчә булганда, бер гөнаһ икенче гөнаһны чакырып китерәчәк, һәм шулай бер-бер артлы гөнаһлар кылынып, бик авыр нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Игелекне дә көчебезгә карап кылган кебек, начарлыкны да көчебезгә карап кылабыз бит. Кемдер садака итеп бары ун сум гына бирә ала, ә кемгәдер мең сум бирү дә кыенлык китерми. Шуның кебек, мөмкинлекләре азрак булган кеше, бәлки азрак гөнаһ кыладыр, әмма шул ук кешегә юлларын ачсаң, ул кешене зур гөнаһлар кыла башламас, дип кем әйтмәс?! Юрган озынайса, аяк та сузыла бит. Бер тапкыр сүз тыңламаган балага: «Әйдә, ул кечкенә бит әле», – дип салкын карап, болай гына калдырырга ярамый. Гөнаһ кечкенә яки зур булса да – барыбер гөнаһ бит! Кечкенәдән башкаларны хөрмәт итәргә ияләшмәгән бала, балалар бакчасында тәрбиячесенә, мәктәптә укытучысына, ә инде үсеп буйга җиткәч, Аллаһы сакласын, әти-әнисенә, олыларга, мескеннәргә дә каршы барачак. Шуңа, кадерле җәмәгать, гаиләбездә, эшебездә, илебездә гел тынычлык булсын дип әйтсәк, гөнаһлардан ерак торыйк, тәүбә кылыйк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللَّهِ تَوْبَةً نَّصُوحًا

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга ихлас бер тәүбә белән тәүбә итегез».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:12

Икенчедән, Аллаһы Тәгалә кушканнарга игътибарлы булу. Аллаһыга шөкер, намаз укучылар, ураза тотучылар күп. Әмма, барлык намаз укучылар да үрнәк мөселманмы? Барлык ураза тотучылар да нәфесләрен йөгәндә тотамы? Дөреслектә, һәрбер изге гамәл безне Аллаһыга якынайтырга, ә, димәк, гөнаһлардан ерагайтырга тиеш. Бу үзенә күрә бер кагыйдә дип карасак, намаз укып та, фәхешлектән, начарлыктан ерагаймасак, димәк, намазыбызда хилафлык булырга мөмкин. Безнең күңелләребез караңгы булып, ураза тотып ашказаныбыз чистарудан, намаз укып тәннәребез физик күнегүләр ясаудан гына ни мәгънә бар икән? Фәхешлектән ерак булмаган кеше, калганнарның гайбәтен сөйләргә дә, гаиләсендә, җәмгыятьтә үзен дорфа тотарга да читенсенмәс. Мисал өчен, көн саен эшкә йөрибез, һәм кергән саен, сакта торучыларга махсус рөхсәт кәгазе күрсәтергә кирәк ди. Бер көн күрсәтәбез, бер атна, ай, һәм бер-ике айдан кеше күрсәтмичә генә кереп китмәкче була. Сакчы ипләп кенә күрсәтергә сораса, дорфа итеп: «Мин монда көн саен йөрим, истә калдырып булмый мәллә?» – дип әйтүче кешеләрне очратканыгыз юкмы әллә? Без, мөселманнар ук, шулай эшлибез бит. Читтән карап торганда бу инде талашуга тиң. Әйткәнебезчә, һәр кеше мөмкинлегенә карап яманлык кыла: эшче сакчыга кычкыра, ә шундый холыклы кеше берәр югарырак урында утырса? Шуңа күрә, үзебезнең генә түгел, якыннарыбызның да, балаларыбызның да гыйбадәтләренә игътибарлы булыйк! Салкынлык белән карап, намазны тиз генә укып, кабат дөньяга чума башласак, дөнья безне үзенә батырачак. Ә дөньяда бер кагыйдә бар: кем көчлерәк, кем җитезрәк, шуның тапкан «сөяге» дә зуррак булачак. Ә инде ул «сөяк»нең ничек, нинди юллар белән табыласы аңлашыла: кычкырышулар, талашулар, алдаулар аша! Сак булыйк, җәмәгать!

Өченчедән, догалар кылыйк. Бу дөньяның, барлык галәмнәрнең, безнең, табигатьнең, хайваннарның Раббысы – Аллаһы Тәгалә. Тәүбәләр кылып, зикерләп әйтеп, һәрдаим догада булсак, Аллаһы бирсә, без дөньядагы иминлекне, тынычлыкны чакыручы, якынайтучылар рәтендә булырбыз. Дога – ул мөселманның иң зур мөмкинлеге, коралы. Әби-бабаларыбыз дога кылганда Раббыбыздан кеше золымыннан гына сыену сорамыйча, табигать бәла-казаларыннан, ут-су хәвефеннән дә сыену сорыйлар иде. Чыннан да, кешенең кылган гөнаһлары аркасында, дөнья табигать бәла-казаларыннан да тыныч булмаска мөмкин. Су басулар, җир тетрәүләр һәм башка төрле афәтләр безнең көнкүрешне иминсез кылырга мөмкин. Шуңа да Раббыбыздан һәртөрле тынгысызлыктан, иминсезлектән безләрне ерак кылуын сорарга кирәк. Раббыбыз безне дә, сезне дә тыныч-имин тормышлар белән яшәтеп, Үзенең яраткан, камил гакыллы, күркәм холыклы колларыннан кылса иде. Әмин!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәенишәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*2 нче сентябрь вәгазе,*
*сафәр аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Гыйлем алу – фарыз

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Бүгенге вәгазебез гыйлем алу мөһимлеге хакында булыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гыйлем алу – һәрбер мөэмин-мөселман өчен фарыз», – дигән. Икенче бер хәдистә: «Кем дә кем гыйлем алу юлына басса, Аллаһы аңа җәннәткә алып бара торган юлны җиңеләйтә. Фәрештәләр гыйлем алучы кешегә ризалык белдереп, канатларын җәя. Күктәге һәм җирдәге җан ияләре гыйлем иясенең гөнаһысын гафу итүне сорый, хәтта – балыклар да. Галимнең гыйбадәт кылучы (белемсез) кешедән өстенлеге, айның бөтен йолдызлардан да өстен булганы кебек. Галимнәр – алар пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр динарны да, дирһәмне дә мирас итеп калдырмады, алар бары тик гыйлем генә калдырды. Кем дә кем аны алса, үзенә бик зур өлеш алган булыр»[1], – дип әйтелгән.

Ошбу хәдистән гыйлем алуның Аллаһы каршында нинди мөһим урын алуын аңлап була. Моннан тыш, Раббыбызның Җәбраил гәләйһиссәлам аша Пәйгамбәребезгә җиткергән иң беренче сүзләре дә гыйлем алуга әмер булган:

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ

**«[Расүлем! Һәрнәрсәне юктан бар итеп] Яратучы Раббың исеме белән [башлап, Коръәнне] укы!»**

«Әл-Галәк / Оешкан кан», 96:1

Хөрмәтле мөселманнар, әлбәттә, һәрнәрсәнең дә төрле ягы бар. Гыйлемнең дә файдасызы, кирәкмәгәне була. Расүлебез дә аннан куркып, болай дип дога кыла торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ عِلْمٍ لَا يَنْفَعُ، وَمِنْ قَلْبٍ لَا يَخْشَعُ، وَمِنْ نَفْسٍ لَا تَشْبَعُ، وَمِنْ دَعْوَةٍ لَا يُسْتَجَابُ لَهَا

Мәгънәсе: *«Йә Аллаһы! Дөреслектә, мин сиңа файдасыз гыйлемнән, Синең бөеклегеңнән курыкмаучы йөрәктән, туймаучы нәфестән һәм кабул булмаучы догадан сыенам»*[1].

Әти-әнинең дә үз баласына бирә алганнардан иң хәерле нәрсә – ул гыйлем. Әлбәттә, гыйлем әдәп белән бергә булырга тиеш. Безнең «гыйлем» дип әйтүебез әдәпне дә күзаллый. Аннан соң, Аллаһы Тәгалә тарафыннан әманәт итеп тапшырылган балага гыйлем бирү – ата-ананың мәҗбүри бурычы, чөнки диннең, милләтнең киләчәге бүгенге көндә үк тәрбияләнә. Һәм бу мәсьәләгә салкын карау киләчәккә тап төшерергә мөмкин.

Гыйлем бу дөньяда гына түгел, Ахирәттә дә адәм баласына таянычтыр. Бер хәдистә Пәйгамбәребез: «Кеше үлгәч, аның барлык гамәлләренә дә әҗер-савап язылу туктый, өч төрле гамәленнән кала: әҗер-савап китереп торучы садака, кешеләр файдалана торган гыйлем һәм догачы бала»[2], – дип әйткән.

---

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Балаларыбызны гыйлемгә этәрер өчен, үзебездә дә гыйлемгә омтылу булырга тиештер. Шуны да онытмыйк: һәр кеше үз гыйлемсезлеге өчен үзе җавап бирәчәктер. Шуңа да гыйлем алган кеше дә алганыннан файда китерсә иде.

Аллаһы Раббыбыз безләрне гыйлемсезлектән сакласын, гыйлем алуга юлларыбызны җиңеләйтсен, вәгазебездән файдаланырга насыйп итсен.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*ТР МДНнең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәре*

*9 нчы сентябрь вәгазе,*

*сафәр аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Әбү Мансур Әл-Матуриди юлыннан барабыз

Галәмнәрнең Раббысы булган Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкраналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават-сәламнәр әйтәбез.

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре, аңа иярүчеләр һәм, гомумән, Пәйгамбәребезнең өммәте ул. Без – әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать вәкилләре – Аллаһыга, фәрештәләргә, китапларга, пәйгамбәрләргә, Кыямәт көненә, тәкъдиргә һәм яхшының да, яманның да Аллаһыдан булуына ышанабыз.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешеләрнең иң хәерлесе – минем вакытымдагы кешеләр, ә аннары – алардан соң булган кешеләр, ә аннары алардан соң булганнары», – дип әйткән[1].

Пәйгамбәребезнең: «Сезгә минем һәм минем сәхабәләремнең сөннәтен калдырам», – дигән сүзләренә ияреп, без яраткан сәхабәләребезнең дә, табигыйннәребезнең дә хезмәтләренә таяна алабыз. Аллаһыга шөкер, ул заманнар безгә бик күп галимнәр бүләк иткән дәвер булып чыкты: Гомәр бине Әл-Хаттаб, Гали бине әби Талиб, Зәед бине Сәбит, Әнәс бине Мәлик, Хәсән Әл-Басри, Үвәйс Әл-Карани, Сагыйд бине Әл-Мосаййиб, без вәгазьләребезнең азагында искә алырга яраткан Фузайл бине Гыяз һәм башка бик күпләр.

1 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

Бу шәхесләребез Пәйгамбәребезне яки аны күргән кешеләрне күргән, алар белән аралашкан, ягъни бик бәрәкәтле вакытта яшәгән. Алар Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең түбәндәге сүзләрен тулысы белән аңлаганнар һәм кабул иткәннәр:

وَمَا آتَاكُمُ الرَّسُولُ فَخُذُوهُ وَمَا نَهَاكُمْ عَنْهُ فَانتَهُوا ۚ

**«Расүл сезгә нәрсә бирсә, шуны [кабул итеп] алыгыз, сезне нәрсәдән тыйса, [шуннан] ваз кичегез».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:7

«Ә Пәйгамбәребез безгә нәрсә алып килгән соң?» – дигән сорау туа. Чыннан да, без – бүгенге көн мөселманнары, Ислам диненең нәрсәләр алып килгәнен кайдан белергә тиеш соң? Моңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе җавап бирә: «Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары». Һәм Аллаһыга шөкер, без, аерым алганда, Татарстан мөселманнары, олуг галим, имам Әбү Хәнифә дини-хокукый юнәлеше һәм олуг галим Әбү Мансур Әл-Матуриди тәгълиматлары нигезендә факыйһ һәм Голәмәләр иҗтиһадында чагылыш тапкан Коръән, Сөннәт һәм шәригать нормаларындагы хакыйкатькә таянып яшибез. Имам Әгъзам Әбү Хәнифә турында бик күп тапкырлар сөйләшкәнебез бар инде. Табигыйннәр заманында яшәгән бу галимебезгә Аллаһы Тәгалә зур бәрәкәт бирә. Ул без бүгенге көндә аерым-аерым өйрәнергә күнеккән кайбер фәннәрне системага салучы да булып тора. Аллаһы Тәгалә һәр 4 мәзһәбнең дә имамнарына рәхмәтен бирсә иде. Бу дүрт галим күп фәннәрне белгән, һәм алар нигез салган шушы юллардан тагын бик күп галимнәр атлаган. Аларның кайберләре фикһ галимнәре булса, кайберләре гакыйдә фәнен өйрәнеп, гади халыкка җиткерергә тырышкан. Шулар арасыннан кәлам, ягъни гакыйдә фәнен тирәнтен өйрәнеп, ялгыш фиркалар барлыкка килгән вакытта аларга каршы чыгып, хак аңлауны өстен күтәрә алган галимнең берсе – Әбү Мансур Әл-Матуриди. Ул һиҗри буенча 238 елда

туса да, галимнәребез аны имам Әбү Хәнифә хәзрәтләре карашларын нечкәлекләренә кадәр өйрәнеп, тәгаенләп бетергән галим дип саныйлар. Бигрәк тә гакыйдә фәненә басым ясалганга күрә, Матуриди хәзрәтләре хәнәфи мәзһәбенең гакыйдә өлешендә аерым урын алган.

Имам Сәмәркандка янындарак урнашкан Матурид дигән авылда туа. Яшьлеген гыйлем алуга багышлый: Коръән, хәдис, тәфсир кебек фәннәрне өйрәнә. Шулай ук шәригать хөкемнәре, әдәп-әхлак мәсьәләләре дә галимне бик кызыксындырган фәннәрдән була. Аллаһы Тәгалә имамга шулай ук бәрәкәт бирә: ул гыйлем алып кына калмый, гыйлеме белән чын мәгънәсендә бүлешә, аны тарата ала. Бүгенге көндә бу имамның үз хезмәтләре барыбызга да таныш ук булмаска мөмкин. Шулай да «Хозур» нәшрият йортында имам Матуридиның «Китабүт-Тәүхид» һәм «Тәэвиләтүл-Куръән» хезмәтенең беренче өлеше белән танышырга мөмкин.

Барыбыз да белә: Пәйгамбәребез вакытында мөселманнар бер юл буенча гына баралар. Аларда ниндидер фикер каршылыклары, гакыйдәдә бер генә дә ихтилаф булмый. Әмма имам Гали бине Әби Талиб вакытында хәвариҗләр дигән беренчеләрдән булган адашкан фиркалар барлыкка килә башлый. Ә алардан соң мөгътәзиләр, мөрҗиләр һәм башка фиркалар барлыкка килә, һәм алар барысы да үзләренең ялган, дөрес булмаган фикерләрен күтәрә башлыйлар. Әлбәттә, әһле Сөннәт галимнәре дә аларга каршы көрәшне туктатмый, алар хакыйкатьне үзләренең хезмәтләре аша гына түгел, зур-зур фикер алышуларда катнашып, халыклар каршында чыгышлар ясап якларга тырыша. Нәкъ менә мөгътәзилә фикерләренә каршы күтәрелеп, хакыйкатьне яклаучы галимнең берсе Әбү Мансур Әл-Матуриди була да инде. Аллаһы Тәгалә бу имамга тагын бер зур нигъмәт бирә: ялган фикерне хактан аерырга өйрәтә. Меңләгән кеше бу имамның халык алдындагы вәгазьләреннән һәм фикер алышуга багышланган очрашулардан соң хак юлга баса, динне кабул итә. Аллаһы Тәгалә бу имамга

тел ачкычлары бүләк итә, шуңа да имам күп халык алдында чыгыш ясарга читенсенми, һәм, киресенчә, мондый форсатны беркайчан да кулдан ычкындырмый. Галим яшәгән дәвердә адашкан тәгълиматлар гына таралып калмый, ул вакытта фәлсәфә, мифология күтәрелә башлый. Бигрәк тә грек фәлсәфәчеләренең дөнья төзелешенә караган фикерләре гади халык арасында гына түгел, кайбер адашкан фиркаларның тәгълиматларына да үтеп керә. Бу үз чиратында халыкка диннең асылын ялган фикерләр аша таратуга китерә башлый. Имам Әл-Матуриди һәм киләчәктә аның укучылары бу күренешкә каршы зур хезмәт, тырышлык куя. Имам Әбү Хәнифәне замандашлары ук «Имам Әгъзам», ягъни бөек имам дип атаган кебек, имам Матуридиның тарафдарлары да аны «Имам Әл-Һүдә», ягъни «Туры юл имамы» дип атый башлыйлар. Акрынлап Урта Азиядә, Идел буе Болгар дәүләтендә, Пакыстанда, Һиндстанда, Әфганстанда, Госманлы империясенең күпчелек өлешендә яшәүче хәнәфиләр имам Әбү Мансур Әл-Матуриди юлыннан бара башлый.

Аллаһыга шөкер, безнең 4 фикһ мәзһәбе дә, ике гакыйдә мәктәбе дә бүгенге көнгә кадәр үзләренең асылын югалтмыйча, безнең көннәргә килеп җитте. Бүген дә бу мәктәпләрнең зур галимнәре, миллионлаган укучылары бар. Әлбәттә, фиркалар да Аллаһы Тәгаләнең бер рәхмәтедер. Бүгенге көндә нинди генә фиркалар таралмасын, Аллаһы Тәгаләнең кулы бар, тәне бар, дип, Коръән аятьләрен ничек кенә ялгыш итеп аңлатырга, җәһәннәм мәңгелек түгел дип, күпме генә ышандырырга тырышмасыннар, имам Әбү Хәнифә, имам Әл-Матуриди, аларның укучылары, хакыйкатьне яклау өчен, бик күп хезмәтләр калдырганнар инде. Аллаһы Тәгалә безгә дә тәүфыйк биреп, адашмыйча, тайпылмыйча туры юлдан барырга насыйп итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәеншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*16 нчы сентябрь вәгазе,*

*сафәр аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Диннәр арасында татулык

Галәмнәрнең Раббысы булган Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкраналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават-сәламнәр әйтәбез.

Әссәләмү галәйкүм, хөрмәтле мәхәллә халкы, мөселман дин кардәшләрем! Көннәрнең иң хәерлесе булган җомга көне һәрбарчабызга мөбарак булсын. Җомга көненең фазыйләтләренә, вәгъдә ителгән әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсен. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабыздан разый булсын.

Хөрмәтле җәмәгать, без бүген динара бердәмлек турында, башка дин әһелләренә карата мөгамәләбез хакында динебезнең тәртипләрен карап, вәгазьләнеп китәрбез.

Ни хикмәт, ни гаҗәеп, Аллаһы Тәгалә рәхмәте, теләге белән безне төрледән-төрле итеп, юктан бар кылган. Гакылыбызга, нәфесебезгә, гамәлләребезгә Үзе теләгәнчә ихтыяр көче билгеләгән. Шуңа күрә һәр кешенең үз фикере, үз юлы, хәтта үзе генә яраткан әйбере була. Һәрбарчабыз кабатланмас бер шәхестер. Табигатьтә, ризыкларда төрлелек булган кебек, адәм балалары арасындагы төрлелек – Аллаһының бер кануны, тәртибедер. Шуңа күрә бу чынбарлыкны, Галәм канунын кабул итү акылга һәм иманыбызга сыешлы гамәлдер. Әмма төрледән-төрле булуыбызга карамастан, Аллаһы Тәгалә безгә бердәмлек, дуслык, якын булу юлларын да ачык куйды. Галәмнәрне юктан бар кылучы, аның Хуҗасы Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хавва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] Без сезне, [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен, кавемнәр һәм кабиләләр иттек».**

«Әл-Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Бу аятьне күп тапкыр укысак та, яңадан исебезгә төшереп, кагыйдә буларак истә калдыру бик файдалы булыр иде. Үз чиратында, Аллаһы Тәгалә динне, хаклыкны тануда да ихтыяр биргән. Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

وَلَوْ شَاءَ رَبُّكَ لَآمَنَ مَن فِي الْأَرْضِ كُلُّهُمْ جَمِيعًا ۚ أَفَأَنتَ تُكْرِهُ النَّاسَ حَتَّىٰ يَكُونُوا مُؤْمِنِينَ

**«[Җир йөзендәге кеше һәм җеннәрнең бөтенесе дә иман китерергә теләп һәм] Раббың [да моның шулай булуын] теләгән булса, җирдәге кешеләрнең һәммәсе дә тулысынча иман китерерләр иде. [Ләкин Аллаһы Тәгалә аларны иман китерергә мәҗбүр итмәде]. Син кешеләрне, мөэмин булсыннар дип, ирексезләр идеңме әллә?»**

«Юныс», 10:99

Әлеге аятьтән аңлашылганча, дин ягыннан да төрлелек Аллаһыдан узып башкарылмый, бу Аның хикмәте илә буладыр. Хәтта ки, Пәйгамбәребездән дә кешеләрне ирексезләп, мәҗбүриләп бер дингә кертеп бетерү соралмаган. Аллаһы тарафыннан ятарылган табигать һәм кешеләр кеше тырышлыгы белән үзгәртелә алмый. Ә бәлки, күркәм, ма-

тур һәм гадел рәвештә чакыру, иманга өндәү сорала. Әби-бабайларыбыз гасырлар буена башка халыклар һәм диннәр белән янәшә яшәде. Бер яктан, бу күренеш аларны баеткан булса, икенче яктан, үсеш һәм уңыш өчен этәргеч тә биргән. Һәм, шул ук вакытта, динебезгә тугры калып, аны безгә тапшыра да алганнар.

Башка динне сүгү, башка дин әһелләренә хәтта телең белән дә зыян салу, динебездә, гомумән, тыелган. Башка динне, шушы диндә булучыларны сүгеп, начар сүздә булсаң, киресенчә, гөнаһлы буласың. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَا تَسُبُّوا۟ ٱلَّذِينَ يَدۡعُونَ مِن دُونِ ٱللَّهِ فَيَسُبُّوا۟ ٱللَّهَ عَدۡوَۢا بِغَيۡرِ عِلۡمٍۗ

> **«Сез аларны, Аллаһыны калдырып, табынган нәрсәләрен сүкмәгез [башка юл белән игелеккә чакырыгыз], юкса алар да белмичә чиктән ашып, Аллаһыны сүгәчәкләр».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:108

Бу аятьтә мөселман бәндәсенә башка динне, шушы дин әһелләрен хәтта сүгү дә тыела. Башка төрле гаделсезлекләр турында әйтеп тә тормыйбыз. Бары тик матур динара тормыш алып бару сорала. Халыкта: «Кешенекенә тимә, үзеңнекен бирмә», – дигән әйтем бар. Башка дин әһелләре белән хәерле мөгамәләдә булуның иң зур мисалы – Пәйгамбәребезнең тормышы, ул безгә үрнәк булып тора. Шулай ук бөек сәхабәләрнең тормышын өйрәнсәк тә, алардан үзебезгә үрнәк алырга мөмкинбез.

Динара матур тормыш алып баруның бер мисалы итеп, көндәлек яшәешебезне китерергә була, чөнки, без, тормыш алып барганда, башка халыклар һәм диннәр белән янәшә яшибез, эшлибез. Үзара хөрмәт, яхшы мөгамәлә безнең бер-беребезгә булган дустанә, гадел мөнәсәбәттә чагыла. Үзара килешеп яшәү һәм тынычлык, беренче чиратта, безнең үзебездән башлана. Нәрсә дә булса әйтер, язар алдыннан, кемгә дә булса бер караш

ташлаганчы, иҗтимагый челтәрләрдә нәрсәдер язганчы, иң элек, мин бу гамәлем белән кемнәрдер арасында каршылык тудырмыйммы, кемнедер мыскылламыйммы, дип уйларга кирәк. Үз сүзе, үз гамәле өчен һәркем үзе җавап бирә. Шуңа күрә, һәрбер мөселман үзе яшәгән җирдә, эшендә, гомумән, үзе аралашкан кешеләр арасында үрнәк булып, динебез кушканча яхшы мөгамәләдә булырга тиеш.

Үз чиратында мөфтиятебез тарафыннан да бу максатларда күп чаралар үткәрелә: бердәм хәйрия чаралары, уку-укыту өлкәсендә рухи кыйммәтләрне саклауда бердәм тәрбия эшләре алып бару, төрле берләштерә торган спорт, бәйрәм чаралары үткәрү шуның мисалы булып тора.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*«Динислам» мәчете имам-хатыйбы*

*23 нче сентябрь вәгазе,*

*сафәр аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Тәрбияле ата һәм ана

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Аллаһының рәхмәте белән безнең халкыбыз Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итә. Өлкән буыннарыбыз Раббыбыз Аллаһыны танып, Аңа гыйбадәт кылучылар иде. Әмма ахыргы 100 елда безнең халкыбыз төрле авырлыклар күрде: динсезлек чорын да, манараларын кискәннәрен дә, балаларга тәрбия бирә торган мәдрәсәләрне юкка чыгарганнарын да, сабыйларга гыйлем бирүче абыстайларны, муллаларны сөргәннәрен дә. Шул сәбәпле, хәзерге дәвердә балаларга тәрбия бирү мәсьәләсе шактый күтәрелә.

Элекке заманнарда данлыклы хәзрәтебез янына бер яшь кенә әти чабып килә дә: «Хәзрәт, улым туды, аңа кайчан тәрбия бирә башларга кирәк?» – дип сорый. Хәзрәт шатланып дога кыла һәм: «Улым, син 9 айга соңга калдың», – ди. Ягъни, бала бу дөньяга килгәнче, без баланы ничек тәрбияләвебез турында уйларга, фикерләргә тиеш. Ата-ананың бер-берсенә мөнәсәбәтен бала ана карынында ук ишетә икәнен онытмаска кирәк.

Кеше үзенә тиң парын – кыз бала ирен сайлаганда, булачак балаларның атасын, оныкларының бабасын сайлый. Егетләр үзләренә хатын сайлаганда, булачак улларының, кызларының әнисен, оныкларының

әбисен сайлый.

Аллаһының рәхмәте белән гаилә коргач, Аллаһы Тәгалә тәкъдире белән һәрбер гаиләдә тәүфыйклы, иманлы, озын гомерле, мул ризыклы балалар булсын иде.

Бала бу дөньяга аваз салганчы әти-әни өстендә нинди вазифалар тора соң? Беренчедән, ике яктан кодалар һәм яшьләр бергә утырып, бөтен гаилә мәсьәләләрен уртага салып сөйләшсеннәр иде. Әлбәттә, без һәрвакыт шәҗәрә ягын карарга әйтәбез, ягъни яшьләргә әти-әнисе, әби-бабасы, башка буыннары турында белергә кирәк.

Бер галимнән: «Ничек балаларыбызда намазга мәхәббәт уятырга?» – дип сораганнар. Шунда данлыклы шәехебез «Беренчедән, намазга үзегез мәхәббәт белән басыгыз, шунда балаларыгызда да булыр», – дигән. Бала без җиткерә торган сүзне ишетмәскә мөмкин, әмма ул безнең гамәлләребездән, эшләребездән өйрәнә. Урамда карасаң, яшь кенә әни, бер кулында бала белән аның арбасын алып бара, икенче кулында – тәмәке. Ә менә шуннан соң ир бала әнисенең: «Син тәмәке тартма, тәрбияле бул», – дип әйтүен тыңлармы?! Әни һәм әти кылган эш бала өчен үрнәк булып тора, шуңа күрә безнең һәр гамәлебез тәрбияви булсын. Без балаларыбызны һәм оныкларыбызны дога кылучы итеп үстермәсәк, 100 елдан соң алар безгә атап дога кылырмы? Аллаһының Расүле өйрәткән юлыбыз бар, һәм без шулай балаларны тәрбияләргә тиеш. Ата-ана әхлаксыз, тәрбиясез булса, бала да шундый булыр.

Акыл иясе Җәләледдин Руми янына киңәш һәм зирәк сүз артыннан күп кенә кеше килә торган булган. Бервакыт аңа бер хатын үзенең малае белән килгән һәм:

– Мин барлык ысулларны да сынап карадым, әмма бала мине тыңламый. Ул артык күп шикәр ашарга ярата. Аңа болай эшләү ярамый, үзенә әйтегезче. Улым сезнең сүзегезгә колак салыр, чөнки ул сезне бик хөрмәт итә, – дигән.

Җәләледдин Руми балага карап:

– Өч атнадан соң килегез, – дигән.

Хатын аптырашта калган, әмма өч атнадан соң яңадан килгәч, акыл иясе янә аларны: «Өч атнадан соң килерсез», – дип кайтарып җибәргән.

Өченче тапкыр килгәч, Җәләледдин Руми малайга: «Киңәшемне тыңла, минем сүземне ишет, шикәрне күп ашама, ул сәламәтлек өчен зарарлы», – дип әйтә.

– Сез миңа шундый киңәш биргәч, мин моны бүтән эшләмәячәкмен, – дип җавап бирә малай.

Әнисе малайга аны урамда көтеп торырга кушкан һәм Җәләледдин Румидан: «Укытучы, нигә сез бу гади әйберне беренче тапкыр килгәндә әйтмәдегез?» – дип сораган.

Җәләледдин Руми: «Эш шунда ки, мин үзем татлы ризыкны бик яратам. Сезнең улыгызга шикәр ашаудан тукта дип әйтер өчен, миңа үземә бу зәгыйфьлектән арынырга кирәк иде. Башта мин моңа өч атна җитәр дип уйладым, аннары ялгышуымны аңладым», – дигән.

Шуңа күрә бала тәрбиясе бездән – әти-әнидән, әби-бабайдан башлана. Кызганыч ки, без гаепне мәктәпкә, урамга, телевизорга, интернетка сылтыйбыз, ләкин әни сөте белән кермәсә, тана сөте белән кермәс.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әни – ул бала өчен мәдрәсә», – дигән. Әни дога кылуны, намаз укуны, ураза тотуны, гомумән, динне белмәсә, ничек ул үз баласына динне тапшырыр?!

Хөрмәтле егетләр, кызлар! Мәчетләргә, мәдрәсәләргә дәрес алырга, укырга керегез, дин таләпләрен белегез, шул вакытта гына сез балаларыгызга «мәдрәсә» булырсыз.

Кайбер вакытта: «Мин дини гыйлем алам, ул миңа җитә, дөньяви гыйлем кирәкми», – дигән сүзләр ишетәбез. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрбер кеше ике канатлы булырга тиеш, бер канаты – Ахирәте, дине булса, икенчесе – бу дөнья», – дигән.

Хөрмәтле әтиләр һәм әниләр! Ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирешер өчен, ике канатлы булып яшәргә омтылыгыз. Шул вакытта балаларыгыз да ике канатлы булыр. Балаларыбызга дөньяви һәм дини гыйлем бирик! Ул безгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан әманәт итеп бирелгән, шуны үтәргә онытмыйк!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчетенең имам-хатыйбы*

*30 нчы сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Ислам – тынычлык юлы

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Бисмилллләәһир-рахмәәнир-рахиим! Вәгазебезне сөннәт буенча бәсмәлләдән башлыйк әле, чөнки алай башлаган гамәлдә, Аллаһы бирсә, бәрәкәт булыр. Шулай ук бәсмәлләне әйткәндә, без үзебез өчен дә, аны ишетүчеләр өчен дә Аллаһының исем-сыйфатларын искә төшерәбез: «Аллаһы, Рәхимле, Шәфкатьле». Чыннан да, бүгенге вәгазебезнең темасына әйләнеп кайтсак, ә ул «Ислам – тынычлык юлы» дип атала, Ислам кем тарафыннан иңгән соң дигән сорау туачак. Без: «Аллаһы», – дип җавап бирербез. Сораучы кеше, дәвам итеп, Аллаһы Тәгалә турында сорый башласа, без Аның иң беренче килгән исемнәрен кулланып: «Ул – Әр-Рахмән һәм Әр-Рахим», ягъни Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә тарафыннан иңгән, дип әйтербез. Һәр эшебезне, гамәлебезне, җөмләбезне шушы гыйбарәдән башлап, гел үз-үзебезгә искә төшерәбез: «Бу эшемне мин Рәхимле һәм Шәфкатьле булган Аллаһы исеме белән башлыйм».

Исламның башы да, уртасы да, ахыры да иминлек, сәламәтлек белән сугарылган: Ислам сүзе «сәламәт» дигән тамырдан; Ислам – сәлам таратырга, ягъни иминлек таратырга чакыра; Ислам туганлык җепләрен сакларга боера; Ислам кеше гомерен югарыга күтәрә, аңа кагылуны тыя; Ислам кешенең үз гомерен, үз җанын сакларга өнди, аңа салкын карау-

ны тыя; Ислам кешенең малына кагылуны да тыя, Ислам әти-әниләргә, туганнарга, дусларга карата иң яхшы мөгамәләдә булырга, кечеләрне дә, олыларны да хөрмәт итәргә куша; Ислам хайваннарга да, табигатькә дә зыян китерүне тыя, Ислам – кешеләр белән көрешкәндә дә сәлам белән каршы алырга, сәлам белән саубуллашырга, ягъни Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын, дип әйтергә куша һ.б.

Кадерле җәмәгать, динебез һәртөрле гаделсезлекне, һәртөрле битарафсызлыкны, һәртөрле зыянны тыя! Һәм, киресенчә, яхшылыкка, яхшылык кылырга, яхшылыкны күрә белергә чакыра. Менә бүген, Аллаһы бирсә, кыска гына итеп шулар турында сөйләшеп китәрбез.

Ислам турында кем генә, нәрсә генә әйтмәсен, алар аны шул динне тоткан кешеләрнең гамәлләреннән чыгып әйтергә күнеккән. Бер караганда, бу дөрес тә кебек. Кеше үзен мөселман дип атый икән, димәк, ул үз өстенә фарызларны, сөннәтләрне һ.б. үтәргә дип, һәм, киресенчә, мәкруһлардан, харамнардан тыелам дип, зур вазифа ала. Һәм дин белән таныш булмаган кеше, үзен мөселман дип атаган кешегә карый да, аның изгелек кылганын, тырышып эшләп йөргәнен күреп, динебез турында яхшы фикер йөртә башлый, йә ул кешенең гаделсезлекләрен, гөнаһларын күреп, динебез турында да тискәре фикер йөртә башлый. Әмма, кеше кеше инде ул, без күпме генә: «Мөселман – диннең көзгесе», – дип әйтсәк тә, кеше абына да, ялгыша да ала. Бер кешенең гамәлләренә карап, беребез дә бар милләт, ил яки дин турында фикер йөртергә тиеш түгелбез. Бу безгә дә кагыла: динебезне беләбезме? Аның нәрсәгә чакырганын, нәрсәләрдән тыйганын өйрәнәбезме, үтибезме?

Беренчедән, динебездә кемнәргә нинди гамәлләр өчен әҗер-саваплар ирешкәнен карап алыйк. Ник дигәндә, нәкъ менә әҗер-савап белән «котырткан булып» кешеләрне ялгыш юлларга җибәрүче кешеләрне күреп була. Аллаһы Тәгаләнең берәр тапкыр булса урлаган, гайбәт сөйләгән, кеше хакына кергән өчен әҗер-савап вәгъдә биргәне бармы?

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

مَنْ عَمِلَ صَالِحًا مِّن ذَكَرٍ أَوْ أُنثَىٰ وَهُوَ مُؤْمِنٌ فَلَنُحْيِيَنَّهُ حَيَاةً طَيِّبَةً ۖ

**«Һәр мөэмин ир яки мөэмин хатын [иман шартларына шөбһәсез иман китереп] изге гамәл кылса, Без аңа [дөньяда да, кабердә дә, җәннәттә дә] бик күркәм тормыш бирәчәкбез».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:97

إِنَّ الْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ وَالْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْقَانِتِينَ وَالْقَانِتَاتِ وَالصَّادِقِينَ وَالصَّادِقَاتِ وَالصَّابِرِينَ وَالصَّابِرَاتِ وَالْخَاشِعِينَ وَالْخَاشِعَاتِ وَالْمُتَصَدِّقِينَ وَالْمُتَصَدِّقَاتِ وَالصَّائِمِينَ وَالصَّائِمَاتِ وَالْحَافِظِينَ فُرُوجَهُمْ وَالْحَافِظَاتِ وَالذَّاكِرِينَ اللَّهَ كَثِيرًا وَالذَّاكِرَاتِ أَعَدَّ اللَّهُ لَهُم مَّغْفِرَةً وَأَجْرًا عَظِيمًا ﴿٣٥﴾

**«[Аллаһы Тәгаләнең бөтен хөкемнәренә буйсынып] Исламга кергән ирләр һәм Исламга кергән хатыннар, [ышанырга тиешле мәсьәләләрнең барысына да] иман китергән ирләр һәи иман китергән хатыннар, [әмерләрне тотып һәм тыюлардан тыелып] итагать иткән ирләр һәм итагать иткән хатыннар, [ниятләрдә, сүзләрдә һәм гамәлләрдә] тугры ирләр һәм тугры хатыннар, [тәкъдирләрендәге кыенлыкларга] сабыр иткән ирләр һәм [бөтен бәла-казаларга] сабыр иткән хатыннар, хошугълы ирләр һәм хошугъ иясе хатыннар, [фарыз булган зәкятне һәм нәфел булган] садакалар бирүче ирләр һәм хатыннар, [фарыз һәм нәфел буларак] ураза тоткан ирләр һәм ураза тоткан хатыннар, җенес әгъзаларын [зина, ливата кебек харамнардан] саклаган ирләр һәм саклаган хатыннар, Аллаһыны күп итеп зикер иткән**

**ирләр һәм зикер иткән хатыннар, һичшиксез, Аллаһы болар өчен мәгъфирәт һәм [итагатьләре өчен] зур әҗер әзерләде».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:35

Күрәсезме, әҗер-савап кемнәр өчен әзерләнгән?

Аллаһы Тәгалә кешегә ниндидер физик зыян салу түгел, хәтта ки авыр сүз әйтүне, кеше артыннан сүз йөртүне дә тыя!

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اجْتَنِبُوا كَثِيرًا مِّنَ الظَّنِّ إِنَّ بَعْضَ الظَّنِّ إِثْمٌ ۖ وَلَا تَجَسَّسُوا وَلَا يَغْتَب بَّعْضُكُم بَعْضًا ۚ

**«Ий иман китерүчеләр! Фаразларның бик күбеннән сак булыгыз, чөнки, һичшиксез, кайбер фаразлар – гөнаһ. Янә [бер-берегездән] гаеп эзләмәгез, берәүләрегез икенчеләрегезнең гайбәтен сатмасын»;**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:12

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا يَسْخَرْ قَوْمٌ مِّن قَوْمٍ عَسَىٰ أَن يَكُونُوا خَيْرًا مِّنْهُمْ

**«Ий иман китерүчеләр! Берәүләр икенче бер кешеләрне мыскыл итмәсен, кем белә, бәлки, алар болардан хәерлерәктер».**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:11

Һәм мондый аяти-кәримәләрне бик күпләп китереп булыр иде.

Икенчедән, динебездә зур гөнаһлар кылу гына тыелмый, хәтта ки кечкенә ганаһлар кылу да шелтәләнә. Кыямәт көне үлчәүләренә бер бөртек изгелек куелган кебек, анда бер бөртек начарлык та куела. Пәйгамбәребез гөнаһлар кылуны гына түгел, аларга илтә торган юллар турында да кисәтә иде. Мәсәлән, аның янына бер кеше нәсыйхәт сорап килгәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа берничә тапкыр «Ачуланма», – дип кенә җавап кайтара. Ә кеше ачуланса, аның акылы

капланып, әллә нинди начар гамәлләр кылырга мөмкин бит. Ачулы кеше калганнарга гына түгел, үзенә дә зыян салырга мөмкин, андый кешенең акылы каплана һәм ул бары тик хискә бирелеп, ни кылганын аңламыйча да йөрергә мөмкин. Ә Пәйгамбәребез, мондый гамәлләр кылынмас өчен, алдан ук кисәтеп куя!

Пәйгамбәребез вәгъдәсендә тормаган, әманәтенә хыянәт иткән кешеләрне «икейөзле» дип атый. Кулларыннан һәм теленнән башкалар имин булмаган кешене хәтта мөселман түгел, ди. Мөселман булган кеше беркайчан да алдаламас, дип кисәтә. Һәм бигрәк тә, башкаларга карата рәхимлелек күрсәтмәгән кешеләргә рәхимлелек күрсәтелмәс, дип әйтә. Киресенчә, Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Бу дөньяда кешеләргә газап кылучыларны Аллаһы Тәгалә Үзе газаплар», – дип килә. Пәйгамбәребез бу дөньяга килгәнче, күпме бозыклыклар, әшәкелекләр кылына иде дә, ул килгәч, гүя бер нур булып, барлык дөньяны яктыртып, шушы эшәкелекләр юкка чыга башлады. Ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ниндидер бер кавем, милләт өчен генә түгел, барлык мәхлүкъларга да рәхмәт буларак җибәрелгән пәйгамбәр. Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ

> **«Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек»**, – дип әйтә.

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:07

Пәйгамбәребез җеннәргә дә, кешеләргә дә, иман китергәннәргә дә, иман китермәгәннәргә дә бары тик рәхмәт буларак иңгән икән, ул тоткан дин турында без ничек итеп киресен сөйли алабыз?

Динебезнең тынычлык дине булуының һәм тыныч юллар белән таралуының бер зур мисалын китеримме? Быел без Идел буе болгар дәүләтендә Ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүенең 1100 еллыгын

зур итеп бәйрәм итәбез. Бик күп чаралар үткәрелде, әле алда күпме чаралар планга кертелгән. Әмма, шушы вакыйга безнең өчен зур дәрес булып тора түгелме соң? Ислам динен ниндидер бер кечкенә генә авыл, шәһәр түгел, ә Идел буе болгар бабаларыбыз дәүләт күләмендә үз теләкләре белән кабул итәләр! Бу үзе бер зур мисал түгелмени?! Һәм бүгенге көндә дә без бу вакыйганың җимешләрен татып, җөмһүриятебез күләмендә матур итеп үз динебезне тотып яшәп киләбез. Аллаһыга шөкер, гаетләребезне, җомгаларыбыз, биш вакыт намазларыбызны мәчетләребезгә җәмәгать белән җыелып укыйбыз, мәчет-мәдрәсәләребездә дини дәресләр бирәбез, Ислам динен кабул итүне дәүләт дәрәҗәсендә бәйрәм итәбез. Бу безнең динебезнең күркәмлеген, матурлыгын, сафлыгын күрсәтә торган фактор түгелмени?

Кадерле җәмәгать, темабыз бик зур. Әмма Ислам дип әйткәч, күңелдә якты хисләр, тынычлык уянуын теләсәк, без үзебездән башласак идек. Нинди булырга тиешлегебезне Аллаһы Тәгалә бик күп аяти-кәримәләрдә әйткән:

أُولَٰئِكَ يُسَارِعُونَ فِي الْخَيْرَاتِ وَهُمْ لَهَا سَابِقُونَ

**«Әнә шулар хәерле гамәлләрдә [ярыша-ярыша] узышалар һәм алар башкалардан алга узачаклар»;**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:61

فَاسْتَبِقُوا الْخَيْرَاتِ

**«Сез [кыйблага юнәлгән кебек, ике җиһан бәхете казандырырлык] яхшы гамәлләргә ашыгыгыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:148

Ә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дин – ул яхшылык теләү», – дип безгә бик зур үлчәү биреп калдырган. Бу – чын-

нан да бер үлчәү, шуңа күрә гамәлләребезне, сүзләребезне алдан ук уйлап кылсак, әйтсәк иде. Безгә хисап кылганчы, үз-үзебезгә хисап кылып, тәүбәләр кылып яшәргә насыйп булса иде. Динебез чакырганнарга чын күңелдән җавап кайтаручылар рәтендә булсак иде. Әәмин!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәеншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*7 нче октябрь вәгазе,*
*рабигыль-әүвәл аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Мәүлид кичәсе

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Пәйгамбәребез дөньяга килгән ай – рабигыль-әүвәл ае җитү белән, барлык мөселманнар бу айда махсус мәҗлесләр үткәрә, мәүлидләр уздыра, Аллаһының Расүленә булган мәхәббәтләрен белдерә, Коръәндә һәм хәдисләрдә Пәйгамбәребезнең дөньяга рәхмәт өчен җибәрелүе хакында искә алынуы хакында сөйләшә.

Ләкин барыбызның да кайберәүләрнең бу очрашуларны дөрес түгел дип санаулары хакында ишеткәне бардыр. Бу чыннан да шулаймы? Пәйгамбәребез бакыйлыкка күчкәч барлыкка килгән һәрбер гамәл начар яңалыкмы? Әйдәгез, моны аңларга тырышыйк.

Күпчелек галимнәр: «Мәүлидне зарарлы яңалык дип санарга бернинди сәбәп юк», – дип әйтә, чөнки ул рөхсәт ителгән, хәтта мөстәхәб гамәлләрне дә үз эченә ала. Мәсәлән, Коръән уку һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын өйрәнү, зикер һәм салаватлар әйтү, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүенә багышланып иҗат ителгән шигырьләр уку күркәм гамәл булып тора.

Беренче тапкыр мәүлидне һиҗри ел буенча VII нче гасырда Ирбил өлкәсенең (хәзерге Гыйрак Көрдстаны) Мозаффар исемле җитәкчесе уздыра башлаган. Ибне Кәсир үзенең «Әл-бидәя вә-ниһәя» дип исемләнгән

китабында Мозаффарны (тулы исеме: Әбү Сәгыйд ибне Зәйнеддин Гали) иң юмарт һәм данлы җитәкчеләрнең берсе итеп тасвирлый. Ул аның батырлык, гаделлек, дини тәрбия кебек сыйфатларын ассызыклый. Ел саен рабигыль-әүвәл аенда ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көне уңаеннан мәүлид бәйрәмнәре үткәргән. Мәүлид бәйрәменә ул хәдисне яхшы белгән танылган галимнәрне җыйган.

Ләкин мондый дәлилләр нигезендә мәүлидне тәнкыйтьләр алдыннан, кешеләрнең мәүлидне нинди максат белән уздырганын карарга тиешбез. Бу мәҗлесләр, иң беренче чиратта, кешеләрнең йөрәкләрендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булган мәхәббәтне уяту, аның тормышы турында гыйлем тарату, Расүлуллаһ аша безгә җибәргән мәрхәмәте өчен Аллаһыга шөкер белдерү йөзеннән эшләнә.

Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен мондый мәҗлесләргә җыелышуда ихтыяҗ юк иде, чөнки аларның күңелләрендә Пәйгамбәребезнең вафатыннан соң да аңа карата мәхәббәт саклангaн. Мондый җыелышларга мохтаҗлык шушы дөньядан Пәйгамбәребез киткәннән соң, берничә гасыр узгач кына барлыкка килде. Шушы дәверләрдә күп кеше өчен ул билгеле бер тарихи шәхес кенә булып калды, аның тормышы турында бик аз гына мәгълүмат белә торган булдылар.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышыннан соң барлыкка килгән күренешләр начар яңалык дип әйтүче кешеләргә, хәзерге вакытта мөселманнар кулланган күп әйберләрне мисал итеп китерә алабыз, ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре заманында алар юк иде:

– Иң мәшһүре – Коръән мосхафы (экземплярлары). Ул беренче тугры хәлифәләр радыяллаһу ганһүмә яшәгән заманда тупланган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе яшәгән вакытта Коръәнне язу һәм җыю кирәклеге турында беркайда да искә алмый. Мондый ихтыяҗ хәлифә Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе вакытында – ха-

физлар сугышларда вафат була башлагач, Коръән югалу куркынычы тугач, барлыкка килә;

– Рамазан аенда хәлифә Гомәр радыяллаһу ганһе тарафыннан кертелгән җәмәгать белән тәравих-намазларын үткәрү дә шундый ук яңалык булып тора. Бу хакта ул үзе: «Нинди гүзәл яңалык кертү бу!» – дигән;

– Төрле дини фәннәр буенча китаплар язу һәм дини белемнәрнең махсус бүлекләргә аерылуы. Бу фәннәрнең исемнәре – гакыйдә, фикһ, гыйльм-әл-хәдис, гыйльм-әт-тәфсир, гарәп теле, сарф һәм нәһү, риторика, усуль-әл-фикһ һәм башкалар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре яшәгән вакытта болар булмаган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөреслеккә һәм яхшылыкка этәрә торган яңалыкны сөннәт дип атады, һәм аны кылучылар өчен әҗерләр вәгъдә итте, түбәндәге хәдисендә әйтелгәнчә: «Исламга яхшы традиция керткән кеше, аның өчен савабын алыр, һәм аның үрнәгенә ияргән кешеләрнең савапларын да алыр. Бу вакытта аның артыннан барган кешеләрнең савaплары кимемәс»[1].

Галимнәр мәүлид бәйрәмен үткәрүнең дөреслегенә мондый дәлилләр китерә:

1. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәүлиден уздыру – дөньяга Аллаһының сөекле бәндәсе килүенә шатлык белдерү ул. Хәтта имансыз кеше дә бу шатлыктан файда күрде: имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгында хәбәр ителгәнчә, Ислам диненең танылган дошманы Әбү Ләһәбнең һәр дүшәмбе көнендә газаплары җиңеләйтелә, чөнки ул энесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тууына шатланган һәм хәтта колы Сүвәйбаны, аңа шушы шатлыклы хәбәрне тапшырганы өчен, азат иткән.

2. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең туган көнен үзе дә зурлаган, шул көнне ураза тотып билгеләп үткән. Бу хакта имам

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Әл-Мөслим җыентыгында килгән Әбү Катәдә тапшырган хәдистә болай дип әйтелә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән дүшәмбе көнне ураза тотуы турында сорагач, ул: «Дүшәмбе – минем туган көн һәм бу көнне миңа вәхи иңдерелде», – дип җавап биргән.

3. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм инде күптән үк булган дини вакыйгаларны да игътибарсыз калдырмаган.

Имамнар Әл-Бохари һәм Әл-Мөслим җыентыгында Ибне Габбастан риваять ителгән хәдис китерелә: Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә килеп, анда яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотканын күргән һәм алардан: «Бу көнне сез ураза тотасызмы?» – дип сораган. Алар: «Бу – бөек көн, Аллаһы Мусаны һәм аның халкын коткарды, ә фиргавенне һәм аның гаскәрен батырды. Шуңа күрә без, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән, бу көнне ураза тотабыз», – дип җавап биргәннәр. Аннары Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Без Муса пәйгамбәр галәйһиссәламгә сезгә караганда якынрак, безнең аңа хокукыбыз сезнекеннән күбрәк», – дигән, һәм шул көннән башлап, Гашурә көнен ураза тотып олылый торган булган, башка мөселманнарга да бу көнне ураза тотарга кушкан.

4. Аллаһы Үзе мөэминнәрне, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүенә сәбәпле, шатлыкларын белдерергә һәм аңа салаватлар әйтергә чакыра:

قُلْ بِفَضْلِ اللَّهِ وَبِرَحْمَتِهِ فَبِذَٰلِكَ فَلْيَفْرَحُوا هُوَ خَيْرٌ مِّمَّا يَجْمَعُونَ ﴿٥٨﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Аллаһының фазылы [булган Коръәни Кәрим] белән һәм Аның гына рәхмәте [булган Пәйгамбәре, Ислам һәм сөннәт] белән [бәхетле булсыннар], шуңа гына шатлансыннар. Ул [илаһи фазыл һәм рәхмәт] алар туплаганнардан яхшырак»;**

«Юныс», 10:58

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ ﴿١٠٧﴾

**«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек»;**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ ۚ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا ﴿٥٦﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. [Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәтләр һәм бәрәкәтләр яудыра, фәрештәләр исә аңа югары теләге белән дога кылып, шәрәф казана һәм аның зикере белән бәрәкәтләнәләр]. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

5. Билгеле булганча, шагыйрьләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп, аңа багышланган шигырьләр укыйлар иде. Пәйгамбәребез аларны хуплады, кылган эшләреннән канәгать калды, бүләкләр бирде һәм алар өчен күркәм дога кылды. Әгәр Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны мактаучылардан риза булган икән, нигә ул безнең заманда аның яхшы сыйфатлары хакында сөйләүчеләрдән канәгать булмас?

6. Мәүлидне уздыру дин турында, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы, могҗизалары турында белем таратуга ярдәм итә, аңа ышануны көчәйтә һәм аңа булган мәхәббәтне арттыра.

7. Мәүлид мәҗлесләре кешеләрне күркәм максат белән җыя, Аллаһыны зикер итү, садака тарату, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә

сәлләмне олылау, аңа салаватлар әйтүне үз эченә ала. Болар барысы да сөннәт гамәлләр һәм шәригать буенча алар өчен әҗерләр вәгъдә ителгән.

Чиксез кодрәтле Аллаһы безнең йөрәкләребездә Үзенең сөекле Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мәхәббәтебезне арттырсын, Ислам диненең чын галимнәреннән белем алырга һәм шушы белемнәребезне тормышта кулланып, башкаларга да ирештерергә насыйп итсен!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», - дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әхмәт хәзрәт Фәйзуллин,*

*«Иман нуры» мәчетенең икенче имамы*

# Фәтвалар

# Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фәтвалары

*Фәтвалар чыгару Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора. Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә гаилә хокуклары, сәүдә-милек мөнәсәбәтләре, гыйбадәт кылу тәртипләре, хәләл, хәдис гыйлеменә кагылышлы, мөселманнар өчен мөһим һәм көнүзәк мәсьәләләр буенча бик күп дини карарлар чыгарылды. Фәтвалар өчен темалар Татарстан мөфтиятенең «Даруль ифта» мөселман call-үзәгенә килеп ирешкән иң еш бирелә торган сораулар буенча һәм Татарстан мөселманнарының хәзерге вакытка актуаль булган проблемаларыннан чыгып формалаша. Сезнең игътибарыгызга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның берничә фәтвасын тәкъдим итәбез. Алга таба да бу сәхифә дәвам итәчәк.*

# Аллаһыны мәхлүкатларының сыйфатлары белән тасвирларга ярыймы?

**Сорау:** Аллаһыны мәхлүкатларның сыйфатлары белән тасвирларга ярыймы? Ни өчен Аллаһы Үзенең мәхлүкъларына охшый алмый?

**Җавап:** Мәрхәмәтле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Тәгаләне яратылган мәхлүкъларны тасвирлаган мәгънәләр белән тасвирларга ярамый, әмма шул ук сүзләр белән тасвирларга мөмкин. Бу хакта имам Әбү Габдулла Әл-Куртуби (671 елларда вафат булган) болай дип язган:

لأن الشيئين لا يشتبهان لاشتباه أسمائهما في اللفظ وإنما يشتبهان بأنفسهما أو بمعان مشتبهة فيهما

«Ике әйбер бер-берсенә атамалары охшаш булу аркасында түгел, ә үзләреннән-үзләре яки үзләрендәге мәгънәләр аркасында охшаган» («Әл-Әснә фи шәрх әсмәиләһи әл-хүснә вә сыфәтиһи», 8 б, Мәктәбә Әл-Әсрийя, 2005).

Мәсәлән, кешене дә, Аллаһыны да «белүче» дип атарга була, бу очракта бер үк сүз кулланыла, әмма белемнең асылы һәм мәгънәсе Аллаһы Тәгаләгә һәм кешегә карата төрлечә килә.

Шуңа күрә имам Әбү Җәгъфәр Әт-Тахави (321 елларда вафат булган) үзенең мәшһүр «Гакыйдә»сендә болай дигән:

وَمَنْ وَصَفَ اللَّهَ بِمَعْنًى مِنْ مَعَانِي الْبَشَرِ فَقَدْ كَفَرَ

«Һәм кем дә булса Аллаһыны кешеләргә хас булган мәгънәләр белән тасвирласа, шул көферлеккә төшәр», ягъни, сүзләр белән түгел, нәкъ менә мәгънәләр белән: Аллаһыга карата мәхлүкъларны тасвирлаган мәгънәләрне кулланырга ярамый.

Имам Гомәр Ән-Нәсафи (537 елларда вафат булган) «Гакаид ән-Нәсафийя»дә болай дип яза:

ليس بعرض، ولا جسم، ولا جوهر، ولا مصور، ولا محدود، ولا معدود، ولا متبعض، ولا متجزئ، ولا متناه، ولا يوصف بالماهية، ولا بالكيفية، ولا يتمكن في مكان، ولا يجري عليه زمان، ولا يشبهه شيء، ولا يخرج عن علمه وقدرته شيء

«[Аллаһы] акциденциягә [гәүдә сыйфаты] дә, гәүдәгә дә, субстанциягә дә ия түгел. Аның кыяфәте юк, Ул чикләнмәгән, күпчелеккә ия түгел, кисәкләрдән тормый һәм кисәкләргә бүленми, беркайчан да бетми. Ул [мәхлүкат] кебек сан һәм сыйфат белән бәйле тасвирламалар белән сурәтләнми, урын биләми, вакыт белән бәйле түгел. Бернәрсә дә Аңа охшаш түгел, һәм Аның белемнәре [күзәтчелегеннән] һәм Аның кодрәте [хакимиятеннән] бернәрсә дә чыкмый».

Гакыйдә буенча китапларда әлеге мәгънәләрнең барысын да Аллаһы Тәгаләнең «мүхаләфәтуһу лил-хавәдис» (ягъни «яратылганнардан аермасы» яки «мәхлүкъләр белән охшаш булмау») дигән сыйфатына (атрибутларына) кертәләр.

Әмма рациональ күзлектән караганда да, мантыйк ягыннан, Раббыбызның мәхлүкатлар белән бернинди дә уртаклыгы булмавын дәлилләргә мөмкин. Киләсе дәлилне карап китик:

1. Галәмдәге һәр нәрсәнең үзеннән тыш сәбәбе бар (балаларның үз ата-аналарында сәбәпләре бар, детальләрне заводта ясыйлар һәм башкалар);

2. Үзеннән тыш сәбәпкә ия булган әйберләрдән торган галәм үзе дә үзеннән тыш сәбәпкә ия булырга тиеш;

3. Галәм – энергиягә ия булган, вакыт белән урында бар булган материя. Димәк, галәмнең сәбәбе шушы дүрт категориядән тыш булырга тиеш.

Аллаһыга охшамаганлык шулай ук хәзерге заман фәнни теорияләр белән дә раслана. Танылган инглиз фәлсәфәчесе, гомеренең ахырында атеизмнан баш тартып, Аллаһыга иман китергән Энтони Флю (1923 – 2010) үзенең «Аллаһы бар» дигән китабында, галим Брайан Лефтоу сүзләрен китереп, болай дип яза:

«Нисбәтлелек теориясе буенча, вакыт белән бәйле булган бар нәрсә дә шулай ук киңлек белән дә бәйле. Бу – бары тик дүрт үлчәмле континуум гына. Аллаһы бу киңлектә туры мәгънәдә була алмый. Әгәр Ул киңлектә юк икән һәм вакытта булган бөтен нәрсә киңлектә дә бар икән, димәк, Ул вакыт эчендә юк».

Һәм Аллаһы яхшырак белүчедер.

# Намазда бишенче рәкәгатькә бассаң, нишләргә?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм. Ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде. Кичә мин өйлә намазын укыганда, дүртенче рәкәгатьтән соң, онытылып китеп, өченче рәкәгать дип уйлап, киләсе рәкәгатькә басканмын. Аннары гына моның бишенче рәкәгать икәне башыма килде. Аннары, мин намаздан чыгып, аны кабаттан укыдым, чөнки нишләргә кирәк икәнлеген белмәдем. Бу мәсьәләгә ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде.

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәлам вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Имам Кудури рахмәтуллаһи галәйһи «Мохтәсар Әл-Кудури» хезмәтендә болай дип яза:

و من سها عن القعدة الأخيرة فقام إلى الخامسة رجع إلى القعدة ما لم يسجد و ألغى الخامسة و يسجد للسهو و إن قيد الخامسة بسجدة بطل فرضه و تحوَّلت صلاته نفلا و كان عليه أن يضم إليها ركعة سادسة. و إن قعد في الرابعة قدر التشهُّد ثم قام و لم يسلِّم يظنها القعدة الألى عاد إلى القعود ما لم يسجد في الخامسة و يسلِّم و إن قيد الخامسة بسجدة ضم إليها ركعة أخرى و يسجد للسهو و قد تمت صلاته و الركعتان له نافلة و سجد للسهو. (مختصر القدوري/ كتا الصلاة/ باب السجود السهو)

«Соңгы утыруда ялгышкан (ягъни гомумән соңгы утыруны башкармаган) кеше, (ялгышлык белән) бишенче рәкәгатькә басып, әгәр ул бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен үтәргә өлгермәгән булса, утыруга кире кайтырга тиеш; аннары ялгышлыктан соң үтәлә торган сәҗдә-и сәһү кыла, бишенче рәкәгать укылмый. Әгәр ул бишенче рәкәгатьтә сәҗдә кылып өлгергән булса (ягъни исенә төшергәнче бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен

үтәргә өлгерсә), аның фарыз намазы юкка чыга һәм ул нәфел намазына әверелә һәм аңа алтынчы рәкәгатьне өстәргә кирәк. Әгәр намаз укучы кеше дүртенче рәкәгатьтән соң «Әттәхият» дәвамлылыгында утырса, һәм шуннан соң, бу беренче утырудыр дип, сәлам бирмичә торса, ул бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен башкарганчы кәгъдәгә кайта (аннары сәҗдәи сәһү башкара). Әгәр ул бишенче рәкәгатьне сәҗдә белән башкарырга өлгергән булса, аңа тагын бер рәкәгать һәм сәҗдәи сәһү өсти, аның фарыз намазы дөрес була, ә ахыргы ике рәкәгате аның өчен нәфел намазы була».

Сезнең очракта, искә төшерүгә үк, кабаттан утырырга һәм, сәҗдәи сәһү кылып, намазны тәгәлләргә кирәк иде.

Аллаһы яхшырак белүчедер.

# Тәсбихне кайчан әйтергә – фарыз яки сөннәт намаздан соңмы?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм! Берничә ел түбәндәге хәлне күзәтәм. Имам һәм мәчеткә йөрүче калган кешеләр тәсбихне сөннәт намаздан соң әйтсә дә, кайбер мөселман кардәшләребез фарыз намаздан соң ук тәсбих әйтергә тотына. Элек бу хәлгә игътибар бирмәскә тырыштым. Алар башка мәзһәбкә иярүчеләр булырга мөмкин дип уйладым. Әмма, бервакыт, аларның берсе актив агитация алып бара башлады, имештер, имам дөрес эшләми, бу – бидгать дип белдерде. Һәм алар кебек эшләргә, ягъни фарыз намаздан соң тәсбих әйтергә кирәк, диде. Мин бөтенләй буталып беттем. Зинһар өчен, бу мәсьәләгә ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде. Рәхмәт.

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәлам вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Әйе, дөрестән дә, кызганыч, әмма мондый күренешләр булырга мөмкин. Гыйлем җитмәү һәм күп нәрсәләрне дөрес аңламау нәтиҗәсендә, кайбер кешеләр дини сорауларны үзләренчә аңлатырга тотына. Алай гына да түгел, алар өммәттә танылу алган чын галимнәр тапшырган белемнәрне кире кагып, абсолют хакыйкатькә дәгъва кыла башлый.

Әлеге сорауга җавап бирү өчен, сезне иң әүвәл галимнәребезнең методологиясе белән таныштырырга телибез. Аннары мөһим нәтиҗәләр чыгару мөмкин булачак.

Әлеге теманы тикшереп, имам Ибне Габидин рахимәһуллаһи болай дигән:

(قوله ويكره تأخير السنة إلا بقدر: اللهم أنت السلام الخ.) لِمَا رَوَاهُ مُسْلِمٌ وَالتِّرْمِذِيُّ عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ «كَانَ رَسُولُ اللَّهِ – صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ – لَا يَقْعُدُ إلَّا بِمِقْدَارِ مَا يَقُولُ: اللَّهُمَّ أَنْتَ السَّلَامُ وَمِنْك السَّلَامُ تبَارَكْت يَا ذَا الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ» وَأَمَّا مَا وَرَدَ مِنْ الْأَحَادِيثِ فِي الْأَذْكَارِ عَقِيبَ الصَّلَاةِ فَلَا دَلَالَةَ فِيهِ عَلَى الْإِتْيَانِ بِهَا قَبْلَ

السُّنَّةِ، بَلْ يُحْمَلُ عَلَى الْإِتْيَانِ بِهَا بَعْدَهَا؛ لِأَنَّ السُّنَّةَ مِنْ لَوَاحِقِ الْفَرِيضَةِ وَتَوَابِعِهَا وَمُكَمِّلَاتِهَا فَلَمْ تَكُنْ أَجْنَبِيَّةً عَنْهَا، فَمَا يُفْعَلُ بَعْدَهَا يُطْلَقُ عَلَيْهِ أَنَّهُ عَقِيبَ الْفَرِيضَةِ. وَقَوْلُ عَائِشَةَ بِمِقْدَارِ لَا يُفِيدُ أَنَّهُ كَانَ يَقُولُ ذَلِكَ بِعَيْنِهِ، بَلْ كَانَ يَقْعُدُ بِقَدْرِ مَا يَسَعُهُ وَنَحْوَهُ مِنْ الْقَوْلِ تَقْرِيبًا، فَلَا يُنَافِي مَا فِي الصَّحِيحَيْنِ مِنْ «أَنَّهُ – صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ – كَانَ يَقُولُ فِي دُبُرِ كُلِّ صَلَاةٍ مَكْتُوبَةٍ: لَا إلَهَ إلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، اللَّهُمَّ لَا مَانِعَ لِمَا أَعْطَيْت وَلَا مُعْطِيَ لِمَا مَنَعْت وَلَا يَنْفَعُ ذَا الْجَدِّ مِنْك الْجَدُّ» وَتَمَامُهُ فِي شَرْحِ الْمُنْيَةِ، وَكَذَا فِي الْفَتْحِ مِنْ بَابِ الْوِتْرِ وَالنَّوَافِلِ. ابن عابدين

Автор сүзләре: сөннәт намазын «Аллаһүммә...» сүзләрен әйтер өчен таләп ителгән вакыт аралыгына калдырып тору» Гайшә радыяллаһу ганһәдән килә, әлеге хәдис Әл-Мөслим һәм Әт-Тирмизи җыентыкларында урын алган, ул түбәндәгеләрне әйткән:

«Аллаһы Расүле (сөннәт алдыннан фарыз намазны үтәгәннән соң) әлеге доганы укыр өчен кирәк булган вакыттан да күбрәккә утырмаган:

اللَّهُمَّ أَنْتَ السَّلَامُ وَ مِنْكَ السَّلَامُ تبَارَكْتَ يَا ذَا الجَلَالِ و الإِكْرَامِ

«Аллаһүммә энтәс-сәләәмү вә минкәс-сәләәм табәәрактә йә ẕәлҗәләәли вәл-икраам».

Тәсбихфарызнамаздансоңкылынутурындахәбәрителгәнхәдисләргә килгәндә, бу гамәлнең сөннәтне үтәр алдыннан эшләнүе әйтелми. Мондый хәдисләрдән аңлашылган дөрес мәгънә шулдыр ки: тәсбих сөннәт намазны үтәгәннән соң башкарылган, чөнки сөннәт турыдан-туры фарыз намаз белән бәйле булып тора һәм аны тулыландыра. Сөннәт шулай ук фарыз намаздан аерым булып тормый. Шул сәбәпле, сөннәттән соң башкарыла торган барлык гамәлләр фарыздан соң килә торган гамәл

булып тора. Моннан тыш, Гайшә радыяллаһу ганһә вакыт аралыгын да искә ала. Димәк, әлеге хәдистән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм (һәрвакыт) нәкъ менә шул сүзләрне әйтүе хакында белдерелми. Мөгаен, бу хәдис Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм (фарыз намазны үтәгәннән соң), әлеге сүзләрне әйтү өчен, җитәрлек булган вакыт аралыгына игътибар юнәлтә. Шулай итеп, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәрбер фарыз намазны үтәгәннән соң түбәндәге сүзләрне әйтүе хакында сахих хәдисләрнең ике җыентыгында килгән мәгълүматка берничек тә каршы килми:

لا  إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ
اللَّهُمَّ لَا مَانِعَ لِمَا أَعْطَيْت وَلَا مُعْطِيَ لِمَا مَنَعْت وَلَا يَنْفَعُ ذَا الْجَدِّ مِنْك الْجَدُّ

«Игълә Әссүнән» дип аталган хезмәттә имам Зәфар Әхмәд Госмани рахимәһуллаһи болай дигән:

إعلاء السنن: قلت: والظاهر أنه صلى الله عليه وسلم كان يأتي دبر الصلاة بواحد من الأذكار، فروي كل راو بما سمع وأما احتمال أنه كان يأتي بجميع الأذكار الواردة في دبر الصلاة كل يوم بعد كل صلاة فبعيد جدا، كما لا يخفى على من له أدنى فهم، فحديث عائشة محمول عندنا على فرض بعده سنة، والأحاديث التي ورد فيها الذكر الطويل دبر الصلاة محمولة عندنا على فرض ليس بعده سنة راتبة، وإن كان بعده سنة فبعد الفراغ منها. وبهذا تجتمع أحاديث الباب بأسرها. ووجه الفرق أن الراتب من توابع الفرائض، فينبغي أداؤها متصلة بها كما هو مقتضى التبعية، ولما ثبت من الأمر بالتعجيل في بعض الرواتب كما سيأتي فالتطبيق (بين أحاديث الباب) بالوجه الذي ذكرنا هو الأولى. وهذا هو الأمر الرابع من الأمور العشرة فتذكر.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәр намаздан соң зикернең кайсы да булса бер төрен әйтүе ачык булып тора (алар хакында без югарыда сүз алып барган идек). Тапшыручыларның һәрберсе аңа ишетү насыйп булган зикер төре турында хәбәр иткән. Пәйгамбәребезнең һәрбер намаздан соң төрле хәдисләрдә телгә алынган барлык төр зикерләрне әйтеп чыгу ихтималлыгы – бик аз. Әлеге факт һичьюгы аз гына булса да аңларга теләге булган теләсә кем өчен ачык. Гайшә радыяллаһу ганһәдән килгән хәдистән аңлашыла торган мәгънә фарызны укыганнан соң сөннәтләре үтәлә торган намазларга күрсәтә (биредә фарызны укыганнан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәлам догасын уку өчен кирәк булган вакыттан да күбрәк утырып тормыйча, сөннәтне үтәргә керешкән). Ә намаздан соң озак зикер кылу хәбәр ителә торган хәдисләрдә фарыздан соң сөннәтләр укылмый торган намазлар турында әйтелә, әгәр фарыздан соң сөннәт булса, зикер сөннәттән соң әйтелә. Шулай итеп, барлык хәдисләр дә, берләштергәннән соң, бер мәгънәгә күрсәтәләр. Фикер каршылыкларының асылы шунда ки: сөннәт намаз турыдан-туры фарыз намазга бәйләнгән, ул фарыз намаз белән бергәлектә башкарыла, бәйлелек бар, сөннәтне үтәүгә ашыгу кирәклеге раслана. Димәк, мондый тәҗрибә (ягъни күрсәтелгән тема буенча барлык хәдисләрне куллану тәҗрибәсе) иң дөресе булачак, бу хакта без югарыда әйтеп уздык.

Нәтиҗә:

1. Нинди дә булса дини-хокукый мәсьәләне караганда, хәнәфи мәзһәбе нигезендә, аерым хәдисләрне генә түгел, ә Аллаһы Расүленә барып тоташкан барлык мәгълүматны да исәпкә алырга кирәк. Юкса, безнең хөкем (хокукый норма) эшләрнең чын торышын чагылдырмаячак.

2. Югарыда китерелгән хәдисләрдән шунысы аңлашыла: фарыздан соң сөннәте булмаган намазларны укыгач, тәсбихне фарыздан соң башкарырга кирәк. Ягъни, иртәнге һәм икенде намазларыннан соң тәсбих фа-

рыздан соң ук, имам «сәлам» догасын укыгач ук кылына. Ә фарыздан соң сөннәтләр укыла торган намазларда, без, фарыз намазны укыганнан соң, «сәлам» догасын укыйбыз, сөннәт намазны башкарабыз, ә аннары тәсбих әйтәбез. Мондыйларга өйлә, ахшам һәм ястү намазлары керә.

3. «Сәлам» догасы урынына төрле хәдисләрдә китерелгән кайсы доганы укысаң да була.

Ә Аллаһы яхшырак белүче.

# Үрнәк затлар

# Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи

## Тууы һәм әти-әнисе

Табигыйн, олуг галим, дин белгече Хәсән бине Йәсәр Әл-Басри һиҗри буенча 21 нче елны (642 нче елда) Мәдинә шәһәрендә дөньяга килгән. Аның әтисе – Йәсәр, Пәйгамбәребезгә килгән вәхине язып баручы, олуг сәхабә Зәед бине Сәбит радыяллаһу ганһенең колы булган. Йәсәр Ислам динен кабул иткәннән соң, Зәед бине Сәбит радыяллаһу ганһе аны азат иткән. Ә әнисе – Хайра, мөэминнәрнең аналары булган Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһәнең азат ителгән кол хатыны булган.

Пәйгамбәребезнең хатыны Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһәгә азат ителгән колы Хайраның бала тапканы хакында хәбәр килгәч, ул бик куанган һәм аның күркәм йөзе яктырып киткән. Ул Хайраны баласы белән аның өенә алып килүләрен сорап кеше җибәргән. Күпмедер вакыттан соң кулына сабый күтәреп Хайра килеп кергән. Бала бик тә сөйкемле һәм нурлы булган. Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә аның әнисеннән: «Син аңа исем куштыңмы?» – дип сораган. Хайра: «Мин бу эшне сиңа калдырдым», – дип әйткән. Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә: «Димәк, аңа Әл-Хәсән исемен бирәбез», – дигән.

## Балачагы, алган тәрбиясе һәм гыйлеме

Хәсән Әл-Басри мөэминнәрнең әнисе Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһәнең өендә тәрбияләнеп үскән. Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә әле җәһилият чорында ук укый-яза белгән, үзенең гыйлеме белән танылган хатын-кыз булган, аның тарафыннан бик күп хәдисләр тапшырылган. Аларның саны 387 дән артык дип хәбәр ителә. Әлбәттә, шуңа да Хәсән Әл-Басри кечкенәдән бәрәкәтле, гыйлемгә бай булган йортта үскән. Әле

бала вакытында ук, Өмме Сәләмә аны олуг сәхабәләргә алып килә торган булган һәм алар кечкенә Хәсән өчен Аллаһыга дога кылганнар.

Берьюлы кечкенә Хәсәнне хәлиф Гомәр радыяллаһу ганһе янына алып килгәннәр һәм ул аны кулына алып: «Йә Аллаһы! Аңа диндә дөрес аңлау бир һәм аны кешеләр яратсын», – дип дога кылган. Һәм, чыннан да, Хәсән Әл-Басри табигыйннәр арасында иң гыйлемлеләрнең берсе булган һәм кешеләр дә аны яраткан. Ул Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб, Әбү Муса Әл-Әшгарый, Габдулла бине Гомәр, Габдулла бине Габбас, Мәлик бине Әнәс һәм башка олуг галимнәрдән гыйлем алган. Хәсән Әл-Басри югары әхлакка ия булган һәм йөрәкләре Аллаһыга карата сөю белән тулган кешеләр җәмгыятендә тәрбияләнеп үскән.

Һиҗри буенча 37 нче елны Хәсән бине Йәсәрнең гаиләсе Басра шәһәренә күчеп киткән. Һәм шул вакыттан бирле галим Хәсән Әл-Басри дип атап йөртелә башлаган.

## Хәсән Әл-Басри – калебләрнең дәвалаучысы

Хәсән Әл-Басри кешенең күңелендә тәкъвалык, Аллаһыны сөю, мәрхәмәт, оят һәм башка күркәм хисләр булмаса, аның диндәге гыйлеменнән файда аз булуын аңлаган. Ул динне белеп тә, Шәригатьне аңлап та, Коръәнне укып та мөселман кешесенә хас булмаган гамәлләрне кылучыларны күп күргән. Шуңа да Шәригать фәннәрен тарату белән берлектә калебләрне дәвалауга юнәлдерелгән фәннәргә зур игътибар юнәлткән. Хәсән Әл-Басри суфичылык фәненә нигез салучыларның берсе булган, киләсе гасырдагы күп кенә остазлар суфичылыкны өйрәтүдә нәкъ менә аңа барып тоташа. Хәсән Әл-Басри бернинди дә яңалык уйлап чыгармаган, ул бары тик кешеләрне ихласлыкка, сафлыкка, калебләрнең төзеклегенә чакырган.

Әйе, кешеләр арасында дөнья байлыгына өстенлек бирү артса да, бу гасыр чисталык вакыты булган, кешеләр галимнәренең сүзләренә колак

салган, аларны хөрмәт иткән. Кызганычка, бүгенге көндә без боларның киресенчә булуын күрәбез. Кешеләр бераз гына гыйлемгә ия булса, бәхәскә керә башлый, аларны бәхәстән, үз фикерләрен өстен чыгарудан башка берни дә кызыксындырмый, алар хәтта олуг галимнәрне тәнкыйтьләүдән дә оялмый. Әмма үзләре башкаларны камилләштерү, аларның калебләренә изгелек орлыклары салу өчен бернинди дә тырышлык куймый. Бу хәлләр бик кызганыч.

Хәсән Әл-Басри кешеләргә аларның күңелләренә үтеп керә торган нәсыйхәтләр белән мөрәҗәгать итә торган булган. Ул җыйган мәҗлесләрдән кешеләр бик нык тәэсирләнеп, калебләре пакьләнеп чыккан. Галим белән бер чорда яшәгән берәү болай дип әйткән: «Хәсән Әл-Басри теге дөньяда булып кайтып, анда үз күзләре белән күргәннәрне сөйләүче кешегә тиң иде».

## Хәсән Әл-Басриның гыйлеме

Хәсән Әл-Басри төрле фән өлкәләрендә киң гыйлемгә ия булган. Басрада бик күпләр аның янына гыйлем эзләп килгән. Берәүләр хәдис өйрәнер өчен аңа мөрәҗәгать иткән, икенчеләр Коръән тәфсире хакында гыйлемнәргә ия булырга теләп килгән, башкаларның кайберсе күркәм сөйләмгә, кайберләре ихласлыкка ия булырга теләп, Хәсән Әл-Басри янына юнәлгән. Кем генә, нинди генә гыйлем эзләп, аның янына килсә дә, эзләгәнен табып, калебен разый иткән. Аның мәҗлесләрендә булучы һәркем Хәсән Әл-Басриның гыйлемнәренең тирәнлегенә соклана торган булган. Галим мәчеттә уздырган гыйлем бирү мәҗлесләреннән тыш, үзенең өендә дә очрашулар оештырган. Биредә ул Шәригать мәсьәләләре хакында сөйләмәгән, ә калебләрне пакьләү, ихласлылык, күркәм сыйфатларга ия булу мәсьәләләрен күтәргән. Бу мәҗлесләр һәркем өчен дә гаять зур файдага ия булган.

## Хәсән Әл-Басриның әхлагы һәм тәкъвалыгы

Тәкъва һәм ихлас, һәрдаим гыйбадәттә, гыйлем алуда һәм аны таратуда булса да, Хәсән Әл-Басри бик еш елый торган булган. Йәзид бине Хушаб Хәсән Әл-Басри белән Гомәр бине Габделгазиздән дә тәкъвалырак кешене күрмәве хакында әйткән.

Бер кеше Хәсән Әл-Басрига: «Дөреслектә, фәлән кеше синең хакта гайбәт сөйләде», – дип әйткән. Хәсән Әл-Басри бу кешегә яңа өлгергән хөрмәләрнең төрлесен җибәргән дә болай дип әйткән: «Дөреслектә, син миңа изгелекләреңне бүләк иттең. Мин сиңа бу изгелекләр өчен рәхмәтлемен. Ләкин син мине гафу ит, чөнки мин сиңа ул изгелегең өчен рәхмәт кылырга, ягъни аңа каршы бүләк бирергә кодрәтле түгелмен».

Шулай ук ул нәсыйхәт биреп, болай дигән: «Берәү сиңа кеше сүзен сөйләсә, бел, дөреслектә, ул синең сүзеңне дә синнән башкаларга ирештерәчәк».

Болай дип риваять ителгән: Хәсән Әл-Басри радыяллаһу ганһе бер егет яныннан үткәндә аның көлеп торганын күргән. Һәм ул егеттән: «Әй, улым, Сират күпереннән үттеңме?» – дип сораган. Егет: «Юк», – дигән. Хәсән радыяллаһу ганһе: «Синең җәннәткә яисә тәмугка кайтуың белендеме?» – дип сораган. Егет: «Юк», – дигән. Хәсән радыяллаһу ганһе: «Бу көлке нәрсә хакында соң?» – дип сораган. Моннан соң бу егет көлгән хәлдә күренмәгән. Ягъни Хәсән Әл-Басриның сүзе егетнең калебенә төшкән, ул егет көлүдән тәүбә иткән.

Ул заманда галимнәр бер үгет бирсә, аларның сүзе кешегә ирешә иде, чөнки алар гыйлем белән гамәл кылучылардан булдылар. Аларның гыйлемнәре башкаларга ярдәм итә иде.

## Галимнәрнең анты

Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи: «Аллаһы Тәгалә гыйлемгә ия булган ирләрдән ант алды һәм алар бернәрсәне дә яшермичә, кешеләргә хакыйкатьне ирештерер», – дип әйтә торган булган. Һәм ни генә булуга да карамастан, Хәсән Әл-Басри кешеләргә хакыйкатьне ирештерүдә тырышлык куйган. Ул, Ислам дөньясының иң явыз дошманнарының берсе булучы залим Хәҗәҗ бине Йосыф Әс-Сәкафи хакимлек иткән чорда яшәгән. Хәҗәҗ Гыйрак белән идарә итә башлагач, Басрадан ерак урнашмаган бер шәһәрдә зур сарай төзегән һәм шуны күрсәтер өчен, халык җыйган. Бар халык шунда агылган, алар арасында Хәсән Әл-Басри да булган. Әмма башкалардан аермалы буларак, аның бару максаты – кешеләрне дөнья зиннәтләренә алданмаска чакыру, аларны нәсыйхәтләү булган. Ул: «Моңа кадәр без иң начар кешеләрнең берсе булган Фиргавеннең биек бина төзүен һәм аннары аның Аллаһы тарафыннан һәлак ителүен күргән идек. Әгәр Хәҗәҗ аңа күкләр әһеленең игътибар итмәвен һәм җирдәгеләрнең аңа ялагайланып, аны алдавын белсә иде…», – дип сүз башлаган. Кешеләр арасында булган берәү, аның өчен куркып: «Җитәр, Әбү Сәгыйд!» – дип, аны туктата башлагач, ул: «Аллаһы Тәгалә гыйлемгә ия булган ирләрдән ант алды һәм алар бернәрсәне дә яшермичә, кешеләргә хакыйкатьне ирештерер», – дип җавап биргән.

Хөкемдар Хәҗәҗгә бу сүзләр килеп җиткәч, аның бик каты ачуы чыккан һәм юк бар нәрсә өчен дә кешеләрне җәзага тартырга күнеккән залим Хәсән Әл-Басри артыннан кешеләр җибәргән һәм галимне җәзага тарту урынын әзерләткән.

Хәсән Әл-Басри Хәҗәҗ янына килеп, җәлладны[1] һәм үзен җәзага тарту урынын күргәч, аның иреннәре нидер пышылдаган, әмма ул үз дәрәҗәсен саклап, залим каршына килеп баскан. Шулвакыт гаҗәп хәл булган: галимне һәлак итү теләге белән янган Хәҗәҗ урыныннан торып,

1 Палач.

галимне үз урынына утырткан һәм аңа дингә кагылышлы кайбер сорауларны бирә башлаган. Хәсән Әл-Басри олуг галим буларак, аның барлык сорауларына да җавап биргән. Моннан соң Хәҗәҗ зур ихтирам күрсәтеп, аны озаткан. Ул Хәҗәҗ яныннан чыккач, ишек сакчыларының берсе аннан: «Сине һәлак итәр өчен әзерләнгән җәза урынын күргәч, синең иреннәрең нидер пышылдады. Син нәрсә әйттең?» – дип сораган. Хәсән Әл-Басри: «Мин: «Раббым, хәсрәт вакытымда Синең рәхмәтеңне һәм ярдәмеңне сорыйм. Ибраһим өчен утны салкынча иткән кебек, Хәҗәҗ ачуын да минем өчен салкынча һәм имин кылсаң иде, дип дога кылдым», – дигән.

## Галимнең фани дөньядан китүе

Һиҗри буенча 110 нчы елның раҗәб ае башында, җомгага каршы төндә Хәсән Әл-Басри бакыйлыкка күчә. Бу вакытта аңа 89 яшь була. Җомга намазыннан соң, аңа җеназа намазы укыла һәм кешеләр олуг галимне соңгы юлга озатырга китә. Бу көнне Басраның Җәмигъ мәчетендә икенде намазы укылмый һәм бу хәл әлеге мәчетнең тарихында беренче мәртәбә була, чөнки шәһәр халкының барысы да хөрмәтле остазын соңгы юлга озатырга чыга, шәһәр буш кала.

*Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# Апрель

## Казан Җәмигъ мәчетенең эскиз проектына халыкара конкурс игълан ителде

1 нче апрельдә Казанда Җәмигъ мәчетенең эскиз проектын эшләү максатыннан, халыкара бәйге игълан ителде. Җәмигъ мәчете комплексы төзелеше 2022 елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча төп федераль чаралар планына кертелгән. Казан шәһәрендә 10 000 кеше сыйдырышлы төп Җәмигъ мәчетен төзү башлангычы белән Диния нәзарәте исеменнән Татарстан мөселман өммәте чыкты.

Шәүвәл аеның 19 нчы көнендә, Казанда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү кысаларында, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның Җәмигъ мәчете төзелү урынында беренче җомга намазын үткәрде һәм мәчет төзелешенә истәлекле таш куелды. Ачык һавада узган әлеге чараларда Рәсәй Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хакимият органнары вәкилләре, Рәсәй мөфтиләре XII Бөтенрәсәй татар дин әһелләре форумына һәм юбилей тантаналарына илнең төрле почмакларыннан килгән имамнар, республика мөселман җәмәгатьчелеге катнашты. Ташта гарәп, татар, рус һәм инглиз телләрендә «Идел Болгарстанында Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан Җәмигъ мәчетен төзи башлауга багышлана» дип язылган.

## Питрәчтә Мәүлә Колый мирасын өйрәнү һәм саклау җыены узды

Шәгъбән аеның 29 нчы көнендә Питрәч районында XVII гасырның бөек татар суфый шагыйре һәм дин эшлеклесе Мәүлә Колыйның иҗади

мирасын өйрәнүгә һәм исемен мәңгеләштерүгә багышланган чаралар узды. Фәнни җыен Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлап үткәрелде. «II Питрәч фәнни-төбәкне өйрәнү укулары» Рәсәйкүләм конференция эшендә Рәсәйнең 12 төбәгеннән, Татарстанның 24 районыннан тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр, әдәбият белгечләре катнашты. Җыен кысаларында Мәүлә Колыйның туган җире – Чыты авылына керү юлында шагыйрь хөрмәтенә истәлек билгесе (стела) куелачак урынга киләчәк буыннарга мөрәҗәгать белән капсула салу тантанасы узды. Галимнәр конференциянең Яңа Шигали авылында узган пленар утырышында Мәүлә Колыйның мирасын өйрәнүгә караган актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышты, шагыйрьнең Татарстан, Идел-Урал төбәкләре, мөселман Көнчыгышы һәм Евразия илләренең рухи тормышына зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

## Нәзарәт башка дини оешмалар белән бергә Донбасска гуманитар ярдәм озатты

Рамазан аеның 6 нчы көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин йөкләмәсе буенча, аның халыкара мәсьәләләр буенча киңәшчесе Салих хәзрәт Ибраһимов, Дин тотучыларның хокукларын кысрыклаудан һәм ксенофобиядән яклау буенча Рәсәй Федерациясе Президенты каршындагы Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек советының динара эшче төркем вәкилләренең Донбасс өчен гуманитар ярдәм җыю акциясенә багышланган брифингта катнашты. Брифингтан соң дин әһелләренең эшче төркеме гуманитар йөкне озатып җибәрде. Акциядә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә Рәсәйнең башка традицион диннәр вәкилләре, хәйрия фондлары катнашты.

## Казанда дөнья чемпионы Айрат Кәлимуллин истәлегенә спортчылар ифтары узды

Рамазан аеның 12 нче көнендә Казанда мөселман спортчылары өчен махсус ифтар үткәрелде. Әлеге авыз ачу мәҗлесе «Туган авылым» милли-туристик комплексы җитәкчеләренең берсе, ТР грэпплинг Федерациясе президенты Радик Абдрахманов тарафыннан оештырылды. Беренче тапкыр йөздән артык спортчыны бер өстәлгә җыйган ифтар Рәсәй һәм Татарстан данын халыкара мәйданда күп тапкырлар яклаган, күпсанлы мөселман спортчыларын тәрбияләгән тренер Айрат Кәлимуллин истәлегенә багышланды.

## Болгарда Коръәнне хәтем кыла башлауга 2500 көн тулды

Рамазан аеның 16 нчы көнендә татар хафизлары тарафыннан Болгарда Коръәнне өзлексез хәтем кылу – Изге Китапны башыннан алып ахырына кадәр укый башлауга 2500 көн тулды. Болгар шәһәрендә Коръән 2015 елның 14 июнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән хәтем кылына башлады. «Ак мәчеттән» алдарак, Коръән хәтем кылуны 2015 елның 2 нче гыйнварында Камил хәзрәт Казанның «Кол Шәриф» мәчетендә башлап җибәрде һәм Рамазан аеның 14 нче көнендә бу мәчеттә Коръән укыла башлауга 2660 көн тулды. Хәтем кылу, биш вакыт намаз укудан кала, бер көнгә дә тукталмады.

## Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды һәм Казан епархиясе качакларга ярдәм күрсәтте

Рамазан ае башында Диния Нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Донецк һәм Луганскттан Казанга килгән, вакытлыча яшәү өчен оештырылган 4 урында тормыш башлап җибәргән качакларга гуманитар ярдәм

тапшырды – 462 кешегә көндәлек кирәк-яраклары, шәхси гигиена һәм көнкүреш химиясе әйберләре таратылды. Гуманитар ярдәмне шулай ук Казан епархиясе дә күрсәтте.

## «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 9 нчы чыгарылышында 90 кеше намазга басты

Рамазан аеның 18 нче көнендә Казанда Нәзарәтнең иң мөһим проектларыннан берсе – намаз укырга өйрәтү һәм Ислам нигезләре белән таныштыру буенча «Ислам. Беренче адымнар» дип исемләнгән кыска вакытлы курслар тәмамланды. Шәкертләр 6 атна дәвамында «Сира», «Гакыйдә» фәннәре һәм тәһарәт, намаз, ураза, хаҗ гамәлләре буенча гыйлемнәрне колачлаган курсны үзләштерде. Башка еллардан аермалы буларак, бу чыгарылышта гаиләләре белән белем алучылар да күп булды. «Ислам. Беренче адымнар» проектының 9 нчы курсын 90 кеше тәмамлады. Барлыгы әлеге курсларда 840ка якын кеше белем алды һәм намазга басты.

## Нәзарәт Туган тел көнендә «Без – татарлар!» онлайн-платформасын ачып җибәрде

26 нчы апрельдә, Габдулла Тукайның туган көнендә, Диния Нәзарәте Татарстанда Туган тел көне уңаеннан «Без – татарлар» онлайн-платформасын ачып җибәрде. «Без – татарлар» – татар телен өйрәнү өчен яңа онлайн-платформа. Ул 2018-2021 елларда Татарстан мәчетләрендә уңышлы оештырылган курслар программасы һәм аларда кулланылган «Татар теле. Башлап өйрәнүчеләр өчен» уку әсбабы нигезендә «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан эшләнде. Beztatarlar.ru платформасын эшләүдә Рәсәй ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы мөдире вазифаларын башкаручы Венера Гарипова-Хәсәншина, тарих фәннәре кандидаты, РИИның татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы мөдире Рафилә

Гыймазова, педагогика фәннәре кандидаты, Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр Институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегенең татар теле белеме кафедрасы доценты Светлана Айдарова катнашты. Онлайн-ресурс сөйләм телен өйрәнү, ситуатив лексик җыелмаларын үзләштерү һәм аралашу күнекмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән. Курс программасында мөселман дини риторикасына һәм ислам терминологиясенә аерым игътибар бирелә.

## Мөфти 2022 елда хаҗ оештыру буенча утырышта катнашты. Татарстан өчен квота бүлеп бирелде

Рамазан аеның 28 нче көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәскәүгә эшлекле сәфәр кылды. Биредә РФ Федерация Советы бинасында РФ Хакимиятенең дини берләшмәләр мәсьәләләре Комиссиясенең хаҗ эшләре буенча вәкаләтле иясе Ильяс Умаханов рәислегендә 2022 елда хаҗны оештыру буенча киңәйтелгән утырыш узды. Аның эшендә мөфти, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Татарстанның «ДУМ РТ Хадж» рәсми хаҗоператоры җитәкчесе Ранис хәзрәт Вахитов, шулай ук Рәсәйнең хаҗ программаларын гамәлгә ашыручы башка дини оешма вәкилләре, федераль һәм региональ башкарма хакимият органнары вәкилләре катнашты. Согуд Гарәбстаны 2022 елда квоталар санын 1 миллионга кадәр кыскартты. Нәтиҗәдә Рәсәй мөселманнары өчен – 11 318 урын, шул исәптән, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә 810 урын күләмендә квота бирелде.

### Казанда Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы исеме белән 10 Республикакүләм ифтар узды

2022 елның 30 нчы апрелендә, Рамазан аеның соңгы кичендә, Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы исеме белән 10 Республикакүләм ифтар узды. Чарага Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та кушылды. Ифтар Диния нәзарәте, «Ак барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристик комплексы тарафыннан «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге ярдәме белән оештырылды һәм Татарстанның һәр почмагыннан 8 меңнән артык кунакны кабул итте. Ә барлык катнашучылар саны 9400гә җитте. Авыз ачу мәҗлесенә чакырылучылар арасында гади мөселманнар, мохтаҗлар һәм аз керемлеләр, җитәкчеләр, эшмәкәрләр, чит төбәкләрдән кунаклар, рәсми затлар бар иде. Мисал өчен, Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды карамагындагы коляскалы инвалидлар өчен махсус транспортта барып кайту, шулай ук авыз ачуда махсус урыннар оештырылды.

## Май

### Ураза гаетендә Казанда яңа «Әхмәтзәки» мәчете ачылды

Ураза бәйрәме көнендә, Казан шәһәре Залесный бистәсендә яңа иман йорты – XX йөз күренекле мөселман дин эшлеклесе Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин исемен йөрткән мәчет ачылды. Ул башкалабызның Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәтендә 16 нчы мәчет. Аны аеруча «Салават күпере» торак комплексында яшәүчеләр зарыгып көтте. Әлеге мәхәлләнең сөенечен бүлешергә һәм яңа мәчет белән танышырга республика һәм муниципаль хакимият органнары вәкилләре, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, дин әһелләре, мәхәллә халкы җыелды. Яңа мәчетне беренче булып күрүчеләр рәтендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов

та булды. Биредә беренче гает намазын Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин алып барды.

Мәчетнең ир-атлар өчен намаз уку залы 120 кешегә исәпләнгән. Биредә беренче катта тагын гардероб, ир-атлар өчен тәһарәтханә һәм шулай ук физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен аерым уңайлы юыну урыны бар. Икенче катта берничә уку бүлмәсе, никах залы, хатын-кызлар өчен исәпләнгән намаз уку урыны урнашкан. Мәчет комплексына шулай ук имам йорты, дини хезмәтләр күрсәтү бинасы, ислам әдәбияты һәм мәгърифәте йорты, хуҗалык бинасы, 73 машинага исәпләнгән парковка керә. Мәчет янәшәсендә корбан чалу урыны, хәләл азык-төлек кибете булдыру күздә тотыла, шулай ук мәетләр озату хезмәте каралган.

## Гает көнендә Казанда остазларны һәм мөселман дин әһелләрен искә алдылар

Шәүвәл аеның 1 нче көнендә Казан шәһәренең Яңа бистә зиратында Остазларны искә алу көне узды. Остазлар көне шәкертләр катнашында мәрхүмнәрне дога белән искә алу, шәхесләр турында бай мәгълүматны яшь буынга җиткерү максатыннан үткәрелә. Быел Ураза бәйрәменә туры килгән искә алу чарасында Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан мөфтиятенең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин белән беррәттән, татар милләтенә яхшы таныш шәхесләр – Искәндәр Гыйләҗев, Разил Вәлиев, Фоат Галимуллин, Данил Салихов, Ләбиб Лерон, Фәрит Мифтахов, Фуат Рәфыйков һ.б. катнашты.

## Татарстан мәчетләре Рамазан аенда 780 мең кеше, шул исәптән мохтаҗлар өчен ифтарлар уздырды

Рамазан аенда Диния нәзарәтенең барлык мөхтәсибәтләрендә дә ифтар мәҗлесләре оештырылды. Рамазан ае нәтиҗәләре буенча, Татарстанда Нәзарәт мөхтәсибәтләре тырышлыгы белән 780 мең кеше катнашында ифтарлар узды. 10 Республика ифтары бик зур мәҗлес булды, ә республика районнары арасында ифтарда катнашучылар саны буенча лидерлар рәтендә – Совет районы мөхтәсибәте (75000 кеше), Вахитов районы (65500 кеше), Түбән Кама (45105 кеше), Яшел Үзән районы (45000 кеше), Әлмәт (42000 кеше), Кукмара районы (33000 кеше), Буа районы (30000 кеше), Сарман районы (27600 кеше), Киров һәм Мәскәү районнары (27000 кеше). «Ярдәм – Помощь» хәйрия фонды 45000 кешегә авыз ачтырды. Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды, махсус хәйрия ифтарлары уздырып, 3725 мохтаҗны ашатты.

## «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны кысаларында Татарстанда 4 780 кешегә ярдәм күрсәтелде

Татарстанда Рамазан ае ел саен үткәрелә торган «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны химаясе белән узды. Әлеге акция Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителде. Рамазан ае катлаулы социаль-икътисади вәзгыять вакытына туры килүгә карамастан, быел Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды, марафон кысаларында битараф булмаган кешеләрдән акча җәлеп итеп, Татарстанның төрле район һәм шәһәрләрендә яшәүче 20 авыру балага тернәкләнү һәм дәвалау курсларын узарга мөмкинлек бирде. 1 400 000 сумнан артык фитр садакасы һәм фидия җыелып, күпбалалы гаиләләргә, балаларын ялгыз тәрбияләүче

аналарга, ялгыз гомер итүче өлкәннәргә һ.б. тапшырылды. 550 дән артык мохтаҗ гаилә 3,5 тоннадан артык азык-төлек белән тәэмин ителде. «Зәкят» хәйрия фонды оештырган 34 махсус хәйрия ифтарында бөтен республикадан 3725 мохтаҗ авыз ачты. Рамазан аенда шулай ук Луганск һәм Донецкидан килгән 462 качакка гомуми авырлыгы 310 кг булган шәхси гигиена әйберләре бирелде. Шулай итеп, Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны кысаларында барлыгы 4780 кешегә ярдәм күрсәтелде. Диния нәзарәте бу акциядә катнашкан битараф булмаган барлык кешеләргә һәм эшлекле партнерларына рәхмәт белдерә.

## Татарстан мәчетләрендә Хәтер көне узды

Шәүвәл аеның 13 нче көнендә Татарстан мәчетләрендә Хәтер көне уздырылды. Әлеге чара ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы тәкъдиме белән ел саен республиканың барлык мәчетләрендә һәм барлык теләүчеләр катнашында һиҗри буенча Шәүвәл аеның 13 нче көнендә искә алына. Хәтер көне башкалада зурлап «Кол Шәриф» мәчетендә Татарстанның барлык мөхтәсибәтләреннән аксакаллар һәм имам-мөхтәсибләр катнашында үтте. Нәзарәтнең Аксакаллар шурасы утырышында аның рәисе Айрат хәзрәт Әюпов 2021 елда башкарылган эшчәнлек буенча хисап тотты һәм 2022 елның икенче яртысына эш планы белән таныштырды. Утырыш нәтиҗәләре буенча резолюция кабул ителде.

Өйлә намазы вакыты керү белән җәмәгать намазы укылды. Аны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкләде. Аңа ияреп «Кол Шәриф»кә җыелган 100 дән артык кеше намаз укыды.

Хәтер көненең төп өлеше алга таба Казан ханнары җирләнгән урын янында дәвам итте. Шунысы игътибарга лаек, Казан ханнарының җәсәдләре бирегә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы тырышлыгы белән 2017 елда Ислам кануннарын саклап җирләнгән

иде. Хәтер көнендә каберлек янында «Йәсин» сүрәсе укылды, Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов Казанны алганда шәһит киткәннәр һәм динебез, халкыбыз һәм Ватаныбыз хакына һәлак булган татар халкының батырлары рухына дога кылды.

## Казанда 1100 еллык чараларын Халыкара Изге Коръән уку бәйгесе башлап җибәрде

Шәүвәл аеның 16 нчы көнендә Казанда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган тантаналар башланып китте: беренче булып Халыкара Изге Коръән уку бәйгесе тантаналы шартларда ачылды. Бәйге Казанда Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы программасы кысаларында узды. Аны Татарстан Хөкүмәте һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр форумы, шулай ук Яшьләр дипломатиясе академиясе, «Сәләт» Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый фонды, Татарстан мөфтияте һәм РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе оештырды. Ике көнлек бәйгедә чит илләрдән һәм Рәсәй субъектларыннан 50 кеше катнашты. Аның җиңүчеләрен Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бүләкләде. Бәйге нәтиҗәләре буенча ир-атлар арасыннан – 3 һәм хатын-кызлардан 3 иң яхшы Коръән укучы сайлап алынды. Бәя биргәндә, авазларны дөрес итеп уку һәм Изге Коръән сүрәләрен яттан белү сыйфаты искә алынды. Ир-атлар арасында бәйгедә Муса Гайтиев (Чечня, Рәсәй) җиңүче булды, икенче урында – Мәхмүт Халед Мәхмүд Суэйд (Мисыр) һәм өченче урында Хәмәд Абдулла Т.А. Алжумайлы (Катар). Хатын-кызлар арасында беренче урынны Деви Юкха Нидха (Индонезия), икенче урынны Исраа Мөхәммәд Эсам Салах (Палестина) һәм өченче урынны Хәлимә Абдинасир Әхмәд (Бөекбритания) яулады. Ә махсус призга Нигер егете Чафаат Иссуф Мәхәммәд лаек булды.

Бәйге жюри дәрәҗәсенең аеруча мәртәбәле булуы белән дә аерылып торды. Аның рәисе Берләшкән Гарәп Әмирлекләре дәүләт башлыгының

Коръән буенча комитет җитәкчесе, шәех Мәэмүн Шәәбән Хәлил Әр-Рави булды. Шулай ук жюри әгъзалары арасында Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Төркиянең иң зур «Чамлыҗа» мәчете имам-хатыйбы Исхак Даныш, Халыкара фикһ ислам академиясенең Фәтвалар идарәсе (IIFA) җитәкчесе, доктор Мөхәммәд Мостафа Шуәйб (Җиддә, Согуд Гарәбстаны), Төркия Республикасының Дин эшләре буенча Президиум әгъзасы, Коръән мосхафларына күзәтү ясау һәм декламация советы әгъзасы Йәшәр Җүхәдәр бар иде.

## KazanSummit-та Нәзарәт экспозициясе беренче тапкыр бүгенге татар дини илаһиятенең йөзек кашы – яңартылган «Казан басма»сын тәкъдим итте

Шәүвәл аеның 18-19 нчы көннәрендә «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданчыгында XIII Халыкара «Рәсәй – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» икътисад саммиты чаралары узды. Саммитның төп рәсми өлешен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ачып җибәрде – ул Изге Коръәннең «Әл-Мүддәссир» («Төренгән») сүрәсенең 32-47 аятьләрен укып, дога кылды. Моннан тыш, Саммит кысаларында Халыкара хәләл индустрия күргәзмәсе – «RUSSIA HALAL EXPO» ачылды. Татарстан мөфтияте күргәзмәдә үзенең экспозициясе белән катнашты. Экспозиция белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та танышып чыкты. Быел Диния нәзарәте экспозициясендә татар рухи мирасының аерылгысыз ике өлешен – динне һәм телне саклау һәм үстерү өчен булдырылган мөселман мультимедиа контенты тәкъдим ителде. Ягъни мөфтият мәйданчыгында Коръән белеме, мәгариф, нәшриятчылык, дини мирас һәм дәгъват өлкәсендә Нәзарәтнең виртуаль мөселман инфраструктурасын үстерә торган соңгы һәм иң мөһим IT-казанышлары күрсәтелде. Мисал өчен, экспозициядә онлайн-мәдрәсә һәм татар телен өйрәнү өчен

«Без-татарлар» интернет-платформасы, «Хозур ТВ» мөселман телеканалы, «Азан» радиосы, Коръәннең рус һәм татар телләрендәге мәгънәви тәрҗемәләре һәм башка мобиль кушымталар, шулай ук Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йортында басылып чыккан иң күп укыла торган басмалар белән танышырга мөмкин иде.

Күргәзмәнең концептуаль мәгънәсен тулысы белән татар рухи мирасының кыйммәтле ядкәре булып саналган «Казан басма»сы ачып бирде. Мәшһүр Коръән ике данәдә тәкъдим ителде – XIX гасыр басмасы һәм Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан яңартылган басма. Экспозициянең нәкъ үзәгендә урнашкан әлеге ике экспонат буыннар арасында рухи мирасның дәвамчанлыгын һәм Коръәнне бастыруның мәшһүр татар традицияләрен торгызуны гәүдәләндерә. Тарихи «Казан басма» үз вакытында мөселман дөньясында беренче басма Коръән булып, дини даирәдә фәнни танылу алса, яңартылган «Казан басма»сы – бүгенге халыкара стандартларга туры китерелеп һәм югары сыйфатта бастырылган хәзерге заман Казан белгечләренең хезмәт нәтиҗәсе. Моның өчен Нәзарәт тарафыннан «Казан басмасының» тарихи типографик эзеннән (оттискысыннан) шул ук исемдәге компьютер шрифты ясалды.

## Мөселманнар KazanSummit мәйданында халыкара «MuslimQuiz» уенында ярышты

XIII Халыкара «Рәсәй – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» икътисад саммиты мәйданчыгында ТР мөселманнары Дирия нәзарәте яшьләр өчен оештырган «MuslimQuiz» мөселманнары уеннары узды. Уенчылар тарих, икътисад, география, төрле телләр, медицина, сәнгать һәм башка мәсьәләләр буенча белемнәрен күрсәтте. Анда дөньяның төрле илләреннән: Рәсәй, Иордания, Таҗикстан, Үзбәкстан, Мисыр, Йәмән, Казахстан, Палестина, Индонезиядән 170 кеше катнашты. Рәсәй командасы составында КИУ, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, КДМУ, К(И)ФУ, КНИТУ, «Гос-

мания» мәктәбе, IT-лицей, Казанның «Адымнар – белемгә һәм татулыкка юл» полилингваль комплексы һәм башка уку йортларыннан белгечләр һәм студентлар бар иде.

## Яңартылган «Казан басмасын» һәм аның компьютер шрифтын бушлай йөкләп алу мөмкинлеге тудырылды

1100 еллыкны бәйрәм иткән көннәрдә Диния нәзарәте яңартылган «Казан басма»сының электрон нөсхәсен һәм компьютер шрифтын өммәтнең гомумкулланышына тапшырды. Аларны түләүсез рәвештә Нәзарәт сайтында уң як өлештәге махсус банерга басып йөкләп алу мөмкинлеге тудырылды.

Яңартылган «Казан басма» – Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы кысаларында Татарстан мөфтиятенең иң төп проектларының берсе, ул Коръән бастыруның мәшһүр татар традицияләре торгызылуын ачык дәлилли. «Казан басма» – 1803 елда «Ар-Расм Әл-Усмани» стандартына туры китереп Казанда басылган, бар мөселман дөньясында дини җәмәгатьчелек тарафыннан танылу алган беренче басма Коръән. «Казан басма», үзенчәлекле шрифтка ия булу сәбәпле, дөнья күләмендә таныла. Безнең чорда ул төрле елларда күп тапкырлар репринт сыйфатында басыла. Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 елында Нәзарәт белгечләре «Казан басма»сының тарихи типографик эзеннән (оттискысыннан) шул ук исемдәге компьютер шрифты ясады, аннары Коръән текстын «Казан басма» компьютер шрифты ярдәмендә яңадан җыйды һәм, революциягә кадәрге күренекле татар галимнәре Шиһабетдин Мәрҗани һәм Муса Бигиевның искәрмәләрен исәпкә алып, заманча халыкара стандартларга туры китереп әзерләде. Шулай итеп, яңартылган «Казан басмасы» инкыйлабка кадәрге оригинал шрифтларның чын тарихи йөзен саклап калды һәм югары сыйфатлы итеп бастырылды.

## Татарстан мөфтие «Рәсәй – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең XII утырышында катнашты

Шәүвәл аеның 19 нчы көнендә Казанда «Рәсәй – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең XII утырышы ачылды. Анда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Җыелыш Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган чаралар кысаларында узды. Стратегик караш төркеме очрашуында катнашучыларның төп темасы: «Этномәдәни күптөрлелекне, милләтара һәм динара татулыкны саклауның Рәсәй тәҗрибәсе – гомумгражданлык бердәйлеген ныгыту нигезе».

## 1100 еллыкны бәйрәм итү тантаналары кунакларына репринт «Казан басмасы» бүләк ителде

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган бәйрәмнең кунакларына Коръәннең репринт «Казан басмасы» бүләк ителде. Бу – Нәзарәтнең 1100 еллыкны бәйрәм итү кысаларында гамәлгә ашырыла торган проектларының берсе. «Казан басма» тарихи нөсхәсе ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган тантана кунакларына тапшыру өчен 4000 данә күләмендә бастырылды. Әлеге бүләк татар өммәтенең иң олы казанышы, мөселман мәдәниятен үстерүгә керткән иң саллы өлеше турында искә төшереп торачак.

## Татарстан мөфтие Бөтенрәсәй татар дин әһелләрен Коръәннең яңартылган «Казан басма»сы белән таныштырды

Шәүвәл аеның 19 нчы көнендә Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында «Милли тормыш һәм дин» XII Бөтенрәсәй татар дин әһелләре форумының пленар утырышы узды. Корылтай Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан Идел буе Болгарында Ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу датасы кысаларында оештырылды һәм Рәсәй Федерациясенең 76 төбәгеннән, 5 чит илдән 1100 дин әһелен һәм кунакларны җыйды. Форумның пленар утырышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Ул Рәсәйнең бөтен җәмәгатьчелегенә – мөселманнарга да, башка дин вәкилләренә дә, динне тотмаучыларга да Исламны кабул итүнең 1100 еллыгының әһәмиятенә төшенү мөһимлеген ассызыклады, әлеге тарихи датаның тирән мәгънәләре турында сөйләде һәм Коръәннең яңартылган «Казан басма»сы белән таныштырды.

## Болгарда 1100 еллыкның кульминацион тантанасы узды

Шәүвәл аеның 20 нче көнендә Болгарда Идел буе Болгар дәүләте тарафыннан рәсми рәвештә Ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан төп тантана – «Изге Болгар җыены» узды. Ул Болгар ислам академиясендә башланды, биредә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча федераль оештыру комитеты утырышы узды. Чараны видеоэлемтә буенча Рәсәй Хөкүмәте Рәисе урынбасары, федераль оештыру комитеты рәисе Марат Хөснуллин үткәрде. Утырышта Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру пла-

нын тормышка ашыру барышы белән таныштырдылар. Болгар ислам академиясендә шулай ук Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан истәлекле почта маркасына тантаналы рәвештә мөһер куйдылар. Почта блогында Ак мәчет һәм «Идел буе Болгарстанында Ислам динен кабул итүгә – 1100» дигән язу сурәтләнгән. «Беренче көн» конвертында рәссам К.А.Тиллиның «Борынгы Болгар. Кече манара. 1868 ел» дип язылган литографиясе чагылдырылган.

Рәсми утырыштан соң «Ислам динен кабул итү» Истәлек билгесе каршындагы мәйданда 1100 еллыкның кульминацион чарасын – «Изге Болгар җыены»н ачу тантанасы үткәрелде. Болгардагы төп бәйрәм чарасына 20 меңнән артык кеше килде. Ул Идел буе Болгар дәүләтенә ислам дине килүне һәм Әхмәд бине Фадлан юлын чагылдырган театральләштерелгән пролог белән ачылды. Рәсәйнең Баш мөфтие Тәлгать хәзрәт Таҗетдинга ияреп өйлә намазы укыганнан соң, 1100 еллыкны бәйрәм итү чарасы көрәш буенча дөнья Кубогына ярышлар, концерт программасы белән дәвам итте – җыелган халык алдында «Илаһи моң» рухи мирас әсәрләрен башкаручыларның төбәкара конкурсы лауреатлары һәм республиканың әйдәп баручы иҗат коллективлары, танылган рухи музыка башкаручылар чыгыш ясады. Моннан тыш, Изге Болгар җыены үткән тарихи тыюлык мәйданчыгында Татарстан мөфтияте күргәзмә оештырды: анда «Хозур» нәшрият йорты, «Хәләл» стандарты буенча Комитет, «ДУМ РТ Хаҗ» оешмасы, «Вакыф» фонды һәм Татарстан мөселман дини уку йортлары эшчәнлекләре чагылды.

## «Әхмәдзәки» мәчетендә беренче мәхәллә бәйрәме үтте

Шәүвәл аеның 21 нче көнендә Казанның «Әхмәдзәки» мәчетендә беренче тапкыр мәхәллә бәйрәме узды. Әлеге чарада Залесный бистәсендә һәм «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләр генә түгел, юби-

лей тантаналарына килгән хөрмәтле кунаклар да катнашты. Мәхәллә бәйрәмендә катнашучылар актив уеннар, күңелле стартлар, конкурсларда көч сынашты, татлы ризыклар, кайнар чәй һәм пылаудан авыз итте. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Рәсәйдә һәм халыкара дәрәҗәдә танылган хөрмәтле кунакларга мәчет комплексы буенча экскурсия үткәрде, аларның игътибарын әлеге мәчет исемен йөрткән күренекле татар дин әһеле һәм мәгърифәтче Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин музеена юнәлтте. Ул галимнең Рәсәйнең Баш мөфтие, Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдиннең һәм РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдиннең остазы булуын билгеләп үтте, кунакларга татар мәгърифәтчесенең шәхси әйберләрен күрсәтте. Аннан соң Камил хәзрәт Рәсәй мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары, Мәскәү өлкәсе мөфтие Рушан хәзрәт Аббясов, Карачай-Черкесия Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Төньяк Кавказ мөселманнары Координацион үзәге рәисе Исмаил хаҗи Бердыев һәм РФ мөселман эшкуарлары ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов белән эшлекле очрашулар үткәрде.

## Мамадышның Түбән Яке авылында яңа мәчет ачылды

Шәүвәл аеның 26 нчы көнендә Мамадыш районы Түбән Яке авылында «Мәкъсүт» мәчете ачылды. Ачылыш тантанасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Мәчет шушы авылда туып үскән, хәзер Мамадыш икмәк кабул итү пункты җитәкчесе булып эшләүче Рифат Мәкъсүт улы Мәхмүтов җитәкчелегендә кирпечтән төзелгән. Авыл халкы гыйбадәт йортына аның әтисенең исемен бирергә карар кылган. 250 кешегә исәпләнгән мәчет янәшәсендә балалар өчен мәйданчык, футбол, волейбол, баскетбол уйнау урыны бар.

## Гарәп массакүләм мәгълүмат чараларының игътибарын Коръәннең репринт «Казан басмасы» җәлеп итте

Коръәннең репринт «Казан басмасын» чыгару гарәп телле массакүләм мәгълүмат чаралары игътибарын җәлеп итте. Мисал өчен, бу хактагы хәбәрләрне актив рәвештә Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең үзәк массакүләм мәгълүмат чаралары таратты. Электрон газеталар, бөтендөньяга танылган дин галиме, Дубайның Изге Коръәнне әзерләү комиссиясе (DIHQA) башлыгы шейх Мәъмун Әр-Рави сүзләренә сылтама биреп, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Самигуллин тарафыннан Шарҗаның Коръәнне өйрәнү үзәгенә Изге Китапның 1803 елда «ташбасма» ысулы белән бастырылган бик сирәк басманың күчермәсе бүләк ителде дип хәбәр бирде. Язмаларда шулай ук гарәп үзәгенең генераль сәркатибе Шерзада Абдула Рахман Тахерның «Казан басмасының» дөньякүләм ислам мәдәниятендәге бик зур әһәмияткә ия булуы турындагы фикере дә китерелде.

Камил хәзрәтнең Берләшкән Гарәп Әмирлекләре мөселманнарына җибәргән кыйммәтле бүләге турындагы хәбәрләр «Шарджаньюс», «Альбаян», «Альхалидж», «Альвахданьюс», «ОАЭньюсапп», «Алехбария» һ.б. басмаларда чыкты. Алардагы язмалар репринт «Казан басмасы» фотосурәтләре белән бергә урнаштырылган.

## Казан мәчетләре балаларның җәйге каникулларын оештыра

Җәйге каникул чорында мәчетләрдә балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары оештырыла башлады. Күркәм гадәт буенча белем бирү, танып белү һәм күңел ачу чаралары кысаларында сабыйлар өчен кызыклы программалар әзерләнде. Ул әхлак һәм тәрбия, Ислам

нигезләре, Коръән дәресләрен, шулай ук күңелле чаралар: шаян уеннар, бәйгеләр, сабантуйларны һ.б. үз эченә ала.

### Мәчкәрә авылы тарихи мәчетен төзекләндерүгә акча җыю өчен сайт булдырылды

Татарстанның мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитеты тарихи мәчетләрне һәм чиркәүләрне торгызуга акча җыю өчен «Сохраняем ВМЕСТЕ!» акциясен игълан итте. Акция кысаларында беренче булып Татарстанның Кукмара районы Мәчкәрә авылының тарихи мәчетен төзекләндерү өчен акча җыю игълан ителде. 1791 елгы мәчеттә ремонт-реставрация эшләре 2022 елның мартында тантаналы рәвештә башланып китте.

Мәчкәрә авылының тарихи мәчете бары тик хәйрия акчаларына гына торгызыла. Бу максаттан naslediert.com адресы буенча интернет-сайт ачылды.

Мәчкәрә мәчете – XVIII гасыр азагына караган татар дини архитектурасының уникаль һәйкәле. Кызыл кирпечтән салынган ике катлы мәчет 1791-1793 елларда 1 нче гильдия сәүдәгәре, атаклы сәүдәгәрләр династиясенә нигез салучы Габдулла Үтәмешев акчасына төзелгән.

## Июнь

### Республика балалар клиник хастаханәсендә тантаналы төстә намаз уку бүлмәсе ачылды

Зөлкагъдә аеның 4 нче көнендә Балалар республика клиник хастаханәсенең Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургиясе үзәгендә намаз бүлмәсен ачу тантанасы узды. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Намаз уку бүлмәсе РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе тырышлыгы белән оештырыл-

ды. Гомумән алганда, хәзерге көндә Татарстанның барлык Үзәк район хастаханәләрендә намаз уку бүлмәләре бар. Моннан тыш, намаз уку өчен ике бүлмә Яр Чаллыда Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсендә эшли. Казанда зур медицина учреждениеләрендә шулай ук намаз бүлмәләре бар, алар МКДЦ, РКБ, ДРКБ, Республика клиник онкология диспансеры, 7 нче поликлиникада урнашкан. Намаз уку бүлмәләре ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре белән хезмәттәшлектә оештырыла.

## Артемий Лебедев Нәзарәтнең «Казан басмасы» турында сөйләде

Рәсәйнең танылган дизайнеры һәм блогер Артемий Лебедев үзенең YouTube-каналындагы яңалыклар чыгарылышында Коръәннең Татарстан мөфтияте тарафыннан яңартылган «Казан басмасы»н һәм аның компьютер шрифтын бушлай йөкләп алу өчен гомумкулланышка тапшыруы турында хәбәр итте. Автор үз каналына язылучыларга «Казан басмасы» тарихы турында сөйләде һәм шул ук исемдәге компьютер шрифтының дизайнерлык эшенә махсус бәясен дә бирде:

– Шунысы кызык, без никадәр параллель киңлекләрдә яшибез икән һәм кириллица һәм латиница белән эшләүче дизайнерлар гарәп шрифтлары һәм Коръән бастыруның татар традицияләре турында берни дә белми икән.

## Яңартылган «Казан басма»сының электрон нөсхәсен һәм компьютер шрифтын Нәзарәт сайтында түләүсез йөкләп алырга мөмкин.

Нәзарәт, Татарстан митрополиясе һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы хезмәттәшлек турында Генераль килешү имзалады

Зөлкагъдә аеның 7 нче көнендә Казанда ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы, ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм Татарстан митрополиясе арасында хезмәттәшлек турында Генераль килешү имзаланды. Документка ТР сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Казан һәм Татарстан митрополиты Кирилл, шулай ук епархиаль архиерей, Әлмәт һәм Бөгелмә епископы Мефодий кул куйды.

Килешү дини оешмаларның социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча мөмкинлекләрен исәпкә алып төзелде, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендәге хезмәтләрне үстерүне күздә тота.

## Камил хәзрәт Сәмигуллин Тәлгать хәзрәт Таҗетдин белән очрашты

Зөлкагъдә аеның 8 нче көнендә Казанда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Рәсәйнең баш мөфтие Тәлгать хәзрәт Таҗетдин белән очрашты. Болгарда Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан оештырылган төп тантаналардан соң беренче очрашу Яңа татар зиратын караудан башланды. Хәзрәтләр күренекле татар дин әһелләре каберләрен зиярат кылды. Биредә Тәлгать хәзрәтнең остазы, күренекле татар дин әһеле, мәгърифәтчесе һәм дин галиме Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин да җирләнгән.

Аннан мөфтиләр тагын бер истәлекле урында – Әхмәдзәки Сафиуллин хөрмәтенә атап салынган «Әхмәдзәки» мәчетендә булды. Камил хәзрәт мәртәбәле кунакка мәчет һәм аның комплексы буенча экскурсия үткәрде. Тәлгать хәзрәткә музейны һәм Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллинның шәхси әйберләрен күрсәтте.

## Нәзарәт, «Ихлас» мәчете һәм «Ирбис» ягулык салу станциясе Рәсәй федераль трассаларында намаз бүлмәләрен ача

Зөлкагъдә аеның 10 нчы көнендә «Мәскәү–Уфа» М7 федераль трассасының 710 нчы чакрымында «Ирбис» автомобильләргә ягулык салу станциясе территориясендә Рәсәй федераль трассаларында стационар намаз уку бүлмәләрен ачу буенча «Юлчы намазы» проектын гамәлгә ашыруга рәсми старт бирелде. Монда беренче намаз бүлмәсе ачылды. Тантаналы чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.

Бу проект ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең методик ярдәме белән тормышка ашырыла. Әлеге эшнең башлап җибәрүчесе – Татарстан Республикасы Лаеш районының Усад авылындагы «Ихлас» мәчете, шушы ук мәчеткә нигез салучы, «Тернәкләндерү һәм җәмгыятькә җайлаштыру үзәге» автоном коммерцияле булмаган оешма генераль директоры Азат Гайнетдинов. Төп партнер – «Транзит Сити» компанияләр төркеменә караган «Ирбис» автомобильләргә ягулык салу станцияләре.

Шул ук көнне М7 трассасының 350, 454 һәм 611 чакрымында тагын шундый ук 3 бүлмә ачылды.

## Нәзарәт делегациясе Казан ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл ачу тантанасында катнашты

Зөлкагъдә аеның 11 нче көнендә Татарстан нәзарәте делегациясе Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә Казан ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл ачу тантанасында катнашты. Һәйкәл РФ мөселманнары Диния нәзарәте башлангычы белән куелды. Идел буе Болгарында Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү кысаларындагы истәлекле чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мәртәбәле кунак булды, ул әлеге чараны Коръән аятьләрен укып башлап җибәрде.

Намаз вакыты җитү белән, тантаналы чараларда катнашучы кунаклар борынгы Хан мәчетендә җомга намазын укыды. РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин вәгазендә остазы, күренекле татар дин эшлеклесе Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллинны искә алды һәм аның хөрмәтенә Казанда «Әхмәдзәки» мәчете ачылуын әйтте, Камил хәзрәткә һәм мәчетне төзегән барлык дин кардәшләребезгә рәхмәт белдерде.

Бер көн элек, Касыйм шәһәрендә һәйкәл ачылу алдыннан, мөфтиләр Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Равил хәзрәт Гайнетдин очраштылар. Алар Идел буе Болгарында Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыру барышы турында фикер алышты.

# Тарих

# Рус миссионерларының татар муллалары хакында фикерләре

Урта Идел буе халыкларының этнографиясен һәм көнкүрешен өйрәнгәндә без җирле халыкларның тормышы белән танышуда рус миссионерларының аерым роль уйнаганын күрәбез. Алар татар халкын өйрәнүгә дә үз өлешләрен керткән. Миссионерлар Ислам диненнән куркыныч яный дип уйлап ялгышсалар да, татар-мөселман халкына каршы булсалар да, аларның күбесе татар халкында Ислам диненең үзенчәлекләре, татар халкының көнкүреше, гореф-гадәтләре хакында дөреслеккә туры килгән мәгълүмат калдырган.

Мондый тикшерүчеләр арасында Коблов Яков Дмитриевичне билгеләп үтәргә кирәк. Ул Казан руханилар академиясен тәмамлый һәм алга таба магистр була. 1901 елдан 1908 елга кадәр Яков Коблов Казан епархиаль миссионеры вазифасын башкара, ләкин ул вакытта рухани дәрәҗәсендә булмый. Аның татар халкы турындагы тикшеренүләре кыйммәтле этнографик чыганак булып тора.

Әлеге мәкаләдә без Кобловның революциягә кадәр Рәсәйдәге татар муллалары хакында бәян итүе белән танышабыз. Татар-мөселман авылларында булганда Коблов, иң беренче булып, әлеге мөһим фактка игътибар итә: кайсы гына авылны алса да, зур яки кечкенә булуына карамастан, анда мәчет урнашкан була. Аның фикеренчә, әлеге истәлекле факт мөселман татарларының беренче чиратта дини мәнфәгатьләрен кайгыртуларын ассызыклый. Коблов мулла кешенең мөселман җәмәгатьчелегендә, мәхәлләдә җитәкче, имам булуын әйтә. Моннан тыш, мулла мәхәлләдәгеләрнең дин тәртипләрен үтәвен күзәтә һәм бернинди дә хаталарны читтә калдырмый. Ул, чыннан да, җәмәгатьчелекнең җитәкчесе ролен башкара һәм барысы да аңа итагать итә.




1871-1878 еллардагы мәчет

*Фотоның чыганагы: Бөек Петр (Кунсткамера) исемендәге антропология һәм этнография музее*

Коблов мулла булган кешенең мәхәллә халкы белән бик тыгыз элемтәдә торуын әйтә. Гадәттә бу вазифаны шушы мохиттән булган кеше башкара. Мулла, башкалар кебек үк, авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнә һәм бу мәсьәләдә башка татар крестьяннарыннан аерылмый. Башкалардан ул дөньяви һәм дини эшләрдән күбрәк хәбәрдар булуы белән генә аерылып торган. Ул мәхәллә халкының тормышын яхшы белә, чөнки үзе дә алар белән бер төрле тормыш алып бара. Шуңа да мәхәллә халкы белән җитәкчелек итү аңа авыр түгел.

Аеруча да Коблов игътибарны түбәндәге фактка юнәлтә: мулла кеше мәхәллә халкын үзенә тышкы авторитеты яки нинди дә булса өстенлекләре белән түгел, ә, барыннан да бигрәк, рухи ягы, акыллы булуы һәм җәмәгатьчелекнең асылын аңлый алган кеше булуы белән буйсындыра. Коблов татар авылындагы мулланың вазифалары күп булуын ассызыклый. Ул намаз укыту гамәлен башкаручы да, балалар мөгаллиме дә, тормыш-көнкүрештәге эшләрдә киңәшче дә һәм хәтта казый да.

Шуңа күрә мөселманнарның мәктәптә укып белгән дингә ышанулары, карашларының ныклыгы көчсезләнми, ә, киресенчә, гыйлемле

җитәкче кулы астында ныгый һәм гомерлеккә сеңеп кала.

Коблов муллаларның көнкүрешенә кагылышлы кызыклы искәртүләр дә калдырган: аерым алганда, мулла исеме кешегә бернинди дә өстенлекләр һәм хокуклар бирми. Шуңа да мулла – ул гадәти крестьян, бары тик читтән кергән хезмәт хакы аркасында башкалардан бераз аерылып тора. Зур керемнәре булмаса да, ул җитеш тормышта яши һәм аның артык ихтыяҗлары юк.



Мулла кешенең йорты. Иске Йорт авылы.

*Фотоның чыганагы: ТРның Милли музее*

Мулланың өс киеме мәхәллә халкыныкы кебек үк. Йортында да башкаларда булган әйберләр генә: шул ук урын-җир, кирәк-яраклар урын алган. Аның йорты башкаларныкыннан дини әдәбиятның күп булуы белән генә аерылып тора.

Моннан тыш, Коблов, мәхәллә халкына мулланың йогынтысы зур булуын билгеләп үтә. Мулланы мәхәлләдә хөрмәт итеп кенә калмыйлар, ә күпмедер дәрәҗәдә (сүзнең уңай мәгънәсендә, билгеле) аннан куркалар да. Әгәр урамда яшьләр төркеме уеннар белән мавыгып торса, тавышлан-

са, кычкырып җырлар җырласа, шул вакытта йортыннан чыккан мулланы күреп, алар тын кала, хәтта иң батырлары да кая туры килсә шунда качып тору ягын карый.




Мулла кеше

*Фотоның чыганагы: Бөек Петр (Кунсткамера) исемендәге антропология һәм этнография музее*

# «Коръәнне яттан өйрәнү җиңел, аннары хәтердә саклау кыен»



Габдрәшит Ибраһимов
(1857-1944)
*Фотоның чыганагы: Facebook.com сайты*

Габдрәшит Ибраһимов XIX гасыр ахыры – XX гасырның беренче яртысында Рәсәйдә яшәгән иң күренекле мөселман эшлеклеләренең берсе була. Ул үзенең киң эшчәнлек алып баруы һәм сәяхәт кылулары белән, Рәсәйдә генә түгел, бөтен мөселман дөньясында танылa. Габдрәшит Ибраһимов Уфадагы Ырынбур мөселман Диния нәзарәтендә казый вазифасын башкарганга күрә, мөселманнар арасында Габдрәшит казый буларак билгеле.

Соңгы елларын Габдрәшит казый Токиода үткәрә. Биредә ул татар җәмәгатьчелегенең дини башлыгы була.

Габдрәшит Ибраһимов 1857 елда, хәзер Омск өлкәсенә кергән, Тара шәһәрендә туган. Аны нәселе Бохара ханлыгыннан булган ата-бабаларга барып тоташа, әмма үзен ул татар яки Себер татары дип атарга күнеккән була. Башлангыч белемне Габдрәшит Ибраһимов туган якларында алган. Ә 1877 елда, данлыклы Кышкар мәдрәсәсендә (бүгенге көндә ТРның Арча районындагы Кышкар авылы) уку нияте белән, Казан губерниясенә килә. Әмма анда ул ел ярым гына укый: яңа паспорт алыр өчен, аңа туган ягына кайтып китәргә кирәк була.

1878 елда Габдрәшит Ибраһимов тирән гыйлемнәр туплау өчен Мәдинә шәһәренә китәргә карар кыла. Ул вакытта 21 яшьлек егет Акмола өлкәсендә бай казах балаларын укыту белән шөгыльләнә. Сәфәргә чыгу эшендә аңа хәлле казах кешесе – Умар Волость ярдәм итә. Ул аңа сәфәргә чыгу өчен 150 сум акча бирә.

Габдрәшит Ибраһимовның Мәккә һәм Мәдинәгә сәфәре җиңел булмый. Хиҗазга килеп җитәр өчен аңа шактый кыенлыклар аша үтәргә туры килә. Ул изге җирләргә хаҗилар белән бергә барырга карар кыла. Ул вакытларда хаҗга ике юл белән барганнар: беренчесе – элеккеге юл һәм ул күп очракта коры җир аша үткән. Бу юл Бохара һәм Һиндстан аша узган. Икенче юл диңгез аша булган. Ул Одесса һәм Стамбул шәһәрләре аша үткән.

Габдрәшит Ибраһимов икенче юлны сайлаган. Баштан ул Түбән Новгородка килеп җиткән, аннары поездда Мәскәү аша Одессага юл тоткан. Ерак сәфәргә чыгуда тәҗрибәсез булганга күрә, ул үзе белән аз акча алган. Одесса шәһәрендә бары тик 30 сум акчасы гына калган. Одессадан Җиддә шәһәренә (Согуд Гарәбстаны) килеп җитү өчен чама белән 150-300 сум акча (сәфәрнең уңайлылыгына карап) кирәк була. Одессада бер көн торып, ул булган барлык акчасын тотып бетерә.

Нәтиҗәдә, мәрмәр ваннада яшеренеп, Стамбулга юл тота торган Итальян корабына эләгү бәхетенә ирешә. Юлда аның бер тиен акчасы да калмый. Әмма, бәхеткә, чыгышы белән Идел буеннан булган, Стамбулда яшәүче Мөхәммәдрәхим әфәнде ярдәме белән, күпмедер вакытка Госманлы империясендә яшәп тору мөмкинлегенә ия була. Аннары аңа Иркутск шәһәреннән булган татар сәүдәгәр Хисаметдин бай акчалата ярдәм итә. Җиддә шәһәренә бара торган пароходка билет алганнан соң, алар бергәләп изге җирләргә юл тоталар. Хаҗ сәфәре төгәлләнгәч, Габдрәшит Ибраһимов Мәдинә шәһәренә укырга китә.

Бу җирләрдәге беренче Рамазан ае яшь шәкерткә бик нык тәэсир ясый. Аны бу изге көннәрдә Мәдинә халкының хәтем (Коръәнне тулысынча укып чыгу) һәм тиләвәт (Коръәнне матур итеп уку) кылулары сокландыра. Ә Гомәр Заһид исемле бер имам Коръәни Кәримне бер төн эчендә укып чыга алган.

Шул сәбәпле, Габдрәшит Ибраһимов Коръән-хафиз булырга, ягъни Коръәни Кәримне тулысынча ятларга ният кыла. Бу хакта ул шәехләрнең берсе белән киңәшләшә һәм ул аңа мондый сүзләр әйтә: «Коръәнне тулысынча ятлау җиңел, әмма аннары үзгәрешсез хәлдә хәтердә саклау кыен».

Ул Габдрәшит Ибраһимовка берничә тапкыр истихара намазын укырга киңәш итә. Нәтиҗәдә, Габдрәшит Ибраһимов һиҗри ел исәбе буенча 1298 елның 1 нче мөхәррам аенда (1880 елның 3 нче декабре), Мәдинә шәһәрендәге «Әмин Ага» дип исемләнгән мәдрәсәгә укырга керә. Шул рәвешле, Мәдинәдәге беренче Рамазан ае яшь Габдрәшит Ибраһимовны олуг эшкә – Коръәни Кәримне ятлауга этәргәч була.

## Йошио Имаидзуми: японлының Ислам динен кабул итүе

Йошио Имаидзуми 1905 елның 16 нчы сентябрендә сәнгать остасы һәм антиквариатлар сатучы гаиләсендә дөньяга килгән. Башлангыч һәм урта белем алуны тәмамлаганнан соң, Йошио Токиодагы Нихон университетына укырга керә һәм 1927 елда инженер-механик белгечлеген алып, укуын тәмамлый. Шул ук елны Йошио Имаидзуми «Меишо Электрик Лимитед» оешмасының металл эшләнмәләр җитештерү бүлегенә инженер булып эшкә урнаша. Биредә ул радио һәм очкычлар өчен кирәкле булган эшләнмәләр җитештерә. Оешмада Йошио 1930 елның мартына кадәр эшли. Шул елның апрелендә Япониянең почта һәм телекоммуникацияләр Министрлыгына почтмейстер вазифасына алына.



Садык Йошио Имаидзуми
(1905-1960)

*Фотоның чыганагы:*
*Япония мөселманнары чыгарган*
*Islamic Culture Forum журналы*

## Ислам динен кабул итүе

Имаидзуминың йорты Рәсәй мөселманнарының лидеры булган татар имамы Габдерәшит Ибраһимовның йорты янәшәсендә булган. Беренче тапкыр Габдерәшит хәзрәт Япониягә 1902-1903 елларда килгән, бу кыска гына вакытлы сәфәр булган. Икенче тапкыр ул бирегә 1908 елда килгән һәм Япония җитәкчелеге тарафыннан бик күркәм рәвештә каршы алынган.

Йошио Имаидзумига әлеге шәхес белән элемтәләр булдыру мөмкинлеге туган. Габдерәшит Ибраһимовның киңәшен тыңлап, Йошио Имаидзуми Токиодагы җирле төрек-татар җәмәгатьчелеге белән аралаша башлаган. Япониядә яшәүче татар-мөселманнары белән булган элемтәләре нәтиҗәсендә, Йошио Имаидзуми Ислам дине хакында белгән һәм мөселманнарның яшәү рәвешен күзәтеп, мөселман кешесе булырга карар кылган – 1929 елның март аенда рәсми рәвештә Ислам динен кабул иткән. Аның Ислам диненә күчү йоласын Токиодагы төрек-татар җәмәгатьчелегенең башлыгы Габделхәй хәзрәт Корбангалиев башкарган.

Йошио Имаидзуми үзенә Садыйк Йошио Имаидзуми исемен алган һәм зур кызыксыну белән Ислам дине нигезләрен өйрәнә башлаган.

Аның укытучысы һәм нәсыйхәтчесе Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов булган. Ул 1933 елда Япониягә кайтып, гомеренең соңгы көненә кадәр, ягъни 1944 елга чаклы шунда яшәгән. Шунысы мөһим: Габдерәшит хәзрәт Япониядә Ислам динен таратуда зур роль уйнаган. Аның тырышлыгы белән, йөзләгән японлы Ислам динен кабул иткән. 1938 елда төрек-татар җәмәгатьчелеге тарафыннан Токиода мәчет салынган. Аның беренче имамы Габдерәшит хәзрәт булган. Мәчет төзелү белән Япониядә Ислам дине үсеш алган.

## Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында

1933 елда Садыйк Имаидзуми, почтмейстер булып эшләгән вакытта, Саеко исемле кызга өйләнгән, ул Ислам динен кабул иткәннән соң Садыйка исемен алган.

1941 елдагы Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында Япония Тын океанында агрессив сугыш хәрәкәтләре башлый. Яшен тизлегендәге кампания барышында Япония Азия континентының бик күп җирен, шулай ук Тын океаны һәм Һиндстанның көнбатыш өлешендәге утрауларны ала.

Япониянең хәрби диңгез көчләре югары командованиесе Садыйк Имаидзумины, мөселман халкы яши торган көньяк оккупацияләнгән территорияләрдә эшләү өчен, даими булмаган граждан хезмәткәре сыйфатында эшкә чакырып ала.

Югары командование аны 1943 елның июнь аенда, регионның мөселман җәмәгатьчелегенә машина төзү проектларының техник инструкторы буларак, Макассар шәһәренә җибәрә (хәзер Индонезиядәге Сулавеси). Ноябрь аенда Садыйк Имаидзуми Борнео утравындагы Банджармасин шәһәренә күчерелә. Биредә ул мөселман җәмәгатьчелегенең инженерлык эшчәнлегендәге проектларда киңәшче булып эшли. Җирле

халык белән аралашып, ул мөселманнар тормышы белән күбрәк таныша.

Икенче Бөтендөнья сугышы һәм Тын океанындагы сугыш, Япониянең җиңелүе һәм оккупацияләнүе белән, 1945 елның август азагында тәмамлана. Голландиялеләр яңадан Һиндстандагы элеккеге колонияләрен кайтарып алалар. Ул арада колонияләрдә милли-азатлык хәрәкәте үсә башлый.

Күп кенә элеккеге японлы солдатлар һәм Япония армиясенең гражданлык хезмәткәрләре индонезияле көрәшчеләргә азатлык өчен ярдәм итә. Садыйк Имаидзуми да шулар арасында була. Әмма 1946 елда голландиялеләр тарафыннан кулга алына. Һәм нидерландлыларга карата дошманлыкта гаепләнеп, хәрби трибуналга бастырыла. Тик хәрби трибунал аны гаепсез дип таба һәм ул азат ителә. Шул ук елның июнь аенда Садыйк Имаидзуми Япониягә озатыла.



Садыйк Йошио Имаидзуми Токио мәчетендә төрек солдатлары белән. *Фото Islamic Culture Forum журналыннан*

Япониядә йөз елдан артык мөселманнар яши. 2016 елда алган мәгълүматларга караганда, илдә 120 000 тирәсе чит ил мөселман кешесе бар, шуларның 10 000 е җирле мөселман японлылары. Әмма бик аз кеше генә японлыларның иң беренче тапкыр Ислам дине белән танышуы һәм Ислам динен кабул итүләре биредә булган татар җәмәгатьчелеге ярдәмендә булганын белә. Бу мәкаләдә без сезне, нәсыйхәтчесе һәм укытучысы Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов булган, Садыйк Йошио Имаидзуми белән таныштыруны дәвам итәбез.

## Икенче бөтендөнья сугышыннан соң

Садыйк Имаидзуми Япониягә кайтканнан соң, сугыштан кайткан кеше дучар була торган төрле авырлыклар алдында калган. Әмма бар кыенлыкларны да җиңеп, инженер-механик белгечлегенең тәҗрибәсен һәм белемен кулланып, «Митсубоши Индастриал Компани Лимитед» дип исемләнгән шәхси заводын ачып җибәргән һәм анда президент булган. Нигез салган компаниясе машиналар һәм оекбашлар әзерли торган җиһазлар җитештергән. Завод Токионың Итабаши районындагы Накадзюку (Харадзюку) кварталында урнаша. Аның даими сатып алучылары Япониянең сугыштан соң булган оккупация көчләре була.

## Япония мөселманнарының берләшүе

Садыйк Имаидзуми Япония һәм чит ил мөселманнары белән элемтәдә тора. Күпмедер вакыттан соң, аның элемтәләре ныгый. Компаниядә эшләүдән тыш, Садыйк Имаидзуми буш вакытын башка мөселманнар белән аралашуга багышлый. Ул японлы мөселманнарны берләштерүдә һәм аларның карашларын ныгытуда зур роль уйный. Садыйк Имаидзуми Япония Мөселманнары җәмәгатенә нигез салучыларның һәм җәмәгать әһелләренең берсе була.

Үз бизнесыннан тыш, ул Япония юстициясе министрлыгының штаттан тыш хезмәткәре дә була һәм элеккеге хөкем ителгәннәрне яклау һәм аларга киңәшче булу ролен үти. Үзенең эшләре бик тыгыз булу: компания белән идарә итү, җирле халыкка ярдәм күрсәтүгә дә карамастан, Садыйк Имаидзуми беркайчан да дини вазифаларын калдырмый. Япония мөселманнары җәмәгатьчелеге президенты буларак, аңа төрле чаралар үткәрергә кирәк була. Мәсәлән, чит илдәге Ислам университетларында укучы японлы яшь мөселманнарга стипендия түләүне оештыру, Япониянең төрле регионнарында лекцияләр үткәрү һәм анда чыгыш ясау, массакүләм мәгълүмат чаралары белән әңгәмә үткәрү яки, японлыларны Ислам дине белән таныштыру максатыннан, мәкаләләр язу.

Аның бертуктамый тырышлык куюлары белән, Япония мөселманнарының саны арта һәм 1959 елда, Япония Мөселман җәмәгатенең нигез салынуына 7 ел үткәннән соң, җәмәгать әгъзаларының саны берничә дистәгә җитә.

Әмма бервакыт Садыйк Имаидзуминың сәламәтлеге начарлана һәм ул авырып китә. Табиблар аның ашказанында яман шеш тапканнан соң, хастаханәгә ятарга киңәш итәләр. Әмма ул хастаханәгә ятудан баш тарта һәм үзенең вазифаларын үтәүне дәвам итә. Ләкин күпмедер вакыттан соң, кисәк кенә аның хәле начарлана һәм Садыйк Имаидзумины хастаханәгә салалар. 1960 елда, үзе белем алган Нихон университеты хастаханәсендә аңа операция ясала, тик инде соң була. 1960 елның 17 нче маенда Садыйк Йошио Имаидзуми фани дөньядан китә. Бу вакытта аңа 55 яшь була.

Аллаһы Тәгалә аны мәрхәмәтеннән аермаса иде.

*Дамир Гайнетдинов язмасы,*

*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Фән

# Әбү Хәнифәнең укытучылары

*(Дәвамы. Башы журналның алдагы санында)*

Үзенең гыйлемгә булган мөнәсәбәте турында фикер йөрткәндә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи: «Мин гыйлем һәм фикһ учагы булган Куфа шәһәрендә туып үстем, галимнәр җыелышына йөрдем, факиһларның иң хөрмәтлесендә гыйлем алдым», – дип әйтә торган булган.[1] Әбү Хәнифә аның дәресләрен калдырмый торган бу хөрмәтле галим, Гали һәм Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһүмәнең укучысы Хәммәд бине Әбү Сөләйман булган.

Әбү Хәнифә 18 ел дәвамында Хәммәд бине Әбү Сөләйманның дәресләренә йөргән һәм шул ук вакытта аның ярдәмчесе булган. Хәммәдкә шәһәрдән китәргә кирәк булганда Әбү Хәнифә дәресләрдә аны алыштыра һәм үзенә бирелгән сорауларга җавап бирә торган булган.[2] Берьюлы Хәммәд ике айга шәһәрдән киткән. Бу вакытта Әбү Хәнифәгә элек укытучысыннан ишеткәне булмаган сорауларга җавап бирергә туры килгән. Ул моны булдырып чыккан, әмма укытучысына күрсәтер өчен, үзенең җавапларын язып алган. Мондый сораулар алтмышлап булган. Хәммәд шуларның кырыгында Әбү Хәнифә белән килешкән һәм егермесендә фикер каршылыгына кергән.[3]

Әбү Хәнифә унсигез ел дәвамында гыйлем алган укытучысына аеруча да бирелгән һәм аңа тугры булган. Хәтта укытучысының үлеменнән соң да, аны беркайчан да онытмаган. Ул һәм аның әти-әнисе намаздан соң Аллаһы Тәгаләдән аның өчен истигъфар сорауны туктатмаган. Һәм ул үзенең догаларында укытучысы Хәммәдне генә түгел, ә барлык укытучы-

---

[1] Мөхәммәд Әбү Зәһра – «Әбү Хәнифә: Хәятуһу вә әсруһу әрауһу вә фикһуһу», «Дәруль-фикриль-гарәби», Каһирә, 1997, 58 б.

[2] Әбү Бәкер Әхмәд бине Гали Әл-Хатыйб Әл-Багдади – «Тариху Мәдинәти әс-сәлам», Бәйрут, 2001. XV, 457 б.

[3] Шунда ук, 457 б.

ларын һәм укучыларын искә ала торган булган.[1]

Әбү Хәнифә Хәммәдтән кала башка галимнәрдән дә гыйлем алган. Әбү Хафс үзенең остазының дүрт мең галимнән гыйлем алганлыгын санап чыгарган. Кайбер биографлар бу саннар табигыйннәрдән булган укытучыларга туры килгәнен әйткән. Бу сан арттыру түгел, чөнки Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи илле биш тапкыр хаҗ кылган. Билгеле булганча, хаҗ кылу айларында Ислам дөньясының тәфсир кылучылары, хәдис белгечләре һәм факыйһлары Әл-Хәрамәйн исемле җирлектә җыела торган булган. Шуңа да Әбү Хәнифәнең җитмештән дә ким булмаган галим белән очрашып, алардан Коръән һәм Сөннәт буенча гыйлем алуы гаҗәп түгел. Шул рәвешле хәтта хаҗ кылу дәверендә дә аның дүрт меңләп галим белән күрешкән булуы мөмкин.

Хаҗ кылырга барудан тыш, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи, Гыйрактагы Өмәвиләр хәлифе Ибне Һүбәйрадан яшеренгәндә (һиҗри белән 130 нчы елда)[2], хакимият Әбү Җәгъфәр Әл-Мансур кулына күчкәнче, күпмедер вакыт бу шәһәрдә яшәгән дә. Әбү Җәгъфәр һиҗри буенча 137 нче елдан идарә итә башлавын исәпкә алсак, Әбү Хәнифә Мәккәдә ким дигәндә җиде ел яшәгән.[3] Ул Габдулла бине Габбасның укучылары Гата бине Әбү Рабәх һәм Гыйкримә һәм шулай ук Ибне Гомәрнең укучысы Нәфигътан дәресләр алган.[4]

Шул рәвешле Куфа һәм Мәккә Әбү Хәнифә өчен ике зур гыйлем чыганагы булган. Әгәр Куфада ул Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе гыйлемнәренең варисы булса, Мәккәдә Ибне Габбас һәм Ибне Гомәр радыяллаһу ганһүмәнең гыйлемнәрен алучы булган. Шуңа да аннан

---

1 Шунда ук, 457 б.

2 Әл-Мовәффәк бине Әхмәд Әл-Мәкки, «Мәнәкибү Әбү Хәнифә», «Дарүл-китабелгарәби» нәшрияты, Бәйрут, 1981, I, 276 б.

3 Ибне Хәҗәр Әл-Мәккә – «Әл-Хайратүль-хисан», 51 б.

4 Мөхәммәд Әбү Зәһра – «Әбү Хәнифә: Хәятүһу вә әсруһу әрауһу вә фикһуһу», «Дәрульфикриль-гарәби», Каһирә, 1997, 58 б.

гыйлемнәре турында соралгач, ул иң элек әлеге галимнәрнең исемен әйтә торган булган. Берьюлы аны Иракта Габәсиләрнең башлыгы Әбү Җәгъфәргә чакырганнар. Монда Гайсә бине Муса да булган. Гайсә бине Муса ул көнне Әбү Җәгъфәргә: «Әбү Хәнифә – безнең көннәрнең бердәнбер хакыйкый галиме», – дип әйткән. Шулчак Әбү Җәгъфәр Әбү Хәнифәгә мөрәҗәгать итеп:

– Ий Әбү Хәнифә! Ия булган гыйлемнәреңне кемнән алдың? – дип сораган.

Әбү Хәнифә болай дип җавап биргән:

– Мин гыйлемнәремне Гомәр, Гали һәм Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһүмәнең укучыларыннан алдым. Мин укучыларыннан гыйлем алган Габдулла бине Габбас, хакыйкатьтә, шундый күләмдәге гыйлемнәргә ия булган ки, хәтта үз вакытында җир йөзендә аннан да күп белүче кеше булмаган.[1]

Әбү Хәнифә чәчәктән чәчәккә йөреп нектар җыеп, шуннан кабатланмас, татлы бал ясый торган бал корты сыман булган. Имам Әгъзам иң олуг галимнәрдән: Куфада Гали һәм Ибне Мәсгудтән, аннары Мәккәдә Ибне Габбас һәм Ибне Гомәр радыяллаһу ганһүмәдән, шулай ук хаҗ кылу вакытында Әл-Хәрамәйн җирлегендә күрешеп алган галимнәрдән гыйлем алган. Аңа шушы гыйлемнәрнең бөртекләп җыеп, үзенең олуг хезмәтен барлыкка китерү насыйп булган.

*Ихсан Шеноджакның «Абу Ханифа – великий муджтахид» китабыннан тәрҗемә*

1 Әбү Бәкер Әхмәд бине Гали Әл-Хатыйб Әл-Багдади – «Тарихy Мәдинәти әс-сәлам», Бәйрут, 2001. XV, 458 б.

# Тәрбия

# Әдәпләр

## Мунча керү әдәпләре

– Гаурәтне капларга

– Башка кешеләрнең җенес әгъзаларына карамаска

– Аулак урын табарга

– Сөйләшмәскә

– Як-якка карамаска

– Сәлам бирешмәскә

– Мунчада озак булмаска

– Мунчага кергәнче җөнеб[1] хәленнән пакьләнергә

– Мунчадан чыгар алдыннан аякларны салкынча су белән юып алырга, чөнки шул рәвешле баш авыртулары басыла

## Тәһарәт алу һәм пакьләнү әдәпләре

– Мисвәк[2] кулланырга

– Билгеле әгъзаларны юган вакытта тиешле догасын укырга

– Кылган гөнаһларың өчен тәүбә итәргә

– Тәһарәт алганнан соң, намазга кадәр, сөйләшмәскә

– Тәһарәтле булган килеш яңадан тәһарәт алырга[3]

– Мыекларны кыскартырга

– Тиешле төкләрне кыркырга

– Тырнак кисәргә

– Кул һәм аяк бармаклары араларын юарга

1 Җөнеб булу – якынлык кылу, поллюция, хәез яки нифас вакытындагы халәт.

2 Мисвәк – арак агачы ботаклары. Мисвәкне теш чистарту щеткасы урынына авыз эчен чистарту өчен кулланалар.

3 Ягъни, икенче намаз вакыты кергәч, яңадан тәһарәт алу, гәрчә әүвәл алган тәһарәт бозылмаган булса да.

– Борын эчен юарга
– Кием һәм тәнне пакьләргә

## Мәчеттә үз-үзеңне тоту әдәпләре

– Уң аяктан керергә
– Мәчеткә керер алдыннан аяк киемен нәҗестән чистартырга
– Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә
– Мәчеттә булучыларга сәлам бирергә
– Мәчеттә беркем булмаса да, сәлам бирергә
– Кыйблага таба карап утырырга
– Үзеңнең хәлең һәм кылган гамәлләрең хакында уйланырга
– Аз сөйләшергә
– Беркемне дә ләгънәт кылмаска
– Тавыш күтәрмәскә
– Кешеләрне үпкәләтерлек гамәлләр кылмаска
– Мәчеттә бары тик Аллаһы Тәгаләне зикер итү белән шөгыльләнергә
– Югалган әйберләрне эзләмәскә
– Сату-алу белән шөгыльләнмәскә
– Мәчеттән сул аяк белән чыгарга
– Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен сорап дога кылырга

## Игътикәф[1] әдәпләре

– Бертуктаусыз (ялыкмыйча) Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә
– Игътибарлы һәм җитди булырга
– Сөйләшмәскә
– Бер урыннан торып киткәннән соң, урынны еш алмаштырмаска
– Нәфес омтылышларына каршы торырга

[1] Игътикәф – фикерләү һәм гыйбадәт кылу өчен ялгыз калу.

– Нәфес омтылган һәрнәрсәдән нәфесне мәхрүм итәргә

– Нәфесне Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга мәҗбүр итәргә

## Азан әйтү әдәпләре

– Мөәзин намаз вакыты керү-кермәү мәсьәләләренә үтә дә игътибарлы булырга тиеш

– Азан әйтелгән вакытта як-якка карамаска

– Азан вакытында «саләх» һәм «фәләх» кәлимәләрен әйткәндә башны уң һәм сул тарафларга борырга

– Азанны ашыкмыйча, ачык итеп, ә камәтне – тизрәк әйтергә

## Имам кешенең әдәпләре

– Намазның фарызларын һәм сөннәтләрен яхшы белүче кеше генә имам була ала

– Намазны боза торган шартларны белергә

– Синең имам булуыңны теләмәгән кешеләр өчен имам булмаска

– Үзең артыңнан гыйлемле кешене бастырырга

– Намаз алдыннан итагатьле итеп кенә, кул ишарәсе белән сафларны тигезләүләрен сорарга

– Намазда озын сүрәләр укымаска, чөнки бу җәмәгатькә кыенлык китерергә мөмкин

– Тәсбихләрне озакка сузмаска

– Әмма шул ук вакытта намазларны аларның дәрәҗәсен киметерлек итеп кыскартмаска

– Намаз укыганда мәчеттәге авыру, хәлсез, өлкән кешеләрнең хәлен исәпкә алырга, ягъни андый кешеләр барында намаз җиңеләйтелеп укыла

– Рөкүгъ һәм сәҗдә вакытында, җәмәгать намазны тәгъдил хошугъ-лык белән укысыннар өчен, тәсбихләрне әкрен әйтергә

– «Фатиха» сүрәсен укыр алдыннан һәм укыганнан соң, шулай ук өстәмә сүрә укылгач, берникадәр вакыт дәшми торырга (тынлык сакларга)

– Әгәр кемнеңдер намазга кушылырга ашыгуын ишетсәгез, рөкүгъ вакытында аны бераз көтеп торырга кирәк. Әлбәттә, әгәр бу җәмәгатькә кыенлык тудырмаса

– Әгәр намазның вакыты чыгачак дигән курку булмаса, күршеләрнең намазга кереп җитүен бераз көтеп торырга кирәк

– Беренче һәм икенче «сәлам» арасында, алар бер-берсеннән аерылып торсын өчен, бераз туктап торырга

– Намаздан соң Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр турында уйланып, Аңа рәхмәтләрне җиткерергә

– Нинди генә халәттә булуга карамастан, Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә

## Намаз әдәпләре

– Үзеңне тыйнак тотарга

– Аллаһы Тәгалә каршында хөрмәт белдереп, итагать белән басып торырга

– Аллаһы Тәгалә каршында үзеңнең түбәнлегең һәм зәгыйфьлегеңне белдереп басып торырга

– Намазны бөтен күңелне биреп укырга

– Шикле уйларны куарга

– Намаз вакытында як-ягыңа боргаланмаска, куллар белән артык хәрәкәтләр ясамаска

– Башны бераз аска иеп, уң кулны сул кул өстенә куярга

– Коръән укыганда уйланырга

– Тәкбирне[1] ихтирам белән әйтергә

– Рөкүгъ һәм сәҗдәләрне Аллаһы Тәгалә каршында түбәнчелек белән кылырга

– Аллаһы Тәгаләне бөекләп тәсбих әйтергә

– Тәшәһһүдне[2] Аллаһы Тәгаләне күргән кебек укырга

– Сәлам биргәндә дулкынланырга

– Мәчеттән, Аллаһы Тәгалә намазымны кабул иттеме-юкмы, миннән ризамы-юкмы, дип курку катыш борчылу халәтендә чыгарга

– Аллаһы Тәгалә ризалыгын өмет итеп, намаз кылырга ашыгырга

## Коръән уку әдәпләре

– Һәрвакыт тәкъва, җитди һәм тыйнак булырга

– Буш һәм мәгънәсез, начар мәгънәле сүзләр сөйләүдән читләшергә

– Оялчан булырга

– Күзләр һәрвакыт кайгылы күз яшьләре белән тулган булырга тиеш

## Дога кылу әдәпләре

– Йөрәктә курку хисе булырга тиеш

– Игътибарны тупларга

– Тышкы кыяфәтең зәгыйфь һәм мохтаҗ булуыңны белдерергә тиеш

– Фикерләргә

– Тыйнак булырга

– Чыннан да мохтаҗ булган әйбереңне сорарга

– Үзеңнең кемлегеңне (бернинди кыйммәткә ия булмавыңны) танырга

– Дога кылып мөрәҗәгать иткән Затның бөеклеген танырга

1 Тәкбир – «Аллаһү әкбәр» («Аллаһы бөек») дип әйтү.

2 Тәшәһһүд – намазда утырган вакытта укый торган дога.

– Яхшы-күркәм әйбер сораганда, кулларны ачып күтәрергә

– Аллаһы Тәгаләнең доганы кабул итәчәгенә бөтен күңелең белән ышанырга

– Аллаһы Тәгалә догаңны кабул итмәс, дип борчылырга

– Бәла-казаларның үтәчәгенә өметләнергә

– Дошманлык хисе кичермәскә

– Ниятләрең дөрес булырга тиеш

– Дога кылганнан соң куллар белән битне сыпырырга

## Җомга намазы әдәпләре

– Намаз вакыты кергәнче, аңа әзерлек эшләрен тәмамларга

– Вакыты керү белән, тәһарәтләнеп мәчеткә иртәрәк барырга

– Тулысынча госел алырга

– Чиста киемнәр кияргә

– Тиешле күләмдә ислемай кулланырга

– Аз сөйләшергә

– Һәрдаим Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә

– Имамга якынрак утырырга

– Хотбә-вәгазьне сөйләшмичә тыңларга

– Намаз укыганнан соң, гыйлем алу белән шөгыльләнергә

– Йөргәндә салмак кына атларга

– Бармакларны берләштермәскә

– Атлаганда кечкенә адымнар ясарга

– Башны бераз алга ияргә

– Мәчеткә ачык йөзле һәм күркәм кыяфәттә керергә

– Кешеләрнең сәламнәренә җавап кайтарырга

– Хатыйб минбәргә күтәрелгәннән соң, намазлар кылмаска

– Хатыйб җәмәгатькә сәлам биргәндә, аның сәламенә җавап кайтарырга

– Хотбәне бөтен күңелне биреп тыңларга һәм нәсыйхәтләргә колак салырга

– Хатыйб җәмәгать тарафына борылып хотбә сөйли башлаганнан соң, як-якка боргаланмаска

– Хатыйб минбәрдән төшмичә һәм мөәзин камәтне төшереп бетермичә, намаз укырга басмаска

## Хатыйб кешенең әдәпләре

Хатыйб мәчеткә җитди кыяфәт белән керергә, әүвәл җыелган мөселманнарга сәлам биреп, күркәм рәвештә утырырга тиеш. Шуннан соң ул, беркем белән дә сөйләшмичә, билгеле вакыт көтәргә тиеш.

Аннары ул, Аллаһы Тәгалә каршында нотык сөйләргә җыенган сыман, акрын гына минбәр тарафына юнәлергә, салмак һәм итагатьле рәвештә, адым саен Аллаһы Тәгаләне зикер итеп, минбәр баскычлары буенча күтәрелергә тиеш. Игътибарны туплап, йөзе белән тыңлаучылар тарафына борылып, ишарә белән генә аларга сәлам бирергә һәм Аллаһы Тәгалә каршында итагать һәм хөрмәт йөзеннән азан вакытында утырып торырга тиеш. Хатыйб тыйнак рәвештә хотбә сөйләргә тиеш. Беркайчан да, беркемгә дә бармак белән төртеп күрсәтергә тиеш түгел. Кешеләр ул сөйләгәннәрдән гыйбрәт алырлар, дип өметләнергә тиеш.

Һәм килгән кешеләргә ишарә итеп, дога кылырга, мөәзин камәт әйтә башлагач, минбәрдән төшәргә тиеш. Җәмәгать тынып калгач, мөәзин камәтне төшереп бетерергә, тәкбир әйтергә тиеш, шуннан соң җәмәгать намаз укый башлый. Намазда аять һәм сүрәләр ачык һәм аңлаешлы итеп укылырга тиеш.

## Гает әдәпләре

– Гает алды кичәсен гыйбадәттә үткәрергә

– Иртән торып госел алырга

– Чиста киемнәр кияргә

– Ислемай сөртергә

– Һәрдаим тәкбир әйтергә

– Һәрдаим Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә

– Зур ихтирам белдерергә

– Тәкбирләр арасында «сөбхәналлаһ» һәм «әлхәмдүлилләһ» дип әйтү

– Намаздан соң сөйләшмичә гает хотбәсен тыңларга

– Рамазан гаетендә мәчеткә барыр алдыннан бик аз гына ашап алырга

– Мәчеткә бер юл белән барып, кайтканда башка юл белән кайтырга

*Имам Әбү Хәмид Мөхәммәд Газалиның «Әдәпләр» китабыннан*

# Тәфсир

# Бәлгам бине Багура

Муса галәйһиссәлам заманында яшәгән Бәлгам бине Багура тирән белемнәргә һәм хикмәтләргә ия булган. Аның кылган догасын Аллаһы Тәгалә шулвакытта ук кабул иткән. Әмма, Аллаһының аңа карата киң рәхмәте булуга да карамастан, ул моның өчен Яратучысына бер тапкыр да шөкер итмәгән. Киресенчә, бу зур бәхетне ул, Аңа итагатьсезлек һәм буйсынмаучанлык күрсәтеп, Аллаһы разый булмаган гамәлләрендә файдаланган. Бәлгам бине Багура Муса галәйһиссәламгә һәм аңа ияручеләргә ләгънәт кылган, шул сәбәпле Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм ителгән.

Коръәндә бу вакыйгаларга карата ачыктан-ачык булмаган түбәндәге күрсәтмәләр бар:

وَاتْلُ عَلَيْهِمْ نَبَأَ الَّذِي آتَيْنَاهُ آيَاتِنَا فَانسَلَخَ مِنْهَا فَأَتْبَعَهُ الشَّيْطَانُ فَكَانَ مِنَ الْغَاوِينَ ﴿١٧٥﴾ وَلَوْ شِئْنَا لَرَفَعْنَاهُ بِهَا وَلَٰكِنَّهُ أَخْلَدَ إِلَى الْأَرْضِ وَاتَّبَعَ هَوَاهُ ۚ فَمَثَلُهُ كَمَثَلِ الْكَلْبِ إِن تَحْمِلْ عَلَيْهِ يَلْهَثْ أَوْ تَتْرُكْهُ يَلْهَث ۚ ذَّٰلِكَ مَثَلُ الْقَوْمِ الَّذِينَ كَذَّبُوا بِآيَاتِنَا ۚ فَاقْصُصِ الْقَصَصَ لَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ ﴿١٧٦﴾

**«[Расүлем!] Аларга [яһүдиләргә һәм башка кешеләргә рухи кыйммәтләрне шәхси мәнфәгатендә кулланган Бәлгам бине Багура исемле] затның хәбәрен укы. Без аңа аятьләребезне бирдек, әмма ул алардан тайпылды, бу сәбәптән [иманлы була торып, аңа ияра алмаган] шәйтан аңа иярде, һәм ул адашканнардан булды. Әгәр Без [аның аятьләрдән файдалануын] теләсәк, шулар аркылы аны [галимнәр дәрәҗәсенә] күтәргән булыр идек. Ләкин ул [гади] туфракка сырышты һәм [кабиләсе күзендә яхшы күренер өчен нәфесенең] начар теләгенә иярде. Аның хәле этнеке кебек: [аны куар өчен] өстенә барсаң да, те-**

**лен чыгара, аны [үз хәлендә] калдырсаң да, телен чыгара. Бу – [Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сыйфатларын Тәүратта укыганнан соң, белә торып] аятьләребезне ялган санаган ул кавемнең кыйссасы. Бу кыйссаны сөйләп тор, – бәлки, алар уйланырлар [һәм бу кешенең хәленә төшмәсләр]».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:175-176

Күрәсез, Бәлгам бине Бәгура тарихы кыскача әлеге аятьләрдә тасвирлана, шулай да тәфсирләргә һәм китапларга да кергән.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Муса галәйһиссәлам бер тәкәббер халыкка каршы яуга әзерләнеп, Кенанның уллары җиренә – Шамга килеп кергән. Халык ярдәм сорап, Әл-Бәлка шәһәре авылларының берсендә торган Бәлгам бине Бәгура янына килгән:

– Ий Бәлгам! Муса бине Гыймран үзенең гаскәре белән безне үтерергә, илебездән куып чыгарырга һәм безне Исраил уллары кулына тапшырырга дип килде. Әмма безнең башка торыр җиребез юк! Ул чагында безгә кайда яшәргә соң? Синең догаларың кабул була, шуңа бу авыр хәлдән имин котылуыбызны сорап, Аллаһыга мөрәҗәгать итсәң иде.

Адашу юлына төшкәнче Бәлгам бине Багура Муса галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә иман китерүчеләрнең берсе булган. Шуңа күрә бу тәкъдимгә җавап итеп, ул болай дигән:

– Ул – Аллаһының илчесе һәм барлык фәрештәләр, иман әһелләре – барысы да аның белән. Мин аларга каршы ничек дога кыла алыйм?!

Әмма халык үз сүзләрендә нык торып, Бәлгамның хатыны янына барырга карар кылганнар. Бәлгамны бу эшкә күндерә алса, хатынына кыйммәтле бүләкләр вәгъдә иткәннәр. Хәер, алар дөнья зиннәтләре белән Бәлгамның үзен дә кызыктырганнар. Һәм Бәлгам… ризалашкан.

Шулай итеп, Бәлгам бине Багура качырына атланып, Хусбан тавына чыгып киткән. Әмма беркадәр ара узгач, аның качыры җиргә утырган һәм алга барырга теләмәгән. Хайванын кыйный һәм сүгә башлагач, качыры

тагын бераз араны үткән, әмма арып янә җиргә сузылып яткан. Шулчак хайван телгә килеп сөйләшә башлаган:

– Ий, Бәлгам! Син кая барасың? Минем алдымда фәрештәләр тора һәм алар миңа узып китәргә ирек бирмиләр. Син Аллаһының пәйгамбәре һәм иман әһелләренең каргышын алырга дип барасыңмы әллә?

Әмма Бәлгам бине Багура артык масаеп һәм тәкәбберлек күрсәтеп, хайванның аның белән сөйләшә башлавына да игътибар итмичә, качырны кыйнавын дәвам иткән.

Аллаһы Тәгалә качырга юлны ачкан һәм ул алга ыргылган. Ниһаять, качыр хуҗасын Хусбан исемле тау башына кадәр алып менгән. Бәлгам бине Багура шушы җирдә, Муса галәйһиссәламгә һәм аның гаскәренә ләгънәт булсын, дип дога кылган. Әмма Аллаһы Тәгалә аның телен үз халкына каршы борган. Аллаһының бу тәккәббер бәндәсе нинди генә ләгънәт укымасын, алар барысы да аның кавемдәшләренә барган, ә изге догалары Муса галәйһиссәлам хисабына кабул ителгән. Бәлгам тарафыннан ләгънәт кылынуын күреп, кавемдәшләре аңа ябырылганнар:

– Ий, Бәлгам! Син нәрсә эшлисең? Алар өчен син изге дога кыласың, ә безгә ләгънәт кылырга чакырасың.

Ул кавемдәшләренә болай дип җавап биргән:

– Мин моны үз ихтыярым белән эшләмим. Минем телем белән Раббыбыз идарә итә.

Шуннан соң аның теле авызыннан атылып чыгып, күкрәк турысына җитеп асылынып калган. Бәлгам бине Багура халкына таба борылып болай дигән:

– Мин хәзер дөнья тормышын да, Ахирәтне дә югалттым. Бары хәйлә һәм мәкерлек кенә калды.

Шуннан соң ул үз халкын җиңүгә ирешү өчен кулланырга кирәк булган хәйләкәр гамәлләргә өйрәтә башлаган.

Бу риваятьтә фикер йөртүче кешеләр өчен кыйммәтле сабак бар: үз юлында Аллаһының ачык могҗизаларына юлыгып та, хакыйкать юлына иярмәгән кешенең ахыры менә шулай тәмамланачак. Бәлгам бине Багура үрнәге бар көчен ислам белән көрәшүгә багышлаган имансыз галимнәрнең торышын күз алдына китерергә ярдәм итә. Имансыз бәндәләр дә шулай ук үз файдалары хакына Аллаһының динен бозалар һәм иманнарын дөнья байлыкларына, дан-шөһрәтләргә алмаштыралар.

Әлеге нәсыйхәттә китерелгән аятьләр, һичшиксез, Бәлгам бине Багура турында сөйлиләр, әмма андагы хөкемнәр бары бер генә кешегә түгел, ә аңа охшаган башка барлык кешеләргә дә кагыла. Үзенең тәкәбберлеге һәм дөньяга хирыслыгы сәбәпле, шәйтанга ияреп адашу юлына баскан Бәлгам Аллаһының могҗизаларын санга сукмыйча, телен чыгарган эт дәрәҗәсенә төшкән кешене гәүдәләндерә. Гыйлем һәм хакыйкать юлыннан тайпылган һәркемнең торышы шундый булачак, ул үзенең нәфесе һәм теләкләренә ияреп, дип сурәтли Раббыбыз аны искә алган аятьләрдә.

Бер риваятьтә әйтелгәнчә, элек Бәлгам бине Багура өчен билгеләнгән җәннәт хәзер мәгарәдә яшәүчеләрнең этенә биреләчәк. Әлеге мисал никадәр дәрәҗәдә гыйбрәт булып тора! Бөек галим була торып, Бәлгам бине Багура, телен чыгарып, эт дәрәҗәсендә калып, Раббыбызның дусларына каршы көрәшүчеләр арасында үз урынын алганнан соң, Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм ителә. Әмма Кытмир кушаматлы гап-гади эт мәгарәдә яшәүчеләр, ягъни Аллаһының дуслары арасында лаеклы урынын алып, җәннәткә ия булучылар дәрәҗәсенә ирешәчәк.

Раббыбыз безне төрле мөмкинлекләр һәм теләкләр белән сыный, әмма карарларны без үзебез кабул итәбез. Тугры яки имансыз булуда һәр акыллы кеше Аллаһының рәхмәте белән үз юлын сайлый. Кем өчендер гөнаһ һәм көферлектән торган татлы, әмма кыска вакытлы бәхет күңеленә якынрак, ә кемгәдер, авырлыклар белән тулган булуга да карамастан,

хакыйкать кыйммәтрәк булып тора. Раббыбыз безне әлеге дәрестән сабак алучылардан насыйп әйләсә иде. Ул безне явызлыктан һәм динне бозучы кабахәт галимнәрнең явызлыгыннан Үзе сакласын һәм безгә әһле Сөннәт галимнәре юлыннан тайпылмауны насыйп әйләсен! Әәмин!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Нәсыйхәт

# Изге эшкә боеру һәм яман эштән тыю бүлеге

Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Исмәгыйль бине Әбү Хәкимнән, ул Гомәр бине Габделгазиз радыяллаһу ганһедән риваять итте, Гомәр бине Габделгазиз радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә барча халыкны бер махсус кешенең явыз гамәле сәбәпле газапламыйдыр. Шулай булса да, гөнаһлар ачылса, алар инкяр кылмасалар, кавемнең барчасы газапка лаек булыр».

Янә хәбәр ителде. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Йөшәгъ бине Нунга вәхи индерде: «Синең кавемеңнән кырык мең изге кешене һәм явызлардан булган алтмыш мең кешене һәлак итәчәкмен». Йөшәгъ бине Нун: «Әй, Аллаһым, алар явызлар иде, ә изгеләрне ни өчен һәлак кыласың?» – диде. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: Дөреслектә, ул изгеләр явызларны Минем ачуым белән ачуланмады, алар белән бергә ашаучылар һәм эчүчеләр иде», – дип әйткән.

Әбү Һөрайра Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Шундый кешеләр бар, алар яхшылыкка ачкыч һәм явызлыкка богау булыр. Дөреслектә, кайбер кеше явызлыкка ачкыч һәм изгелеккә богау булыр. Кулында изгелек ачкычлары булучыга ни сөенечтер! Кулында Аллаһы Тәгалә явызлык ачкычларын кылучыга ни үкенечтер! Ягъни шәригать белән әмер итүче һәм тыелган нәрсәләрдән тыючы кеше изгелекнең ачкычы, явызлыкны баглаучыдыр. Бу кеше мөэмин булса, Аллаһы Тәгалә әйтте: «Иман китергән ирләр һәм хатыннар бер-берсеннән артыграктыр: яхшы эшләргә өндәрләр һәм начарлыктан тыярлар».

Әмма ярамаган эш белән әмер итү икейөзлеләр галәмәтеннәндер. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

ٱلْمُنَافِقُونَ وَٱلْمُنَافِقَاتُ بَعْضُهُم مِّن بَعْضٍ ۚ يَأْمُرُونَ بِٱلْمُنكَرِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ ٱلْمَعْرُوفِ

**«Монафикъ ирләр белән монафикъ хатыннар – икесе бер [кыяфәт белән дә, күңелләре белән дә]. Алар [Пәйгамбәрне инкяр итү кебек акыл һәм дин ягыннан харам кылынган] тыелганны әмер итәләр, [шәһадәт кәлимәсе кебек акыл һәм шәригать ягыннан кабул ителгән] игелектән тыялар...»**

«Әт-Тәүбә», 9:67

Мөэминнәрнең әмире Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Гамәлләрнең иң хәерлесе – изгелеккә боеру һәм ярамаган эштән тыю, шулай ук гөнаһлы кешегә ачулану, ягъни аның бозык гамәлләренә ачулану. Бер кеше изге эшкә әмер кылса, дөреслектә, мөэмин аркасына бәйләнде. Әгәр берәү ярамаган эштән тыйса, икейөзленең борынына төшерде».

Сәгыйд Котәдә болай дип әйткән: «Безгә бу хәбәр сөйләнде, дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдә булганда аның янына бер ир килде һәм Расүлебездән: «Үзен пәйгамбәр дип йөртүче синме?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әйе», – дип җавап бирде. Ир: «Гамәлләрнең кайсысы Аллаһыга сөеклерәк?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләгә ышану», – дип җавап бирде. Ир кеше: «Аннан соң нинди?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кардәшләрнең хәлен белү өчен күрергә бару», – дип әйтте. Ир кеше: «Монан соң нинди?» – дип сорады. Пәйгамбәребез: «Аллаһы Тәгалә кушкан эшләргә боеру һәм ярамаган эшләрдән тыю», – диде. Ир кеше: «Гамәлләрнең кайсысы Аллаһы Тәгаләгә нәфрәтлерәк?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһыга ширек кылу», – дип җавап бирде. Ир кеше:

«Моннан соң нинди?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кардәшләрнең хәлен белмәү», – диде. Ир кеше: «Моннан соң нинди?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә кушкан эшләргә әмер кылудан туктау һәм Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдән тыюны ташлау», – дип җавап кайтарды.

Суфьян Әс-Сәүри болай дип әйткән: «Әгәр укучыны күршеләре хакында ачуланган итеп, яисә кардәшләре каршында макталган итеп күрсәң, аны йомшаклык кылучы һәм алдаучы, дип бел».

Факыйһ үзенең иснәде белән Габдулла бине Җәрирдән, ул атасыннан риваять итә. Аның атасы болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәр кавемдә гөнаһ кылучы кеше булса һәм аларның ул ирне үзгәртергә, ягъни гөнаһ кылуын ташлатырга көчләре җитеп тә, аны ташлатмасалар, Аллаһы Тәгалә аларның барчасын гөнаһлы итәр, шул гөнаһ өчен үлмәстән беренче аларга газап җибәрер», – диде.

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм көчләре җиткән кешеләргә ачыктан-ачык гөнаһ кылучы кешеләрне тыюны вәҗиб иткән, чөнки Аллаһы Тәгалә бу өммәтне кешеләрне гөнаһтан тыйганнары өчен мактады. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ ۗ وَلَوْ آمَنَ أَهْلُ الْكِتَابِ لَكَانَ خَيْرًا لَّهُم ۚ مِّنْهُمُ الْمُؤْمِنُونَ وَأَكْثَرُهُمُ الْفَاسِقُونَ ﴿١١٠﴾

**«Кешеләр [мәнфәгатьләрен кайгыртыр] өчен [мәйданга] чыгарылган өммәтләрнең иң яхшысы сез булдыгыз [Ий, Мөхәммәд өммәте! Аллаһының мәңгелек гыйлемендә дә, Ләүхүл-Мәхфүздә дә бу саклана]. Яхшы гамәлләрне әмер итәсез, начар гамәлләрдән тыясыз һәм Аллаһыга ышанасыз. Әһле китап**

**та [сезнең кебек ахыр заман пәйгамбәренә һәм ул китергән дингә] иман китерсә, үзләре өчен [инкяр итеп, кулга төшергән дөньядагы җитәкчелек, югары урыннардан] яхшырак булыр иде. Алар арасыннан [Габдулла бине Сәлам һәм аның иптәшләре кебек] инанучылар бар. Ләкин аларның күпчелеге – [хак юлдан тайпылган] фасикълар».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

«Күнтүм хайра үммәти» сүзенең мәгънәсе шуны аңлата: Ләүхүл-Мәхфүздә болай дип әйтелгән: «Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтен кешеләрне өйрәтүче иң яхшы өммәт итеп чыгарды». Бу өммәт Аллаһы Тәгалә кушкан нәрсәләргә боера һәм ярамаган эшләрдән тыя, ягъни гөнаһ ияләрен гөнаһтан тыя. Яраган эш – ул Китапка һәм акылга туры килгән нәрсәдер, китап – Коръәндер. Ярамаган нәрсә – акылга һәм Коръәнгә туры килмәгән нәрсәдер».

Икенче аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلْتَكُن مِّنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ﴿١٠٤﴾

**«Арагызда [дини һәм дөньяви] хәергә [файдалы эшләргә] чакыра, яхшы гамәлләрне [кылуны] әмер итә, начар гамәлләрдән тыя торган җәмәгать булсын. Менә шулар – уңышка ирешүчеләр».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:104

Бу «вәлтәкүн» сүзендәге «ләм» хәрефе әмер хәрефедер, ягъни сездән Аллаһы кушкан нәрсәләргә әмер кыла һәм ярамаган нәрсәләрдән тыя торган төркем булсын. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә изгелеккә боеруны һәм начарлыктан тыюны ташлаулары сәбәпле кавемнәрне хурлады. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

كَانُوا لَا يَتَنَاهَوْنَ عَن مُّنكَرٍ فَعَلُوهُ ۚ لَبِئْسَ مَا كَانُوا يَفْعَلُونَ ﴿٧٩﴾

**«Алар үзләре кыла торган начарлыктан бер-берләрен тыймыйлар иде. Алар кылган бу [гөнаһларга карата ваемсыз] эш никадәр начар иде».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:79

Аллаһы Тәгалә икенче аятьтә болай дип әйтә:

لَوْلَا يَنْهَاهُمُ الرَّبَّانِيُّونَ وَالْأَحْبَارُ عَن قَوْلِهِمُ الْإِثْمَ وَأَكْلِهِمُ السُّحْتَ ۚ لَبِئْسَ مَا كَانُوا يَصْنَعُونَ ﴿٦٣﴾

**«Нишләп [үзләрен Аллаһыга баглы дип санаган] раббани кешеләр һәм галимнәр гөнаһ [булган ялган] сөйләүләреннән, [ришвәт һәм риба кебек] харам ашауларыннан аларны тыймыйлар соң? Һичшиксез, алар кылган ул нәрсә никадәр начар».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:63

Яраган һәм китапка килешкән эшләрне әгәр яшерен боерырга көче җитсә, боеручыга яшерен боеру тиешле буладыр, чөнки яшерен җирдә боеру вәгазь һәм үгет урынында боерудан катырак һәм яхшырактыр.

Әбү Дәрдә радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Берәү үзенең кардәшенә кешеләр алдында вәгазь кылса, дөреслектә, аңа карата начарлык кылды, гаепләде. Әгәр берәү үзенең кардәшен яшерен үгетләсә, дөреслектә, аны зиннәтләде. Әгәр кардәшенә яшерен вәгазь файда бирмәсә, ачык итеп, аны кеше алдында вәгазьләсен. Кешене бозыклыктан саклау өчен, яхшы һәм изге кешеләрдән ярдәм сорау кирәк. Әгәр алар аны гөнаһлы эшләрдән тыймасалар, гөнаһ ияләре аларны җиңәрләр һәм аларга газап килер. Ул газап аларның барчасын һәлак итәр».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Ногман бине Бәшир радыяллаһу ганһедән риваять итә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи

вә сәлләм болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең хакларында йомшаклык кылучының ул хакларга төшүченең һәм анда торучының мисалы көймәдә булган өч кешенең охшашы кебектер. Алар үзләренең урыннарын бүлештеләр: аларның берсенә көймәнең югарысы, икенчесенә көймәнең уртасы һәм өченчесенә ул көймәнең түбән тарафы була. Шул вакытта аларның берсе өтергә алса, аннан: «Нәрсә телисең?» – дип сорарлар. Ул: «Миңа су якынрак булсын өчен урыныма тишек тишәм», – дип әйтер. Аларның кайберләре: «Аны калдырыгыз, Аллаһы Тәгалә аны ерак кылсын, теләсә ни эшләсен», – дияр. Ә көймә халкының икенчеләре: «Аны көймәне тишкән хәлдә ташламагыз, безне дә, үзен дә һәлак итәр», – дип әйтер. Әгәр көймә халкы ул тишүчене кулыннан тотып алсалар, үзләре дә котылырлар һәм аны да коткарырлар. Әмма кулыннан тишә торган нәрсәсен алмасалар, үзләре дә һәм ул кеше дә һәлак булыр».

Әбү Дәрдә радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә кушкан һәм Коръәнгә килешле нәрсәне, әлбәттә, әмер кылырсыз һәм ярамаган нәрсәдән тыярсыз, гөнаһны гафу итүне һәм ярлыкауны сорарсыз, аларны Аллаһы Тәгалә ярлыкамас».

Хөзәйфә радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үзем аның кулында булган Зат белән ант итәм, ягъни Аллаһы белән ант итәм. Аллаһы Тәгалә кушкан эш белән, әлбәттә, боерырсыз һәм ярамаган эшләрдән, әлбәттә, тыярсыз. Яхшылыкка өндәмәсәгез, Аллаһы Тәгаләнең Үз тарафыннан сезгә газапны җибәрүе бар. Моннан соң Аллаһыга дога кылсагыз да, сезнең өчен кабул ителмәс».

Хәзрәти Гали радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр минем өммәтем залимгә:

«Син залим», – дип әйтүдән курыкса, аларны (игелек) калдырды».

Әбү Сәгыйд Әл-Хөдри радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Сездән берегез ярамаган эшне күрсә, аны кулы белән үзгәртсен. Әгәр көче җитмәсә, теле белән, әгәр моңа да көче җитмәсә, күңеле белән үзгәртсен. Бу күңел белән генә үзгәртү иманның иң зәгыйфедер. Ягъни иман әһеленең эшләренең иң зәгыйфедер». Кайберәүләр болай дип әйттеләр: «Кул белән үзгәртү түрәләр өчен, тел белән үзгәртү галимнәр өчен, күңел белән үзгәртү барча халык өчендер». Кайберәүләр әйтте: «Һәркемнең үзгәртергә көче җитсә, аңа аны үзгәртү вәҗибтер».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Яхшы эшләргә әмер иткән кешегә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын һәм диннең газизлеген максат итү тиешле. Үз ачуын күрсәтергә теләмәсә, яхшылыкка өндәү белән бары тик Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын һәм диннең газизләнүен максат итсә, ул кешегә Аллаһы Тәгалә ярдәм бирер. Аллаһы Тәгалә аңа моны килешле итәр. Әгәр аның өндәве үзенең гайрәтен күрсәтү өчен булса, Аллаһы Тәгалә аны хур итәр».

Гакрәмә радыяллаһу ганһедән безгә болай дип ирешкән: «Дөреслектә, бер ир гыйбадәт кылына торган агач яныннан үткәндә ачуланып, болай дип әйтте: «Аллаһыга гыйбадәт кылмыйча, бу агачка гыйбадәт кылынды». Моннан соң ул кеше икейөзле балтасын алды, ишәгенә атланып, ул агачны кисү өчен агач тарафына юнәлде. Юлда аңа кеше кыяфәтендә Иблис очрады. Иблис аннан: «Кая барасың?» – дип сорады. Ул кеше: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт ителә торган бер агачны күрдем. Аллаһы Тәгаләгә ишәгемә атланып, балтаны алып, ул агач тарафына юнәлеп, аны кисәргә вәгъдә бирдем», – дип җавап бирде. Иблис аңа: «Сиңа һәм агачка ни булды? Ул агачны һәм ул агачка гыйбадәт итә торган кешеләрне калдыр, кисмә. Аларны Аллаһы Тәгалә ерак кылсын», – диде. Болар ике-

се бәхәсләштеләр, хәтта өч мәртәбә сугыштылар. Иблис гаҗиз булгач һәм бу кеше сүзеннән кайтмагач, аңа: «Сүзеңнән кайт, мин сиңа һәр көнне дүрт дирһәм бирермен. Һәркөн түшәгеңне күтәрерсең һәм анда дирһәмнәрне күрерсең», – диде. Моны ишетеп бу кеше: «Син, чыннан да, шулай кылырсыңмы?» – дип сорады. Иблис: «Әйе, кылырмын. Бу синең өчен һәр көн түләнер», – диде. Ул ир урынына кайтты. Бу дүрт дирһәмне ике яки өч көн яисә Аллаһы Тәгалә теләгән кадәр тапты. Моннан соң таң аткач, түшәген күтәрде, бер әйбер дә күрмәде, дирһәмнәрне тапмаганнан соң, икейөзле балтасы алып, ишәккә атланды. Аңа Иблис янә кеше сурәтендә очрады һәм ул кешегә: «Кая барасың?» – диде. Кеше: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт ителә торган агачка, ул агачны кисәргә телим», – диде. Иблис аңа: «Моңа көчең җитмәс. Беренче мәртәбә чыгуың һәм ачуың Аллаһы Тәгалә өчен булды. Шул вакытта күкләр һәм җирнең кешеләре җыелсалар, сине кайтара алмаслар иде. Әмма хәзер чыгуың үзең өчен генә, чөнки дирһәмнәрне тапмадың. Әгәр анда барсаң, муеныңны кисәрбез», – диде. Ул ир агачны калдырып үзенең өенә кайтты».

Факыйһ Әбү Ләйс радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Яхшыга өндәүче биш нәрсәгә мохтаҗ булыр. Аларның беренчесе – гыйлем, чөнки җаһил (надан) яхшылыкка өндәүне күркәм итеп башкара алмас. Икенчесе, ул өндәве белән Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын һәм диннең ныгуын максат итүенә. Өченчесе, яхшылыкка өнди торган кешесенә йомшаклык һәм сөю белән миһербанлык кылуына. Авыр, яман һәм кире холыклы булмас, чөнки Аллаһы Тәгалә Муса белән Һарун галәйһимуссәламне Фиргавенне үгетләр өчен җибәргәндә болай дип әйтте:

فَقُولَا لَهُ قَوْلًا لَّيِّنًا

**«Аңа йомшак бер сүз әйтегез».**

«Та Һа», 20:44

Дүртенчесе, бик сабыр, түземле һәм авырлыкны күтәрә торган булуына, чөнки Аллаһы Тәгалә Локман кыйссасында әйтте:

وَأْمُرْ بِالْمَعْرُوفِ وَانْهَ عَنِ الْمُنكَرِ وَاصْبِرْ عَلَىٰ مَا أَصَابَكَ ۖ

**«...яхшы дип беленгән нәрсәне әмер ит, [дин һәм акыл ягыннан] яхшы дип танылмаган нәрсәдән тый һәм сиңа килгән [авырлыклар кебек] нәрсәләргә сабыр ит».**

«Лукман», 31:17

Бишенчесе, гаепләре йөзенә орылмасын өчен, кушкан эшне беренче үзе кылыр, аннан соң кешегә кушар, чөнки Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ

**«Әллә сез кешеләргә игелек әмер ителә торып та, үз-үзләрегезне онытасызмы?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мин күкләргә ашкан кичтә, ягъни мигъраҗ кичәсендә ирләрне күрдем. Аларның авызлары кылычлар белән киселә иде. Мин: «Әй, Җәбраил, болар кемнәр?» – дип сорадым. Җәбраил галәйһиссәлам: «Синең өммәтеңнән булган кешеләрне яхшылыкка өндәүче хатыйблар. Алар үзләрен оныттылар. Аллаһы Тәгаләнең Китабын укысалар да, анда булган нәрсә белән гамәл кылмадылар», – дип әйтте.

Котәдә радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Безгә Тәүратта язылган нәрсәләрнең берсе хәбәр ителде: «Әй, Адәм улы, Мине искә алдырасың һәм үзең Мине онытасың. Миңа өндисең, үзең Миннән качасың. Сез бара

торган бу юл дөрес түгелдер».

Мөгавия үзенең иснәде белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу көндә сез Аллаһы Тәгаләнең ачыклыгында, ягъни Аллаһының ачык бәянендә. Хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгалә сезгә юлыгызны ачык күрсәтте. Сездә ике исереклек заһир булмас: берсе тереклек исереклеге һәм икенчесе наданлык исереклеге. Бу көндә Аллаһы кушкан эш белән боерасыз, ярамаган эштән тыясыз. Аллаһы Тәгалә юлында сугыш кыласыз, моннан тиз әйләнерсез. Әгәр сездә дөньяны сөю барлыкка килсә, яраган нәрсә белән әмер кылмассыз, ярамаганнан тыймассыз. Бу көндә китапны торгызучылар беренчесе үткән мөһаҗирләрдән[1] яисә әнсардан[2] булучылар яшерен һәм ачыктыр».

Хәсән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр берәү үзенең дине өчен бер җирдән икенче җиргә күчсә, хәтта бер генә карыш булса да, дөреслектә, җәннәтне вәҗиб итте. Ул кешегә Ибраһим галәйһиссәлам һәм үзенең пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм иптәш булыр. Ягъни, дөреслектә, Ибраһим галәйһиссәлам Хәрран иленнән Шамга күчте. Бу Аллаһы Тәгалә сүзеннән мәгълүмдер:

وَقَالَ إِنِّي مُهَاجِرٌ إِلَىٰ رَبِّي ۖ إِنَّهُۥ هُوَ ٱلْعَزِيزُ ٱلْحَكِيمُ ﴿٢٦﴾

**«Ул [Ибраһим [галәйһиссәлам] исә әйтте: «Һичшиксез, мин [мөшрик кавемем булган Күфә тирәсеннән китеп] Раббыма һиҗрәт итәм. Һичшиксез, Ул – Бөек [Җиңелмәс], Хикмәт иясе»;**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:26

1 Пәйгамбәребез артыннан Мәккәдән Мәдинәгә күчеп китүче сәхабәләре.

2 Нурлы Мәдинә сәхабәләре.

إِنِّي ذَاهِبٌ إِلَىٰ رَبِّي سَيَهْدِينِ ﴿٩٩﴾

**«Мин Раббыма [ул кушканнарга буйсынып] китәмен. Һичшиксез, Ул мине [дини һәм дөньяви бөтен максатларыма ирештереп] һидаять итәчәк».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:99

Дөреслектә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдән Мәдинәгә күчте. Әгәр берәү гөнаһлар күп булган җирдә булса һәм ул җирдән Аллаһы Тәгаләнең риза булган урынын табу нияте белән чыкса, дөреслектә, ул кеше Ибраһим галәйһиссәлам һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иярде. Ул кеше җәннәттә аларның иптәше булыр.

۞ وَمَن يُهَاجِرْ فِي سَبِيلِ اللَّهِ يَجِدْ فِي الْأَرْضِ مُرَاغَمًا كَثِيرًا وَسَعَةً ۚ وَمَن يَخْرُجْ مِن بَيْتِهِ مُهَاجِرًا إِلَى اللَّهِ وَرَسُولِهِ ثُمَّ يُدْرِكْهُ الْمَوْتُ فَقَدْ وَقَعَ أَجْرُهُ عَلَى اللَّهِ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿١٠٠﴾

**«Кем дә кем Аллаһы юлында һиҗрәт кылса, җирдә сыену урыны һәм [ризык табу, динен тоту, күңел тынычлыгы мәсьәләсендә] иркенлек табар. Кем дә кем, Аллаһыга һәм Аның расүленә [алар әмер иткән җиргә] һиҗрәт итәр өчен, өеннән чыкканнан соң, [барасы җиргә барып җитә алмыйча] аңа үлем килсә, аның әҗерен бирү Аллаһыга төшә. Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:100

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бер мөселман Аллаһы Тәгалә һәм Аллаһының Расүле ризалыгы өчен, үзенең йортыннан һиҗрәт кылып чыкса, үзенең аягын дөя өзәңгесенә куеп, бер генә адым атлаганнан соң аңа үлем ирешсә, Аллаһы Тәгалә аңа һиҗрәт

итүчеләрнең әҗерләре охшашын бирер. Бер мөселман йортыннан Аллаһы Тәгалә юлын максат иткән хәлдә чыкса һәм сугышка кадәр аңа атланган хайваны аягы белән типсә яки аны елан чакса, яки ничек булса да үлсә, ул кеше шәһит булыр. Нинди генә мөселман үзенең йортыннан Бәйтуллаһ Әл-Харамга чыкса да, моннан соң Бәйтуллаһка ирешкәнче үлеме җитсә, Аллаһы Тәгалә аңа җәннәтне вәҗиб итәр».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Әгәр берәүнең Аллаһы Тәгаләнең фарызларын үтәргә көче җитеп тә, үз җиреннән һиҗрәт кылмаса, аңа үз җирендә торуда зарар юк. Аларның гөнаһларын мәкруһ күрер булса, ул гозерледер».

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Әгәр сезнең берәрегез ярамаган эшне күрсә һәм аны үзгәртергә көче җитмәсә, ул кешенең күңеле белән ярамаган бу эшне мәкруһ күрүен Аллаһы Тәгаләнең белүе җитәр».

Сәхабәләрнең берсеннән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Сездән берегез ярамаган эшне күрсә һәм аны кылучыны туктатырга көче җитмәсә, өч мәртәбә «Аллаһүммә иннә һәҙә мункәру фәлә туәхиҙни биһи», ягъни: «Әй, Аллаһым, бу ярамаган эш. Син мине гөнаһлы итмә», – дип әйтсен. Әгәр моны әйтсә, аңа яхшылыкка өндәүче һәм ярамаганнан тыючы кешенең савабы булыр».

Гомәр бине Җәбир радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Ул радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Әбү Сәгъләб Хәшнидән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا عَلَيْكُمْ أَنفُسَكُمْ ۖ

**«Ий иман китерүчеләр! Сез үзегезне [үзгәртү ягын] карагыз»,** – дигән аять турында сорадым.

«Әл-Маидә / Табын», 5:105

Әбү Сәгъләб болай дип җавап бирде: «Дөреслектә, ул аятьне белүчедән сорадың. Дөреслектә, мин ул аять турында Пәйгамбәребездән

сорадым. Ул салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа болай дип әйтте: «Әй, Әбү Сәгъләб, сез бер-берегезне изгелеккә чакырыгыз, начарлыктан тыегыз. Әгәр дөньяның мөлкәтенә һәм саранлыгына тәмам бирелгән кешене, янә һәр акыл иясе үз акылы белән үз-үзенә исе китә торган кешене күрсәң, сиңа үз-үзең белән шөгыльләнү тиеш булыр, башкага карама. Сездән соң сабыр итә торган көннәр булыр. Бу көндә туры юлга тотынучыга илле кеше гамәленең әҗере кадәр әҗер булыр». Сәхабәләр: «Әй, Расүлуллаһ, алардан яисә бездән булган илле гамәлнең әҗереме?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Юк, бәлки сездән булган илле гамәлнең әҗере кебектер», – дип җавап бирде.

Кайс бине Әбү Хаземнән риваять ителә. Ул болай дип әйткән: «Әбү Бәкер радыяллаһу ганһедән ишеттем. Ул радыяллаһу ганһе болай дигән: «Дөреслектә, сез бу аятьне укыйсыз һәм ул аятьне үз урыныннан икенче урынга куясыз:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا عَلَيْكُمْ أَنفُسَكُمْ ۖ لَا يَضُرُّكُم مَّن ضَلَّ إِذَا اهْتَدَيْتُمْ ۚ إِلَى اللَّهِ مَرْجِعُكُمْ جَمِيعًا فَيُنَبِّئُكُم بِمَا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ﴿١٠٥﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сез үзегезне [үзгәртү ягын] карагыз. Әгәр сез [изгелеккә өндәп һәм явызлыкны тыеп] һидаятьтә булсагыз, [туры юлдан] адашкан кеше сезгә зарар бирмәс. Сезнең һәммәгезнең кайтуыгыз – Аллаһыга гына. Шуннан ул сезнең ни кылганнарыгызны сезгә хәбәр итәчәк».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:105

Дөреслектә, мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеттем. Ул болай дип әйтте: «Дөреслектә, әгәр кешеләр гөнаһлы кешене күреп, аны туктатмасалар, аларның барчасын Аллаһы Тәгаләнең тарафыннан булган газап белән һәлак кылу якын».

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, аннан радыяллаһу ганһе бу аять турында сорадылар. Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Моның заманы бу заман түгел, шулай булса да аларның нәфес теләкләре күбәйсә, бәхәсләрен торгызсалар, һәр кешегә үзе мәҗбүри булсын». Ул аятьнең тәфсире килде, ягъни бу заманда һәр эш шул рәвешчәдер.

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан*

# Төшенкелеккә бирелү – шәйтаннан

Еш кына тормыш китергән авырлыклар турында милләтәшләребез белән сөйләшкәндә, кайберләренең авызыннан, Аллаһыга ышанучы мөэмин кеше һичкайчан әйтергә тиеш булмаган сүзләрне ишетергә туры килә. Әйе, рухи тетрәнүләрен, күңелендәгеләрне кеше сабырсызланып теленә чыгарырга ашыкса да, рухи төшенкелеге турында бар кеше дә ишетердәй сөйли икән, димәк, ул үзенең җиңелүе һәм шул хәлдә шәйтанга бирелүе хакында игълан итә. Нигә? Мәкаләдә шул хакта сүз барыр.

Билгеле булганча, шәйтан үзенең итагатьсезлеген аклар, балчыктан яратылган һәм Раббыбыз Үзенә сәҗдә кылдырган Адәмнең өмет багларлык бер мәхлүкъ түгеллеген исбатлар өчен, барысын да эшләячәге турында ант иткән. Коръәндә болай дип әйтелгән:

قَالَ فَبِمَا أَغْوَيْتَنِي لَأَقْعُدَنَّ لَهُمْ صِرَاطَكَ الْمُسْتَقِيمَ ﴿١٦﴾ ثُمَّ لَآتِيَنَّهُم مِّن بَيْنِ أَيْدِيهِمْ وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَن شَمَائِلِهِمْ ۖ وَلَا تَجِدُ أَكْثَرَهُمْ شَاكِرِينَ ﴿١٧﴾

**«Ул әйтте: «Мине аздырганың өчен, мин Синең туры [Ислам] юлыңда, һичшиксез, аларга каршы [киртә булып] утырачакмын. Аннары мин аларга – алларыннан һәм артларыннан, уңнарыннан һәм сулларыннан [вәсвәсәләр бирер өчен, һәр дүрт тарафларыннан] киләчәкмен, һәм Син аларның күпчелеген шөкер итүчеләр буларак тапмаячаксың».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:16-17

Күргәнебезчә, шәйтанның адәм балаларын туры юлдан тайпылдыруның беренче һәм төп ысулы – күңелләрендә шөкерсезлек һәм канәгатьсезлек хисләрен кузгату. Димәк, галәмнәр Раббысы белән бәхәсләшүен оныткан шәйтан кебек мәңгелек хәсрәткә дучар булмас

өчен, авырлыкларга зарланып, яшәеше белән канәгать булмаган кеше, иң башта тормышындагы барлык нәрсәләрнең анықы булмавын, аңа бушлай бирелгәнен, һәм ул үзе билгеләмәгән кануннар буенча яшәвен искә төшерергә тиеш. Бу – шәйтан һәм аның вәсвәсәләренә каршы иң ышанычлы корал һәм иң чыдам калкан! Боларны исендә тотмаган кеше тормышы һәм язмышы белән канәгать булмыйча, дөньяви югалтулары сәбәпле, гел газапланып һәм үкенеп яшәячәк.

## «Бүре көтүдән аерылган сарыкны гына ашый»

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә кулыбыздагы нигъмәтләрне ким күрмәвебез, һәм шул сәбәпле чынбарлыктан ерак китмәвебез өчен, тормышны аек акыл белән бәяләргә өйрәткән. Ул болай дип әйтә торган булган: «(Халәтләре) сездән түбән булган кешеләргә карагыз һәм сездән югары булган кешеләргә карамагыз. Бу Аллаһының бер нигъмәтен дә ким итеп күрмәскә ярдәм итәр»[1], – дигән.

Хәлләре безнекеннән тагы да авыррак, һәм, киресенчә, рухи яктан үзебездән көчлерәкләрне күрер һәм алардан үрнәк алыр өчен, мөселман кешесенең гел кеше арасында булуы кирәк. Кеше арасында булу – аны шәйтан тозагы – күңел төшенкелегеннән һәм депрессиядән саклый. Шуңа күрә дә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөэмин-мөселманнарны җәмгыятьтән читләшмәскә, иҗтимагый чараларда, һәм бигрәк тә җәмәгать намазларында катнашырга чакырган, чөнки кеше үзенең уйлары, куркулары һәм яшерен теләкләре белән ялгыз калганда шәйтан өчен җиңел ауга әйләнә. Имам Әбү Давыдның җыентыгында килгән бер хәдистә моның турында болай диелә: «Җәмәгать белән бергә бул, чөнки бүре көтүдән аерылган сарыкны гына ашый».

1 Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим, Әхмәд бине Хәнбәл.

## «Аллаһы кешеләрне яратса, аларга сынау җибәрә»

Әмма кеше күпме сакланса да, Аллаһыга күпме сыенса да, бу дөньяга килгәч, сыналмыйча калуы мөмкин түгел. Көтмәгәндә килеп чыккан проблемалар кешене кайчакта мал-мөлкәтеннән, ирегеннән һәм хәтта сәламәтлегеннән мәхрүм итә. Мондый сынаулар каршында мөэмин кеше үзен ничек тотарга тиеш? Вәгазебезнең башында әйткәнебезчә, бу – кешенең тормышка карашыннан тора. Мөэмин кеше тормышындагы һәрбер нәрсәгә – аңа ата-анасыннан калган мирас һәм Аллаһы Тәгаләдән вакытлыча файдалануга бирелгән әманәт итеп карый, һәм шул сәбәпле, тормышындагы һәрбер вакыйганың нәрсә өчен килеп чыкканлыгын аңлап гомер итә. Коръәннең күп кенә аятьләрендә, җирдәге тормыш шартлары тереклек, һәм бигрәк тә кеше тормышы өчен иң уңайлы рәвештә яратылганлыгы; җирдәге һәрнәрсә кеше һәм аның иминлеге өчен барлыкка китерелгәнлеге турында сөйләнсә дә, кеше бу дөньяга килүгә күп кенә бүтән тереклек процесслары белән тыгыз бәйләнешкә керә. Кайчак, үзе дә белмичә, яки үзеннән тормаган сәбәпләр аркасында, кеше галәмдәге бу төзеклекне бозып, уңайсыз шартларда кала, һәм шуның өчен газап чигә. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

أَيْنَمَا تَكُونُوا يُدْرِككُّمُ الْمَوْتُ وَلَوْ كُنتُمْ فِي بُرُوجٍ مُّشَيَّدَةٍ ۗ وَإِن تُصِبْهُمْ
حَسَنَةٌ يَقُولُوا هَٰذِهِ مِنْ عِندِ اللَّهِ ۖ وَإِن تُصِبْهُمْ سَيِّئَةٌ يَقُولُوا هَٰذِهِ مِنْ
عِندِكَ ۚ قُلْ كُلٌّ مِّنْ عِندِ اللَّهِ ۖ فَمَالِ هَٰؤُلَاءِ الْقَوْمِ لَا يَكَادُونَ يَفْقَهُونَ
حَدِيثًا ﴿٧٨﴾ مَّا أَصَابَكَ مِنْ حَسَنَةٍ فَمِنَ اللَّهِ ۖ وَمَا أَصَابَكَ مِن سَيِّئَةٍ فَمِن
نَّفْسِكَ ۚ وَأَرْسَلْنَاكَ لِلنَّاسِ رَسُولًا ۚ وَكَفَىٰ بِاللَّهِ شَهِيدًا ﴿٧٩﴾

**«Кайда гына булсагыз да, үлем сезгә [һичшиксез] ирешәчәк, хәтта сез биек итеп салынган ныгытылган [сарай яки] кальгаларда булсагыз да. Әгәр аларга [яһүдиләр белән монафикъларга муллык һәм тынычлык кебек] берәр яхшылык тисә [ул нигъмәтне Аллаһыга нисбәт итеп]: «Бу – Аллаһының Үзеннән» – дип әйтәләр. Әмма [фәкыйрьлек һәм кытлык кебек] берәр начарлык килсә [аны синнән күреп]: «Бу – синнән [һәм синең уңмаганлыгыңнан]», – диләр. [Расүлем!] Әйт: «[Мин бернәрсә дә ярата алмаганлыктан, яратылу ягыннан] Барысы да – Аллаһының Үзеннән». Бу җәмәгатькә ни булды ки, алар [Аллаһы тарафыннан килгән] бер сүзне дә аңлый алмыйлар? [Ий кеше!] Сиңа берәр яхшылык килсә, ул [синең тырышлыгың белән булмыйча] – Аллаһыдан. Әмма сиңа берәр начарлык килсә, [ул да сәбәп булу ягыннан] синең үзеңнән. [Расүлем!] Без сине кешеләргә [илчелек вазифасын йөкләп] бер Расүл салләллаһу галәйһи вә сәлләм буларак җибәрдек [мәгәр бер яратучы, бар итүче итеп җибәрмәдек, алар башларына килгән бәлаләрне синнән дип беләләр]. [Дәгъваңда] Шаһит буларак Аллаһы җитә».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:78-79

Димәк, Аллаһы кешеләргә начарлык теләми һәм кеше тормышындагы һәрнәрсә иминлек һәм бәхетле тормыш өчен яратылган. Дөнья тормышында кеше белән була торган бәхетсезлекләр һәм бәла-казаларга килгәндә, алар кешенең гамәлләре яки гамьсезлеге нәтиҗәседер.

Гомумән алганда, бу шулай, чөнки әгәр тормышка атеист кеше күзләре белән карасак та, Җирдә булган һәрнәрсәнең тереклек өчен яратылуы, тереклек өчен эшләп килүе, тереклекнең дәвам итүе өчен яратылганлыгы күренә. Шуңа күрә иманлы кеше, тормышы һәм язмышы никадәр ачы һәм авыр булса да, зарланырга ашыкмас, һәрнәрсәдә Аллаһының

хикмәтен күрергә тырышыр, чөнки ул бу дөньядагы һәрнәрсәнең махсус бер вазифа башкарганлыгына ышанып яшәр. Сынауларга чыдамыйча, тормыш һәм язмышына зарланучы мөэмин Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән рухи дәрәҗәсен генә төшерер.

Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Мөэмин кешенең әҗер-савапларының зурлыгы – дучар булган сынаулар һәм авырлыклар зурлыгына тиң. Һәм әгәр дә Аллаһы кешеләрне яратса, Ул аларга сынаулар җибәрә. Сынауларны шөкер итеп кабул иткән кеше Аллаһының ризалыгын, ә язмышын тиргәгән кеше – Аның ачуын табар»[1].

«Иң зур сынауларга пәйгамбәрләр һәм алар кебекләр дучар була. Һәр кеше иманына карап сынала. Кешенең иманы никадәр нык булса, аңа килгән сынаулар да шул кадәр көчлерәк булыр. Һәм кеше җир йөзендә бөтенләй гөнаһсыз (гөнаһлардан һәм хаталардан чистарынган) хәлдә йөргәнчегә хәтле бу сынаулар һич туктамас»[2].

## «Сабыр итүчеләрне җәннәт белән сөендер!»

Димәк, мөэмин кешенең тормышында төшенкелеккә урын булмаска тиеш, чөнки мөэмин кеше гомере буена тереклек һәм яктылык чыганагын – Аллаһыны эзли, Аңа ышана, Аңа омтыла. Мөэмин кеше үлемнән дә, ачлыктан да, матди югалтулардан да курыкмас. Мөэмин кешене бердәнбер борчый торган нәрсә – ул тормышын Аллаһы теләгән рәвешкә китерү, һәм бу дөньядан иманлы хәлдә китү. Коръәндә әйтелгәнчә:

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَيْءٍ مِّنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنفُسِ
وَالثَّمَرَاتِ ۗ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٥﴾ الَّذِينَ إِذَا أَصَابَتْهُم مُّصِيبَةٌ قَالُوا

---

1 Имамнар Әт-Тирмизи, Ибне Мәҗе.

2 Имамнар Әхмәд, Әт-Тирмизи, Ән-Нәсаи, Ибне Мәҗе.

إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ ﴿١٥٦﴾ أُولَٰئِكَ عَلَيْهِمْ صَلَوَاتٌ مِّن رَّبِّهِمْ
وَرَحْمَةٌ ۖ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُهْتَدُونَ ﴿١٥٧﴾

**«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер! Берәр бәлагә юлыкканнар: «Һичшиксез, без – Аллаһынықылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!» – дип әйтәләр. Әнә шулар – Раббыларының мәгъфирәтенә һәм рәхмәтенә ирешүчеләр, һәм әнә шулар – [башларына төшкән бәлаләргә сабыр итеп, туры юлга] һидаять табучылар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155–157

Тормышларында Аллаһының аятьләрен һәм катнашын күрмичә яшәүчеләрнең тормышы һәрвакыт рухи тетрәнүләр белән тулы булачак, андыйлар турында Коръәндә болай дип әйтелгән:

وَالَّذِينَ كَفَرُوا بِآيَاتِ اللَّهِ وَلِقَائِهِ أُولَٰئِكَ يَئِسُوا مِن رَّحْمَتِي وَأُولَٰئِكَ لَهُمْ
عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿٢٣﴾

**«Аллаһының могҗизаларын һәм Аның белән очрашуны инкяр итүчеләр [Кыямәт көнендә] – Минем рәхмәтемнән өмет өзгәннәр. Аларга тилмерткеч газап [әзерләнгән]».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:23

*Альберт Кадыйров,*

*Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе мәчете мәхәллә әгъзасы,*

*тәрҗемәче*

# Әдәби сәхифә

# Кайнар диңгез юлы

## Салкын җил җылысы

*Дәвамы. Башы алдагы саннарда*

Сургутның киң урамы буйлап Ханты-Манси округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов белән Рәйсә абыстай җәяүләп мәчеткә якынлашып килә. Себернең әче җиле колак яфракларын чеметә. Тик, алар аны сизмиләр. Егерме алты ел дәвамында салкын җилгә каршы көрәшеп, аларның тәннәре генә түгел, рухлары да чыныкты.

– Рәйсә, сизәсеңме, мәчет бинасыннан тирә-якка сирпелгән якты нур, әйтерсең лә, салкын җилне җылыта. Бу мәһабәт мәчетне Сургутка килеп яши башлаган вакытларда ук төшләремдә күреп саташтым. Йә Раббым, Сиңа нинди генә рәхмәтләр әйтсәк тә аз. Себер җирендә яшәүче мөселманнарны дингә тарту җиңел булмады, авыр юллар аша ирешелде, Аллаһ һәр эшебезне җиңеләйтергә ярдәм итте…

– Монда килгәч, узган юлыбызга әйләнеп карагач, үзебездәге ихтыяр көченә шаккатам. Хезмәт хакы да түләнмәде бит әле. Ашарга алырга акчабыз булмаган көннәребез дә байтак булды. Хәтереңдәме, Камилнең: «Бүген уразага гына керәсем калган икән», – дигән сүзе? Таһир хәзрәт башын кагып куйды. – Улымның шул сүзе йөрәгемә кадалып калды. Аллага шөкер, тамаклары туеп кайта дип, мәҗлесләргә балалар белән барганга куана идем. Нинди көннәребез бар иде, хәзрәт. Казыксыз җирдә казык кагудан башланган тормыш юлы буйлап атлый-атлый, пенсия яшенә килеп җиттек бит.

– Минем күңелдә Әлфинурның сүзе калды. Гает көнне барыбызны да Галия апа мәҗлескә чакырды. Шуннан кайткач: «Бүген безгә дүрт сөлге, дүрт эскәтер бирделәр», – дип куанып, әнигә шалтыратып әйткәнен хәтерлим. – Аннары судья Гарифҗан абыйның хатыны Фәния апа да авыр вакытта бик ярдәм итте безгә. Хәтереңдәме, бер тартма сгущенка

китергәне?

– Яхшылык онытыламы соң? Барысын да хәтерлим... Таһир хәзрәт адымын әкренәйтте.

– Соңгы вакытта монда үткән гомер юлыбыз турында еш уйлыйм. Безгә күрсәткән ярдәме өчен Аллаһка рәхмәт укыйм. Күңелләренә Аллаһ иман иңдергән җитәкчеләребез белән бергәләп Себер җирендә нинди зур эшләр башкарылды! 1995 елдан башлап, Ханты-Манси округы буенча Когалым, Нефтюганск, Федоровка бистәсендә, Нижневартовск, Лангипаст шәһәрләрендә нинди зур мәчетләр салынды!

– Ул елларда син айга ничә көн өйдә кундың икән? Мәчетләрнең документлары буенча айга ничә тапкыр Уфага барганыңны хәтерлисеңме? Ул шәһәрләрдә мәхәллә төзегән вакытларыңны исеңә төшергәнең бармы? Имамнар куя башлагач, нинди ызгышлар аша уздың? Дипломант акылы белән идарә итә алганың өчен генә барысын да җайга сала алдың, хәзрәт.

– Күпмилләтле халык яши торган шәһәрләрдә дини вәзгыять катлаулы юллар аша хәл ителде. Чәчән белән дагыстан халкы имам итеп үз кешесен куярга омтылды. Ул елларда милли политиканы дөрес юлдан алып бару иң җитди бурыч булды. Мәчетләргә чит республикадан килгән халыкларның хуҗа булырга тырышуы җирле халык белән ике арада киеренкелек барлыкка китерде. Безнең диндә имамнарның халык тарафыннан сайланып куелу тәртибе юклыгын аңларга теләмәделәр. Имамнар мөфти тарафыннан шәһадәтнамә белән билгеләнеп куелганын аңнарына сеңдергәнче күпме көч куелды. Әгәр дә халык тарафыннан сайланып куела торган булсамы, хәтта күз алдына китерүе дә куркыныч, һәр милләт үзенекен сайлар да, ызгыш-талаш, фетнә барлыкка килер иде. Исеңдәме, Когалым шәһәрендә имам итеп Хәйдәр хәзрәтне куйдык кына, икенче көнне кыйнап киттеләр. Без сайлап куйган имамнарга буйсынмаска тырыштылар. Бездә бер генә төрле – Әбү Хәнифә мәзһәбе икәнлеген аңлату өчен мәчетләрдә кунарга калган вакытларымны искә төшерсәм, хәзер дә

тәнем чемерди башлый. Аллага шөкер, барысы да ипләп кенә җайлашып китте. Имамнарга һаман да күп милләтле халык белән уртак дипломатия саклау сәясәтен аңлатуны туктатырга ярамый.

Рәйсә абыстай ул еллардагы авырлыкларны күз алдыннан үткәрде. Ханты-Манси шәһәренә паром белән барган вакытларын исенә төшерде. Хатынының уйларын укыгандай:

– Хәйдәр хәзрәт каршылыкларга нык торды ул. Шул чорда чалланып калганга, шул округның мөфтие итеп билгеләнде дә инде ул, – диде Таһир хәзрәт. Бераз сүзсез барды: – Булдыра алганның барысын да үз вакытында эшләдек. Ерак Көнчыгыш Сахалин, Владивосток, Блоговещенск, Чита, Иркутск шәһәрләрендә дә мәхәллә төзеп, мәчетләр торгызылды. Үзләре ярдәм сорап, миңа хат яздылар. Сургут мәчете манарасыннан сирпелгән изге нур яктысы, аларның иманнарын уятты.

Абыстайның уйлары янә үткәннәргә барып тоташты. Иренең Себер һәм Ерак Көнчыгыш мөфтие итеп билгеләнгәч, баш-аягы белән эшкә чумган елларны күз алдына китерде. Мәчетләр салу өчен җирләр алып йөргәндә, атналар буе өйгә кайтып куна алмады. Телефон аша гына хәл белешеп тордылар. Сахалинга самолет белән унбер сәгать очарга кирәк. Кемерово һәм Иркутск шәһәрләрендә мәчетләр тапшырылгач, Таһир хәзрәт аның кулына «Халыклар дуслыгы» медале алып кайтып тоттырды.

– Үз бурычыбызны намус белән үтәгән өчен бирелде бу медаль, абыстаем, икебезгә дә дип кабул итик, – диде.

Рәйсә абыстай шул чакларны исенә төшереп, үз алдына елмаеп куйды. Дөньяда кешене изге гамәлләре йөртә шул. Таһире дә һәрдаим: «Кемгә нинди яхшылык эшләргә мөмкинлегебез бар, барысын да булдырырга тырышыйк», – дип әйтеп тора. Мәчеткә йөреп белем алган кешеләрне ике тапкыр ташламалы бәягә Хаҗга алып бардылар. Рәйсә абыстай Хаҗ гамәлен башкарганда, үзләренә һәм балаларына уңышлы тормыш сорады. Аллаһ ананың кулын күтәреп сораган үтенечен ишетте.

Уллары Камил Мәскәү университетында чит телләр факультетында укыды. Әлфинур укытучы һөнәрен сайлады. Кызларының тормышы үзләре кебек динне үстерүгә хезмәт итүче Самара егете белән бәйләнде. Камил Сургут мәчетенең имамы итеп билгеләнде. Килене Гөлназ да үзенә охшап килде. Ачык йөзе, ипле холкы, тыйнаклыгы өчен ярата ул аны. Буйга җитеп үсеп килүче өч оныгына карый да, үзенең гомер көзенә кереп барганын аңлый. Сургут шәһәрендә туган кызлары Сара, югары белем алыр өчен, туган ягына – Казанга кайтты. Кызын сагыну сылтавы белән, ул хәзер туган ягына ешрак кайта. Төпчек кызлары аларны туган якларына якынайтты. Үз уйларына уралып, мәчет комплексына килеп җиттеләр.

– Карале, әтисе, нинди матур безнең мәчетебез! Тирә-якка нур сибә! – диде абыстай, ихласлык белән куанып.

– Гомер юлыбыз, тормышыбыз Себер җирендә Аллаһ йортлары, мәдрәсәләр салу өчен багышланды, кадерле абыстаем. Мәчеттән сирпелгән иман нуры кешеләрнең күңеленә изгелек балкышы сала. Ә изге кеше – мәчетне урап уза алмый. Күрәсеңме, җомга намазына мөселман туганнарыбыз ташкын кебек агылып килә. Кайчандыр, олы хыял гына булса, бүген чынбарлык!

Таһир хәзрәт белән абыстай мәчет ишеге янына якынлашкач, төрле яктан сәламләп, аларга юл бирделәр.

...Җомга намазыннан соң, хәзрәт мәчет эшләре белән китте. Рәйсә абыстай үзенә тапшырылган вазифаларга кереште. Мәдрәсә ягына кереп, шәкертләрнең хәлләрен сорашты. Аскы катта урнашкан кибеткә узды... Мәчетнең беренче катында ашханә эшли. Аның урамнан керә торган ишеге дә бар. Көннең кайсы сәгате булуына карамастан, ашханәдә кеше һәрвакыт тулып тора. Хәләл ризык белән тукланырга теләүчеләрнең күп булуына куана абыстай. Никах мәҗлесләре дә шушы ашханәдә уздырыла.

Ул өстәл янына барып утыруга, мәдрәсәдә мөгаллимәсе Флера апа белән аның группасында укучы Фәния, Зәйтүнә, Әлфия апалар килде.

Ягымлы итеп, абыстайны үз итеп, яратып исәнләштеләр дә:

– Корбан бәйрәмендә чалырга сарыкларга заказлар җыя башладыгызмы әле, абыстай? – дип сорадылар.

– Әйе, – дип, сумкасыннан дәфтәрен алып, заказ бирүчеләрнең исемлеген күрсәтте.

Быел безгә биш сарык кирәк булачак. Корбан чалдырырга кирәклеген балаларыбыз гына түгел, оныкларыбыз да аңлый башлады, әлхәмдүлилләһи шөкер. Яшь вакытта кайлардан сарык табыйк икән дип, борчылып йөри идек. Менә бит, нинди рәхәт заманнар килде. Мәчеткә заказ гына бирәбез, чалып, эшен бетереп бирәләр. Аллаһның рәхмәтләре яусын, – диде Фәния.

– Арендага бина алып, сарык фермасы ясау бик дөрес булды, – дип, Флера апа ике баш сарыкка яздырды.

– Безнең гаиләләргә өчәрне языгыз, абыстай, – диде Фәнзүлә белән Әлфия.

– Апалар, әйдәгез, бергәләп чәй эчик, – диде Рәйсә абыстай.

– Бүген җомгада ике мәеткә җеназа намазы укылды, белгәннәрегез түгел идеме? – дип сорады Флера.

– Икесе дә өлкән кешеләр булган, балалары озата килде. Мәчет янында мәетханә булуына бик куандылар. Берсе – әтисен, икенчесе әнисен соңгы юлга дини кагыйдәләр буенча озатылуына куанып, кат-кат, рәхмәт әйттеләр. Зиратта каберне дә үзләре казыйсы түгел ич, махсус кешеләр хезмәт күрсәтә. Таһир хәзрәт Себер җирендә ислам динен югары дәрәҗәгә күтәрде. Бала туугa исем кушудан башлап, һәр мөселманны ислам дине кануннары белән яшәргә өйрәтә һәм соңгы юлга озату өчен дә барлык шартларны тудырды, – диде Әлфия.

– Таһир хәзрәт белән абыстай килеп эшли башлаган заманнарда монда диннең исе дә юк иде әле. Хәзер Сургутта мәчеткә килми торган татарлар калмагандыр. Җомга намазында гына бер мең биш йөз кеше

катнаша.

– Гаетләрдә гыйбадәт кылучылар саны унар меңгә җитә ич. Мәчет биләмәсендә алма төшәр урын калмый. И, кардәшләр, нинди заманда яшибез, Аллаһка хисапсыз шөкер, – дип, Флера апа мәдрәсәгә укырга йөрүчеләрнең дә елдан-ел арта баруын әйтте.

Рәйсә абыстай дусларының сүзләренә рәхмәтен әйтеп тыңлап утырды да:

– Менә шуның өчен дә, Сургутта тагын бер мәчет төзү өчен, җир участогы алырга йөри хәзрәт. Халык саны артып тора, бер мәчеткә генә сыешмыйлар, – диде дә, үзеннән-үзе хисләнеп сөйләп китте. – Гаетләрдә гыйбадәт кылучыларның мәчет биләмәсенә генә сыешмыйча, урамнарда укыганнарын күргәч, хәзрәт белән минем күңелнең нинди илаһи рәхәтлек кичергәнен белсәгез иде сез! Намаз укучылар сафында мәчеткә ярдәм итүче җитәкчеләребез дә башларын сәҗдәгә ияләр бит. Аллаһ каршында һәркемнең тигез икәнен алар да аңладылар. Гомеребез бушка узмады, Аллаһ юлында ихлас күңелдән хезмәт иткәнебезне Себер җирендә эшләүчеләр дөрес итеп кабул иттеләр, – дигән уйдан җаныбыз җылына. Менә шул җылылыкның кайнарлыгы безне Себер салкыныннан саклый да инде, кардәшләрем. Тормышыбызның иң кыен чорында янәшәбездә сез булдыгыз, – дип әйтеп бетерүгә, Рәйсәнең телефоны чылтырады. – Авылдан Гәүһәрия  сеңлем, – дип, колагына куйды. Ул сөйләшкән арада мөслимәләр чәйләрен эчеп бетереп, бер-бер артлы таралыштылар.

– Апай, җиденче ноябрь көнне авылда шәҗәрә бәйрәме үткәрәбез. Барыгызның да кайтуы мәҗбүри, яме. Безнең нәсел җебен 1678 елдан башлап өйрәндем. «Татарлар» телевизион тапшыруына әзерлиләр. Республиканың Кадрия Идрисова җитәкчелегендәге «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы хатын-кызлары килә. Бик яхшы булачак, апаем.

Гәүһәриянең үзе йомшак, үзе үтемле итеп чакыруына каршы килергә мөмкинме соң!..

– Әлбәттә, кайтабыз, сеңлем, – дип кенә әйтә алды.

...Гәүһәриянең чакыруы Рәйсә абыстайның күңелен авылга кузгатты. Югыйсә, Сара янына Казанга елына бишәр тапкыр да кайтып киләләр. Шәҗәрә бәйрәменә дип чакыру аның һәр туганын аерым-аерым күз алдына китереп бастырды...

Ак яулыгын аркасына җәеп салып бәйләгән әнисен уйлагач, бите буйлап кайнар яше тәгәрәде. Авылда аннан да гыйлем, тәкъва кеше тагын бармы икән? Әнисенең тирән мәгънәле, зирәк фикерләрен, гыйбрәтле сүзләрен, иң кирәкле догаларын һәрчак бер дәфтәргә язып барды. Башта ул аларны мәҗлесләрдә вәгазь сөйләгәндә кулланды. Аннары дәфтәре калынайгач, «Иң кирәкле догалар» дип, китап итеп чыгарып, туганнарына, дини кардәшләренә таратты...

Туган җирнең, туган телнең кадерен белү өчен, аннан бераз аерылып тору кирәк икәнлеген, Рәйсә Сургутка килеп яши башлауга аңлады. Базарда, урамда татарча сөйләшкән кеше дә туганы кебек якын кешегә әйләнде. Кешенең кадере аны югалткач, туган якның кадере аннан ераклашкач беленә икән, дип, ничәмә-ничә тапкырлар кабатланып, күңеле аша уздырды. Бер аның гына түгел, читтә яшәүчеләрнең уртак сагышы бу...

– Абыстаем, ник моңаеп уйга калдың? – дип, аның янына Таһир хәзрәт килеп утырды. Гомер иткән абыстаеның йөзенә генә карап алды да: – Әйтмәсәң дә, күзеңнән күрәм, тагын бер туганыбыз авылга мәчет ачарга чакырдымы әллә?

«Шәҗәрә» бәйрәме турында әйткәч, хәзрәтнең дә йөзенә кояш нуры иңгәндәй булды.

– Туган як белән ике араны ныгытып торучы туганнарыбыз булуы белән ничек бәхетле без! Барысы да динле-иманлы, хаҗ сәфәрләренә барып торалар. Без – дөрес юлда яшибез, кешенең иң олы куанычы шушы бит. Минем дә сиңа шатлыклы хәбәрем бар: Сургутта икенче мәчет төзергә

бик уңайлы урыннан җир бирелде.

Рәйсә абыстай иренең күзенә карап торды да, әйтергә теләгән сүзен башта күңеле иләге аша үткәрде.

– Халык бер мәчеткә генә сыймый, икенчесе кирәклеген аңлыйм. Тик хәзрәтем, таякка таянган картлык көнебез җиткәнче, туган якка кайтып урнашырбыз инде. Синең сызган юлыңнан атлаучы улыбыз бар, яңа мәчетне яшьләр кулына тапшырырсың, – диде җайлап кына, иплəп кенә, ире күңеленә юл табарга тырышып.

Таһир хәзрәтнең йөзе бер яктырды, янә кырысланып алды. Ул карашын тәрәзәгә таба юнәлдерде. Күңелендә егерме ел элек йөрәгенә сеңеп калган вакыйгалар кузгалып куйды. Илле градуслы салкын кыш. Ул, мәчет төзергә җир сорау өчен, иртәнге сәгать биштә поездлан Салихард шәһәренә килеп төште. Каршы алучы юк. Җиргә куе томан төшкән, машина фарасы да күренми. Башта борчылуданмы, сизмәде салкынны. Ул вокзал каршында көннең ачылганын көтеп, әрле-бирле йөри башлады. Каршы алырга килергә тиешле кешеләр, берәр сәгатьтән генә килеп җиттеләр. Салихард шәһәренә, мәчет салырга яхшы урын алу өчен, өч тапкыр барды. Илле-алтмыш градуслы салкынга каршы торырга да ияләшә икән адәм баласы...

– Тормышыбызның бик авыр һәм катлаулы вакытлары бар иде, абыстаем. Аллага шөкер, без ул чорны уздык. Себер салкыны мине чыныктырды, чын ир-егет ясады. Туган якка кайту – читтә яшәгән һәркемнең олы хыялы. Тәкъдиребезгә язылган булса, кайтырбыз. Туган якта – безнең нәсел тамырыбыз исән...

*Гөлсинә Галимуллина*